Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 29 (1394) 29 июль 2022 ел

1995 елның июленнән башлап чыга

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga madani_zhomga

12

Россиянең иң зур мәгарәсе Шүлгән-Таш Башкортстанның Бөрҗән районында урнашкан.

14

Мамадыш районының Кече Сон авылында бертуган Яруллиннар исемендәге сквер ачылды.

16

Генерал дәрәҗәсенә тәкъдим ителгән комдив Миргазиян Крымов 1945 елның 15 апрелендә һәлак була.

Иртәгә Бөтендөнья татар конгрессының VIII корылтае ачыла

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

● Чиләбедә татар мәдәнияте белән бәйле урыннар кергән экскурсия эшли башлый.

● Башкортстанның Баймак районындагы Граф күле буенда «Башкорт аты» башкорт токымлы атлар фестивале уза.

● Актаныш районының «Баламишкин» гармунчылар ансамбле «Күңеллләрдән – гармуннарга, гармуннардан – авылларга» проекты белән авылларга мәдәни сәфәр ясый.

● II Халыкара этномәдәни «Ага-Базар» фестивале кысаларында узган «Аулак өй баттл»ында Чуашиянең Батыр районы командасы финалда Зәй командасын отты, өченче урында – Апас, дүрттә – Татарстан Язучылар берлеге командасы.

● Сәмаркандта узган «Үзбәкстанның мәдәни мирасы – яңа Ренессанс нигезе» халыкара конгрессы кысаларында Татарстан Милли музее ядкәрләре тәкъдим ителде.

● Казан халыкара мөселман киносы фестиваленә волонтерлар командасы туплана, бу эштә 18 яшьтән өлкәнрәк һәркем катнаша ала.

● Казанның Бауман урамында Yummy Music лейблы резидентларыннан бушлай концертлар сериясен Qaynar лабораториясе башлап җибәрде.

● 1 августтан РФ Президенты каршындагы мәдәният һәм сәнгать советы 2022 елда яшь мәдәният эшлеклеләре өчен президент премиясен алуга документлар кабул итә башлый.

● «Глаголица» халыкара әдәби премиясендә катнашу өчен эшләр 19 сентябрьгә кадәр кабул ителә.

● Казанда шәһәр халкыннан җыелган хикәяләр нигезендә Кабан күле тирында аудиоспектакль булдырачаклар.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Ирада ӘЮПОВА, Татарстан мәдәният министры:

«Минем парапланда очканым бар. Беренче тапкыр иң рәхәте – чөнки нәрсә икәнен белмисең. Икенче тапкырында үзеңне мәҗбүр итәсең, өченчесендә тагын да катлаулырак... бишенче, җиденче тапкырында син очуның тәмен тоясың. Беренче тапкыр фестиваль оештыру да бик җиңел – белмичә тотынасың. Аннары авырлаша бара, чөнки аны үстерергә кирәк».

СЫНАМЫШЛАР

Августта имән чикләвеге күп булса, игеннәр уңа ● Томан озак таралмаса – көн аяза ● Августта яшенле яңгырлар күп яуса, көз озын килә ● Август яңгырсыз булса, көз җылы һәм коры килә ● Эт үлән ашаса, яңгыр бик озак явар ● Иртән чык мул төшсә, көн бик эссе була.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **3 сәгать 42 минутта** чыкты, һәм ул **19 сәгать 56 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **16 сәгать 14 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **27 минутка кыскарачак** һәм киләсе җомгада, ягъни **5 августта 15 сәгать 47 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

29 июль – дин эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Харис Салихҗан улы Салиховка 95 яшь (1927);

– композитор, музыкант, дирижер Ильяс Фәйзрахман улы Камаловка 30 яшь (1992).

30 июль – Халыкара дуслык көне.

1 август – әдәбият галиме, тәнкыйтьче, профессор Рифат Хәсән улы Сверигинга 90 яшь (1932);

– Татарстанның халык рәссамы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Шамил Мортаза улы Шәйдуллинның тууына 75 ел (1947–2021);

– Беренче бөтендөнья сугышында һәлак булганнарны искә алу көне.

3 август – философия фәннәре докторы, социолог, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Равил Гобәйдулла улы Балтановның тууына 95 ел (1927–1998).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Июль-августның магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 1 август.**

* * *

Гадәттә, яңа айдан айның беренче чирегенә кадәр **(28 июль-5 август)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **27 июльдән 13 августка кадәр** ашказаны асты бизе, талак һәм ашказаны актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны ныгыту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1443 ЕЛ

Бүген зөлхиҗҗә аеның 30 нчы көне

ЖАН АВАЗЫ

Илһам ФӘТТАХОВ

ПЕДАГОГИКА УНИВЕРСИТЕТЫН КАЙТАРЫЙК!

Халкыбызның зыялылары яраткан «Мәдәни җомга» газетасында көн кадагына суга торган актуаль мәкалә язучы, милләтне яклап кыю сүз әйтүче ватанпәрвәрләр күп түгел: Әгъзам Фәйзрахманов, Әхәт Сафиуллин, Рүзәл Юсупов, Индус Таһиров, Тәлгат Галиуллин, Хатыйп Миңнегулов, Рабит Батулла, Вахит Имамов, Фоат Уразай, Фәүзия Бәйрәмова, Тәэминә Биктимерова, Ренат Харис, Римзил Вәлиев, Тәлгать Әхмәдишин...

Академик Р.Юсуповның «Педагогика университеты кирәк!» (М.Җ., 18 март, 2022), Айдар Гариповның «Без дә студент идек» (8 апрель, 2022), Татарстанның халык шагыйре Р.Харисның «Укытучы – кеше җанының баш инженеры» (29 апрель), милләтпәрвәр Т.Әхмәдишинның «Татар гимназиясендә татарча укытсыннар» (27 май), академик Т.Галиуллинның «Иртәгә соң булыр!» (3 июнь), академик И.Таһировның «Без – чигенмәс халык» (24 июнь) исемле мәкаләләрен укыгач, җаным түземәде, кулга каләм алдым.

Югарыда исемнәре телгә алынган авторларның эчтәлекле язмаларын һичьюгы 1000 татар укыса, бу да яхшы күрсәткеч. Әмма бездә татар матбугатына күзәтү ясап, аңа академикларның педагогика университетын торгызу турындагы тәкъдимнәрен дә кертеп, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов өстәлենә салучы вәкил юк. Шул сәбәпле мөхтәрәм галимнәрнең саллы идеяләре тормышка ашмый кала.

Мәскәү һәм Санкт-Петербургның педагогика институтларыннан соң, XIX гасырның икенче яртысында ук ачылган шанлы Казан педагогика институты 140 ел чамасы мөстәкыйль югары уку йорты булып яшәде. Ни кызганыч, гасыр ярымлык бай тарихка ия уку йортын аяз көнне, көпә-көндез суккан яшендәй юк иттеләр. Безнең бәхетсез илдә, өлкән буыннар тырышып-тырмашып булдырганның кадерен белмиләр, каш ясыйм дип, күз чыгаралар.

Совет чорында Идел-Урал һәм Себер төбәкләре өчен Казан дәүләт педагогика институты (КДПИ) системалы рәвештә педагогик кадрлар әзерләде. Нигездә Татарстан, Башкортстан, Чуаш республикалары һәм Түбән Новгород, Самара, Пенза, Төмән өлкәләре өчен татар теле һәм әдәбияты укытучыларын әзерләп торды. Шулай ук КДПИ Татарстанның авыл мәктәпләрендә математика, физика, химия, биология, география фәннәреннән татар телендә төпле белем бирерлек милли кадрлар әзерләүче югары уку йорты булып исәпләнде.

Безгә – татарларга Казанда федераль университет ачу кирәк идеме? Минемчә, юк. Россия Федерациясе Президенты Дмитрий Медведев фәрманы буенча федераль университетларны ачкан чакта, атаклы Санкт-Петербург һәм Мәскәү дәүләт университетларына кул да тидермәделәр, аларның структураларын җимермәделәр. Киресенчә, аларны саклау һәм үстерү турында Д.А.Медведев махсус указ чыгарды.

Данлыклы Казан дәүләт университеты, классик университет буларак сакланып калган булса, татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләр факультеты өчен, шул исәптән татар теле, татар әдәбияты, татар телен һәм әдәбиятын укыту методикасы, чит телле аудиториядә татар теле, тюркология кафедралары, татар халкы һәм Татарстан тарихы кафедрасы, татар журналистикасы кафедрасы өчен күпкә яхшырак булыр иде. Һәрхәлдә, алар ябылмас иде, бүген дә фәнни эшчәнлек белән нәтиҗәле шөгыльләнер иде. Хәер, татарның акылы төштән соң, әмма терсәкне тешләп булмый шул.

1944 елда Иосиф Сталин приказы буенча аерым бүлек буларак ачылган шанлы татфакны 2012 елда бетерергә, санап үткән шушы кадәр татар кафедраларын ябарга элекке ректор Илшат Гафуров юл куйды, хәзер үзе Россиянең Тикшерү комитеты кулында.

Атаклы җәмәгать эшлеклесе Индус Таһиров халыкка дөресен әйтеп бирә, хәзер «Россиядә карагруһчыл рух көчәйдә», ди ул. Тарихчы-галим газиз милләте хакында күңелендә йөрткән уй-хисләрен ак кәгазьгә төшереп калдырырга ашыга, уйлаганын газета укучыларга курыкмыйча яза.Аның киң җәмәгатьчелеккә җиткергән кыю фикерләрендә, башбирмәс позициясендә Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитетын ун ел буе нәтиҗәле җитәкләве ярылып ята. Бу дәлилне күптән түгел Бакуда вафат булган «соры кардинал», Борис Ельцинның уң кулы саналган Геннадий Бурбулис белән бергә 90 нчы еллар башында Россия-Татарстан делегацияләре сөйләшүләрендә актив катнашкан Индус Таһировның принципиаль позициядә торуы да раслый.

Татар авылын бөтенләй юкка чыгудан коткарып калу өчен, һәм аерым алганда, бүгенге икътисади кризистан чыгу өчен, кичекмәстән республика дәрәҗәсендә стратегик план эшләргә кирәк, дип саный күренекле тарихчы И.Таһиров. Чыннан да, бүген авылда эш урыннары булмау сәбәпле яшьләр салада төпләнеп калмагач, утыз-кырык елдан соң татар авыллары сакланып калырмы, дигән урынлы сорау туа.

Казанны һәм Чаллыны территориаль яктан да, халык саны буенча да үстерүне туктатып, район үзәкләрендә һәм зур татар авылларында асфальт-битум, бетон, кирпеч сугу заводлары, калай җитештерү, савыт-саба ясау предприятиеләре төзергә, күпләп фирма-офислар ачу өчен кече һәм урта эшмәкәрлеккә яшел ут кабызырга кирәк. Бу турыда Президентыбыз Р.Миңнеханов та бер киңәшмәдә чаң суккан иде. Нәтиҗәдә татар халкы да эшле булачак, милли мохит сакланачак һәм безнең яңа зыялылар да үсеп чыгачак. Татар капиталистларының инвестицияләрен бүген авылга кертергә кирәк. Татарстан хөкүмәте бу проектка алынса, башкарып чыга торган эш, дип уйлыйм.

Казанда педагогика университеты булырга тиеш, аны торгызыйк! 2000 елларда татарча диссертация язып яклаган буа буарлык фән кандидатларына бүген КФУда укытырга эш урыннары җитми. Педагогика университеты яңадан ачылса, аларга эш булыр иде. 2010 еллар башында КФУга җиңел юл белән генә кушып куелган Татар дәүләт гуманитар университетын (элекке КДПИны) кире кайтарырга кирәк. Әдәбият галиме һәм әдип Т.Галиуллин язганча, «иртәгә соң булыр!»

МИЛЛӘТ КӨЧЕ – ЯШӘҮ РӘВЕШЕНДӘ

Бу тезисның хаклыгы тормыштан алынган ике кавем мисалында да ачык күренә. Тема четерекле булганга, исемнәрен атамыйча, аларны шартлыча «беренче» һәм «икенче» дип кенә билгелик. Беренчесе – бай тарихлы, тамырлары бик тирәнгә китә. Икенчесенең дә тарихы бай, әмма ясалма җирлектә формалашкан һәм, асылда, басып алу сугышларын хәтерләтә. Беренчесе үзенә генә хас тәрбия системасын булдырган, бу юнәлештә һәм генеалогиядә өстенлек хатын-кызга бирелә. Икенчесенең дә үз яшәү рәвеше, зур урын анда бәйрәм вә кәеф-сафа коруларга бирелә, яшь буын да күбрәк шундый һәм патриотик рухта тәрбияләнә. Беренчесе дөнья буйлап таралып яши, һәр җирдә хакимияткә омтыла, хокук, фән һ.б. өлкәләрдә югары урын били, үз мәктәпләрен һәм хәтта университетларын булдыра. Икенчесе дә күп таралган, тик үзенчәлекле яшәү рәвеше һәм холкы аркасында, башкаларда аңа карата сагаюлы мөнәсәбәт урнашкан. Янә бер уртаклык – һәр ике кавем дә башкалар белән уртак гаиләләрне күп кора. Икенчесе өчен бу аларны ассимиляцияләү чарасы булса, беренчесе моны сайлабрак эшли, үз нәселен талантлы шәхес дәвамчылары белән бәйләргә омтыла, шул рәвешле үз генетикасын яхшырта, кирәк икән – чит кавемгә дә үтеп керә, исемен, горефен һәм хәтта динен дә үзгәртә. Әмма үз асылын саклап кала, кыйбласын үзгәртми, киресенчә, яңа кавемне эчтән үзгәртә, аны үзенә хезмәткә куя.

Әлбәттә, төп хикмәт – нәтиҗәләрдә. Ә алар төрле: әйтик, беренчесе вәгъдәле җирдә кечкенә дәүләт корса да, аны гөл-бакча итеп яши, иске язмаларда гына сакланган телен, гореф-гадәтләрен торгызды, фән һәм технологияләр ягыннан алга киткән дәүләт санала. Кавем үзе – зур амбицияле, максатчан, меңьеллыкларга исәпләнгән геосәясәи планы да бар, асылда, бүген инде ул – дөнья тотучылар рәтендә. Икенчесе дә зур амбицияле, тумыштан ук бөекдержавачыл мин-минлектән изалана. Тик ул, гаять зур территория һәм бай табигый ресурсларга ия булса да, гасырлар дәвамында хәерчелектә яши, башкалар кулында сәясәт коралы һәм «туп азыгы» булып кала. Күренә ки, яшәү рәвеше дөрес булмаса һәм милләт миссиясенә җавап бирмәсә, ишле кавем дә башкаларга хезмәт итүдән ары китә алмый. Ә яңа дөньяви тәртип белән бәйле үзгәрешләр барлык милләтләргә дә кагылачак. Хәтта дөнья тотучыларга да үзгәрергә туры киләчәк. Чөнки аларның яшәү рәвешендә һәм эш-гамәлләрендә отыры иблис алымнары өстенлек итә башлады. Ул гына түгел, бүген инсаният кичерә торган глобаль кризис өлешчә шуның белән аңлатыла да.

Милләт көче турында сүз барганда, әүвәл рухи як, иман ныклыгы һәм үз кыйблаңа тугры калу күздә тотыла. Илаһи миссияле милләт буларак, яшәү рәвешен, әлбәттә, татарга да үзгәртергә туры киләчәк. Узган язмада сүз аның күркәм сыйфатлары турында булган иде. Ә сыйфатларның бит началары, хәтта алга барырга комачаулый торганнары да бар. Димәк, иң элек алардан арыну лязем. Ә яшәү рәвешен дә кирәгенчә үзгәртү өчен югары кимәлдәге милли аң, кешелек язмышы вә милләт миссиясе өчен җаваплылык, шулай ук тумыштан бирелгән тырышлык һәм үзоешу кебек асыл сыйфатларга да ия булу кирәк. Соңгысы бүген аеруча мөһим. Ә илдә төп халыклар хәзер чын мәгънәсендә хокуксызлык чигенә җиткезелгән: милли мәгарифләре һәм туган телләре чикләнгән, дәүләтчелек формалары гамәли яктан бетерелгән, алар бүген хәтта үз хокукларын парламентта яклау мөмкинлегеннән дә мәхрүм ителгән. Сайлау системасы һәм парламент анда демократияне имитацияләү өчен генә кулланыла. Асылда, илдә авторитар режим урнаштырылган. Сүз хәтта, төп халыкларның дәүләтчелек формаларын бетереп, милли-мәдәни автономияләр итеп калдыру турында да бара. Күз буяу өчен, алга таба Россия халыклары ассамблеясе дә корылырга мөмкин. Шул рәвешле, бәгъзеләр илдә гомумроссия тәңгәллеге булдырмакчы.

Мондый шартларда төп халыкларга инде үзенең яшәү рәвешен, яңа рухи биеклеккә күтәрелеп, уртак проблемаларны бергәләп хәл итү мөмкинлеген үзгәртү юлы гына кала. Ә ул метасәясәт (илаһият кануннары буенча яшәүгә күчү сәясәте) өлкәсендә ята. Миссияле милләт буларак, зур җаваплылык татар милли хәрәкәтенә дә төшә. Яшәү рәвешен шуңа тәңгәл үзгәртү өчен ул яңа шартларга җавап бирерлек итеп үзоешуга һәм метасәясәтне югарылыкта эш итәргә тиеш була. Бүген аның өчен бу – бердәнбер ышанычлы юл.

Фоат УРАЗАЙ.

Борынгы мәчет урынына яңасы

Түмән өлкәсендәге Яңавылда борынгы мәчет урынына яңасын төзергә җыенаклар. Түмән татарларының «Яңарыш» сайтында Гөлнур Вәлиеваның «Мәчет урынын хөрмәтләп» дигән язмасы чыкты.

Түмән шәһәренең Яңавылында элекке традицияне кире кайтарырга уйлыйлар. Монда Корбан бәйрәмен билгеләп үттеләр. Бу эшне «Әл-Манар» мөселман волонтерлык хәрәкәте башлап җибәргән.

– Ниятләп куйган идек, менә тормышка ашырдык, – диде хәрәкәтнең, шулай ук «Яңавыл» мөселман дини оешмасының җитәкчесе Әмир хәзрәт Галиев. – Элекке елларда яңгыр сорап корбан чалу, Корбан гаетен үткәрүләр Түре яр буенда оештырыла иде.

Ул елларны хәтерләрендә саклаучылар бар әле. Корбан ашы үткәрү турында хәбәр чыккач, барысы да шул елларны искә төшереп булышырга теләк белдерделәр. Бергәләшеп бу эшне

башкарып чыктык.

Мәчет урынын саклап торучы Идрис Саттаров корбан чалу турындагы уен белдереп, оештыруда ярдәм сорагач, без берсүзсез риза булдык.

«Төшемдә бу урында мәчет торгызылганын күрдем. Бу хыялым белән өлкә мөселман Диния нәзарәте җитәкчесе Зиннәт хәзрәт Садыйковка киттек. Аның белән уртаклашып, аңлатып уртак фикергә килдек: тиздән монда яңа мәчет калкып чыгачак. Әлегә кәгазь эшләре башкарыла.

Мәчетебездә традицион ислам тәртипләре – үзебезнең борынгыдан сакланган гореф-гадәтләрне куллanырбыз», – дип сөйләде Идрис Галимулла улы.

Бәйрәмгә башка төбәкләрдән, чит илдән дә кунаклар килгән иде.

Тәбрикләү өчен сүз өлкә мөселман Диния нәзарәте җитәкчесенең урынбасары Рөстәм хәзрәт Камалиевка бирелде. Рөстәм хәзрәт – Мәскәү ислам университетын кызыл диплом белән тәмамлаган югары белемле белгеч. Ул Корбан бәйрәменең тарихы, мөселманлыкның әһәмияте турында сөйләде.

Өлкә мөселман Диния нәзарәте җитәкчесе киңәшчесе Динар хәзрәт Нәфыйков Россия дини мөселман оешмасы мөфтие Равил Гайнетдин, Зиннәт хәзрәт Садыйков исеменнән котлауларны җиткерде. Түмән дәүләт университетының гарәп үзәге рәисе Әхмәт Сәет Ибраһим килүчеләргә изге теләкләрен юллады. Аннары «Әл-Манар» хәрәкәте җитәкчесе Әмир хәзрәт иң тырышларга Рәхмәт хатлары тапшырды.

Бәйрәмне әзерләүдә Яңавылны торгызуда, тарихи хәтеребезне саклауда актив эшләр алып баручы Әлмирә ханым Гомәрова килүчеләргә, үз өлешләрен кертүчеләргә рәхмәт белдерде.

Бөтендөнья татар конгрессының VIII съездын үткәрү программасы

30 июль (шимбә)

14.00-18.00 Кунакларны һәм делегатларны каршы алу, теркәү, кунакханәләргә урнаштыру

18.00-21.00 «Печән базары» заманча татар дизайны һәм татар шәһәр мәдәнияте фестивале *(Кабан күле яр буе, Иске татар бистәсе, Ш.Мәрҗани урамы)*

21.00-21.30 Тору урыннарына кайту

31 июль (якшәмбе)

08.00-11.00 Изге Болгар тарихи-архитектура музей-тыюлыгына бару *(Болгар шәһәре)*

11.30-12.00 Изге Болгар җирлегендә Бөтендөнья татар конгрессының VIII съезды делегатларын сәламләү *(Ислам динен кабул итүнең истәлек тамгасы)*

14.00-17.00 Съезд делегатлары һәм кунаклары өчен Изге Болгар тарихи-архитектура музей-тыюлыгы буенча экскурсия

1 август (дүшәмбе)

08.00-08.30 «Казан Экспо» Халыкара күргәзмә үзәгенә бару (Күргәзмә ур., 1)

08.30-09.30 «ТАССРның 100-еллыгы әләме белән истәлек фотосы» акциясе *(«Казан Экспо» Халыкара күргәзмә үзәге, Күргәзмә ур., 1)*

08.30-18.00 Бөтендөнья татар конгрессының 30 еллык тарихына багышланган күргәзмә эше *(«Казан Экспо» Халыкара күргәзмә үзәге, Күргәзмә ур., 1)*

9.00-10.00 Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура утырышы («Казан Экспо» Халыкара күргәзмә үзәге, Күргәзмә ур., 1)

10.00-13.00 Дискуссия мәйданчыклары эше:

1. Идел Болгарстанында Ислам динен кабул итүгә 1100 ел. Татар дөньясы һәм Ислам дине.
2. Милли мирас. Татар мәдәнияте: бүгенгесе һәм киләчәге.
3. Милли үзаңны тәрбияләүдә шәҗәрәнең әһәмияте. Гаиләнең, балалар бакчасы һәм мәгариф системасының роле.
4. Татар эшмәкәрлеге һәм иганәчелек.
5. Тарихи шәхесләр һәм хәзерге заман татар дәүләт эшлеклеләре: милли горурлык тәрбияләү мәсьәләләре.
6. Татар төбәк тарихын һәм татар тарихи-мәдәни мирасын өйрәнү мәсьәләләре.
7. Татар мәгълүмат кыры: алда торган бурычлар. *(«Казан Экспо» Халыкара күргәзмә үзәге, Күргәзмә ур., 1)*

14.00-16.00 Татарстан Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе В.Шәйхразиев катнашында Съездны ачу тантанасы («Казан Экспо» Халыкара күргәзмә үзәге, Күргәзмә ур., 1)

16.00-18.00 Татар халкының сәнгать осталары концерты *(«Казан Экспо» Халыкара күргәзмә үзәге, И. Шакиров исемендәге концертлар залы, Күргәзмә ур., 1)*

2 август (сишәмбе)

08.00-09.00 «Казан Экспо» Халыкара күргәзмә үзәгенә бару *(Күргәзмә ур., 1)*

10.00-13.00 Татарстан Президенты Р.Миңнеханов катнашында пленар утырыш *(«Казан Экспо» Халыкара күргәзмә үзәге, И. Шакиров исемендәге концертлар залы, Күргәзмә ур., 1)*

13.20-14.00 Эшлекле төшке аш форматында Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасының яңа составта беренче утырышы *(Милли Шура әгъзалары өчен; «Казан Экспо» Халыкара күргәзмә үзәге, Күргәзмә ур., 1)*

1 нче биттә – Конгресс тормышыннан бер мизгел.

Бишбалта осталарына һәйкәл

Казанның Киров районындагы Николай Столяров исемендәге паркта «Петр I реформалары. Тарихи мирас һәм хәзерге заман» халыкара фәнни-тикшеренү форумы кысаларында «Бишбалта осталары» һәйкәленә чәчәк кую мәрәсиме булды. Анда ТР мәдәният министры Ирада Әюпова, «Елисаветинско-Сергиевское просветительское общество» фонды Күзәтү советы рәисе Анна Громова, һәйкәлне кую инициаторы, меценат Гарәфетдин Хисаметдинов, скульптор Зөлфия Мөхәммәдьянова катнашты.

«Адмиралтейство бистәсе борынгы Бишбалта территориясендә төзелгән. Анда яшәүчеләр тирә-якка данлыклы агач эше остасы булган. Илдә флот төзү шул исәптән әлеге бистә осталарының гасырлар буе тупланган тәҗрибәсенә дә таянып башланган», – дип билгеләп үтте мәдәният министры Ирада Әюпова. Ул тарихи мирасны торгызуда актив эшчәнлеге өчен Г.Хисаметдиновка Рәхмәт тапшырды.

Һәйкәл Столяров бакчасына 2020 елда ук куелса да, пандемия сәбәпле шәһәр җәмәгатьчелегенә тәкъдим ителмәгән иде. Бирелдәге «Урак һәм чүкеч» заводында 30 ел эшләгән хезмәт ветераны Гарәфетдин Хисаметдинов аны үз акчасына ясаткан, скульпторын да үзе тапкан.

Идел Болгары һәм Казан ханлыгы чорыннан башлап хәзер Адмиралтейство бистәсе урнашкан территориядә яшәүче халык сәүдә кораблары төзегән. Бишбалта исеме Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 1718 елда Петр I Бишбалта янәшәсендә Адмиралтея верфенә нигез салырга фәрман биргән, чөнки монда верфьләр төзү өчен инде бөтен шартлар да булган. Казандагы адмиралтейство ул дәвердәге Россиядә иң алдынгылардан берсенә әйләнгән. «Бишбалта осталары» һәйкәле – бергәләп Россия флотын төзегән Россия халкына ихтирам билгесе ул, Петр чорында флотны аякка бастыруга зур өлеш керткән уңган, хезмәт сөючән, оста бабаларыбыз истәлеген мәңгеләштерү дә.

Китаплар турында видеожурнал

Yummy Music лейблы Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең «Татарча Тираж» видеопроектының беренче чыгарылышын тәкъдим итә. «Тираж» – ул китапханә фондының иң кызыклы китаплары турындагы видеожурнал. Хәзер «Татарча Тираж» атна саен татар телендә дә чыга башлый.

Беренче чыгарылышның кунагы – хореограф Нурбәк Батулла – Мәхмүт Галәүнең «Болганчык еллар» китабын тәкъдим итә.

«XIX гасыр татарларын нәрсә борчыган, алар тормышында нинди кыенлыклар булуын белергә теләсәгез, һичшиксез бу әсәр белән танышырга тиешсез. Театр сәнгатен сөючеләр 2022 елның яңа сезонында Г.Камал театрында «Болганчык еллар» әсәре буенча сәхнәләштерелгән яңа спектакльне дә күрә алачак», – дип хәбәр итә Yummy Music лейблы редакциясе.

«Татарча Тираж» проекты Татарстан Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе, Татарстан Яшьләр эшләре министрлыгы, Бөтендөнья татар яшьләре форумы ярдәме белән гамәлгә куела.

Суслонгерда мәчет ачылды

Марий Эл Республикасының Звенигово районындагы Суслонгер бистәсендә мәчет ачылды.



«Суслонгерда мәчет күмәк көч белән төзелде. Безнең өчен мәчет ачылу тантанасы – куанычлы вакыйга, һәр мөселман өчен көтеп алынган бәйрәм. Яңа мәчет һәркемгә шатлык-сөенечләр алып килсен», – диде Марий Эл Республикасының «Республика татар мәдәнияте үзәге» методисты Рамай Юлдашев.

Аның әйтүенчә, сугыш елларында Суслонгер янында хәрби хезмәткә алынучыларны әзерли торган лагерь урнашкан була. «Бу лагерьдә әзерлек үткәндә күп кенә солдатларның ачлыктан тилмерүе, вафат булуы мәгълүм», – диде ул.

Мәчетне төзергә активистлар, авыл халкы, төрле иганәчеләр булышкан. «Кем акчалата, кем кул көче белән ярдәмгә килде. Аллаһ ризалыгы өчен дә эшләүчеләр күп булды», – диде ул һәм мәчет төзүгә үз өлешен кертүчеләрне атады.

«Суслонгер халкы дини ихтыяҗларын күрше-тирә мәчетләргә йөреп, башкара торган булган. Мочалище бистәсе имамы Рафаэль хәзрәттә укып, гарәп телен, дин нигезләрен өйрәнгәннәр. Шулвакыт хәзрәт Суслонгерның үзендә мәчет салырга кирәк, дигән фикерен җиткерә. 2018 елның 3 февралендә Суслонгерда җыелыш оештырыла. Халыкка мәчет кирәклеге аңлатыла. Халык хуплап ала. Шушы җыелышта ук мәхәллә төзелә», – диде ул.

Мәчет ачылышында Россия Диния нәзарәтенең эчке эшләр департаменты җитәкчесе Наил Шакиров, Марий Эл Республикасы Мәдәният, матбугат һәм милләтләр эшләре министрлыгының баш белгече Александр Илларионов, Звенигово районы администрациясе вәкиле Ольга Михайлова, Суслонгер бистәсе рәисе Сергей Кудряшов һ.б. катнашкан.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

«Яшәүгә юл» дәвам итә

«Ярдәм» илкүләм хәйрия фонды Татарстанда «Яшәүгә юл» проектын дәвам итә. «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында үткән матбугат очрашуында Фонд президенты Илһам Исмәгыйлев хәбәр иткәнчә, «Ярдәм» илкүләм хәйрия фонды волонтерлар булышлыгы белән һәр көнне 250 кешене кайнар аш белән тәэмин итә. Шулай ук ай саен 200 ләп кешегә ризыклар алу өчен сертификатлар да таратыла. Бериш кешеләргә ярдәмне кайнар ризык белән бирмәүнең сәбәбе – мохтаҗлар арасында шикәр авырулылар, аллергия белән чирләүчеләр булу. Алар үзләренә яраклы азык-төлекне сайлап ала. Кайнар аш өчен мәчет биләмәсендә социаль бина булдырылган.

«Яшәүгә юл» проекты 2020 елда коронавирус пандемиясе чорында эшли башлаган иде. Үзчикләнү вакытында чыгып йөри алмаган, ризыкка мохтаҗ кешеләргә азык-төлек җыелмаларын илтеп бирү һәм кайнар ризык белән тукландыруны күздә тоткан проект ул вакытта бик күпләргә ярдәм итте, ике меңнән артык кеше – ялгыз пенсионерлар, аз керемлеләр, инвалидлар, шулай ук яшәү урыннары булмаган кешеләр көн саен кайнар ризык белән тәэмин ителде. «Бу вакытта 100 меңнән артык кеше ярдәм алды», – ди И.Исмәгыйлев.

Үзчикләнү режимы бетерелгәч тә азык-төлек тупланмасын сорап шалтыратулар кимемәгән. Шушы рәвешле проектны дәвам итәргә ниятләгәннәр. Быелның июль аенда «Яшәүгә юл» проекты кабат уңышка ирешкән, президент грантлары конкурсында икенче тапкыр җиңү яулаган һәм 7 миллион 560 мең сум финанс ярдәме алган. Бу инде проект кысаларында 2022нең июль аеннан 2024 елга кадәр (18 ай) 25 200 кешегә кайнар ризык бирелачәк, дигән сүз. «Ярдәм» мәчете биләмәсендә һәр көнне 70тән артык кешене бушлай тукландыру күз алдында тотыла.

Сөембикә КАШАПОВА.

● Икенче бөтендөнья сугышыннан соң Япониядә азык-төлек кризисы башланган, тәмәкене бармакны пешерә башлаганчы тартканнар. Касио бармакка кия торган балдак-төрепкә уйлап тапкан: ул тәмәкене төбенә кадәр тартып бетерү генә түгел, эштән туктамыйча гына да тарту мөмкинлеген биргән. Әлеге балдакка ихтыяҗ бик зур булган. Аны сатудан кергән акчаны Касио гаиләсе дөньяда беренче Casio калькуляторын җитештерүдә файдаланган.

● Англиядәге 90 мең чамасы кеше яшәгән Хай-Уиком шәһәрендә үзәк мәйданда яңа сайланган һәр мэрның авырлыгын үлчиләр. Әлеге гадәт 1678 елдан бирле саклана. Ул чакта халык, дәүләт малын урлап, салым түләүчеләр акчасына симергән шәһәр башлыгы эштән алынырга тиеш, дигән карыйдә керткән. Бер елдан соң мэрны кабат үлчиләр, авырлыгы арткан булса, элек аның өстенә шәрегән йомырка ыргытканнар, хәзер инде алай мәсхәрәләмиләр.

«Сабантуйлар хәзер – бизнестуй»

«Интертат»та Рәмис Латыйповның «Сабан туен саклыйк!» дигән язмасы җәмәгатьчелекне ду китерде, социаль челтәрләрдә йөзләгән комментарийлар пәйда булды. Аларның берничәсенә күз салыйк.

«Сабантуйның ямен сүндереп, аны Пәри туена әйләндерделәр! Сабан туе - ул кыр эшләрендә катнашучылар бәйрәме булырга тиеш, аны концертка әйләндерделәр. Районнан бәйрәм үткәрергә авылларга бер тиен дә акча бирмиләр, халык үз акчасын җыеп үткәрә!»

«Хәзер һәр район Сабан туен бер-берсе белән ярышып уздыра. Кемгә текәрәк артист килә, шул шәпләрәк, имеш. Халык та бозылды, артистларны Аллаһының кашкасына тиңли башладылар. Бер карасаң, шундый ук, безнен кебек кешеләр. Миллилек бетте. Ярышларда бала-чагага телевизор, суыткыч, кер юу машиналары бүләк итәләр, ә авылда кыр эшендә катнашучыга мактау кәгазе белән 1000 сум акча».

«Сабан туйлары авылда гына уздырылырга тиеш, чөнки авылда гына сабанга чыгалар... Шәһәрдә нинди Сабан туе буладыр, аңлашылмый. Быел авылларда, кырда эшләүчеләр хәтта ял да итмәде, ә районга «яхшы эшләүчеләрне» генә алып киттеләр. Әле шунда да хәтта чәй дә эчерми кайтарганнар. Шәһәрләрдә Сабан туе үткәрүне туктатыгыз, дип кычкырасы килә. Асылда, сабан туйлары «отмывание финансов» булып кына калды сыман. Авылда да шуңа калды, для галочки гына үткәрәләр».

«Сабан туе - ул үзешчәннәр, авыл халкы үзе өчен оештырган уен, җыр-биюләр. Анда түләүле «артистлар» булырга тиеш түгел!»

«Көрәштә дә спортсменнар гына катнаша, шулар бозды бөтен бәйрәм ямен. Артистлар фонограммага «җырлый». Түрәләр халык акчасына көтү-көтү кунак чакырып, күңелләрен күрә».

«Сабантуйлар элек кенә сабантуй иде, хәзер алар бизнестуй».

Сабан туе ничек узарга тиеш? Без шул сорауга җавап эзләдек.

Традицион мәдәниятне үстерү үзәгенең элекке җитәкчесе, филология фәннәре кандидаты Фәнзилә Җәүһәрова:

– Сабан туеның халыкчан асылы 1930 елларда югала башлый, чөнки Сабантуйны коммунистлар идеологик коралга әйләндерә. Шул елларда колхозлашу чоры белән бәйле булган транспарантлар белән парадлар барлыкка килә. Сабан туе белән партоешма һәм дәүләт органнары идарә итә башлый, халык үзе Сабан туен җитәкләүдән туктый. Шул 30 нчы елда яңа төшенчә кертәләр: көрәш батыры белән параллель рәвештә кыр батыры билгеләнә. Халыкчанлыкның бозылуы кичә-бүген генә түгел, күптән бозылган ул Сабан туе.

60 нчы елларда махсус пленум була. Сабантуйны регламентлаштыралар. Ул язгы бәйрәмнән җәйге бәйрәмгә әйләнә. Чәчү алдыннан түгел, чәчү беткәннән соң, махсус карар белән көнен билгелиләр. Шул ук вакытта кайбер вак-төяк авыллар үзләре теләгән вакытта – бер атнага соңрак, я алданрак үткәрә. Аларга беркем бәйләнми.

Татарстан Республикасы барлыкка килгән көннән бирле Сабан туен указ нигезендә үткәрәбез. Әгәр башка көнне була икән, Указны бозу була. Шуңа күрә бик күп авыллар, беренче чиратта, иганәчеләр тарафыннан үткәрелә торган Сабантуйлар, авыл бәйрәме дип үткәрелә. Гомумән, авыл сабан туйлары күп җирдә үтми, җыен дип үткәргәннәре дә онытыла.

Без үзебез үк Сабантуйны рәхәтләнеп бозарга һәм исемен алмаштырырга мөмкинлек бирдек.

Иганәчеләр уздыра торган Сабан туйларында 5 әр мең кеше катнаша бит, шуңа кеше күп килсен өчен популяр артист чакыралар. Район Сабан туйларына чыгым күп тотыла. Авыл җирлекләре дә булыр-булмас акчаларын район Сабан туена илтеп бирә. Эшмәкәрләргә карата да махсус такса, тыңламасаң, яхшы көн күрмә. Район Сабан туеның акланмаган чыгымнары бар. Мәсәлән, прологлар – башлангыч өлеше бөтенләй кирәк түгел. Мәктәп балаларын куып китерәләр дә, концерт күрсәтәләр. Аңа әзерлек айлар буе бара. Бер районда шаккаттым – авыл хуҗалыгында эшләүче 50 кешене тезеп бастырганнар, 1 әр мең сум акча өләштеләр.

Район башлыгы пролог кына карый да кунаклар ашарга кереп китә. Шушы ашау да зур чыгым, әле шунда бүләк тә бирелә бит.

2018 елда сораштырган идем: күп кенә районда бүләкнең суммасы 8 мең сум иде. 100 дән артык кунак булса, күпме акча киткәнен исәпләгез. Кунак чакырмаска димим, ләкин бүләк тә символик кына булырга тиеш. Нигә 8 мең сумга ак, кызыл аракысын, башкасын куеп... Шул ашауларга тотылган акчага күбрәк бүләк алсак, гади халыкның да күңеле булыр иде...

Сабан туенда капчык сугышы – менә дигән тамаша бит! Аны без аннан-моннан гына үткәрәбез дә, аның урынына корпоративта уйный торган уеннарны кертеп тутырабыз. Озын чаңгыга 40 лап кеше басып «чабу» – халыкка ник кирәк? Ул – безнең милләт уены түгел ләбаса!..

Бүген Сабан туе белән идарә итә торган тәгәл оешма юк. Бу Сабан туе бәйгеләренең тамырында тагын бер проблема ята: традицион бәйгеләрне – спорт бүлеге, мәдәни өлешен мәдәният идарәсе уздыра. 2000 елларда мини-футбол, волейбол, баскетбол керә башлады, аларны караучы да юк. Армреслинглар да безнең Сабан туеныкы түгел.

Колгага бөтенләй менмибез. Сабан туйларына чират буенча йөри торган аталы-уллы ирләр бүләк җыеп китә. Ә асылы бит - кемнедер күрсәтү түгел, балаларга үзләрен сынап карау. Куркыныч диләр икән, маталар җәй. 6-7 яшьлек балалар өчен өч метрлы багана да җитә. Өлкәнрәкләр өчен 10 метрлы итеп яса, нигә 35 метрлы колга куясың?!

Килсеннәр артистлар, килмәсен димим, чакырыгыз кичен! Элек кичке уеннар булган бит, биегез татарча, бөтенегез бергә җырлагыз! Акчагыз бар икән, кичке уенны киңәйтегез! Ул көнне көне буе бәйрәм булсын! Көндезге концерт урынына кичке уен мәйданнары эшләргә, гади апалар җырларга тиеш, шигырь сөйләүчесе булырга тиеш. Ун гына тамашачысы булсын, ләкин оештырырга, акчаны шуңа тотарга кирәк.

Көрәш династияләре дә юк бит. Югыйсә, көрәш секцияләре – санап бетергесез, федерацияләребез бар.

Спортчылар керә дә, көрәш бетә. Алар Сабантуйда көрәшергә тиеш түгел, аларның үз ярышлары бар. Бәлки, Сабантуйга чакырырбыз 2-3 профессионал көрәшчене, ләкин аларны аерым келәмдә көрәштерик, ә төп келәмдә бала-чага, үсмерләрне көрәштерүдән башлыйк.

Ким дигәндә, авылыгыздан дүрт пар чыксын, булсын өйрәнчекләр генә, алар арасында да батыр билгеләп була. Тәкәгә эшләсеннәр. Көрәшчеләргә машина бирүне туктатырга кирәк. Чөнки аларны көрәшеп түгел, сөйләшеп бүлешәләр.

Татарстан Дәүләт Советы депутаты Ркаил Зәйдулла:

– Президент әйтте бит: Якутиядә чын Сабан туе нинди булырга тиешлеген күрдем, диде. Мин дә булдым анда, Саах дигән бәйрәмнәрен шундый итеп эшләгәннәр – тәңречелек тамырларына кайту, рухларны чакыру, ритмик алкышлар белән. Йола, ырымнары заманча да яңгырый кебек. Ул бик тәэсир итә. Көмешләр белән хәнҗәрләр тагып, милли киемнәр эшләнгән. Нәкышлар файдаланылган, яңартылган.

Президент дөрес әйтте – хәзер Сабан туе спорт уеннары белән концерт карау.

Авылларда элек Сабантуйлар җыелы уза, авылдан чыгып китүчеләр дә кайтып, бөтен уеннарда катнаша иде. Шәһәрләрдә кыенрак инде – татарга хас толерантлык белән бүтәннәр хәтерен саклау, алар үпкәләмәс микән дип уйлау... Халыклар дуслыгына каршы түгел, ләкин һәрнәрсәнең үз урыны бар. Әгәр Сабан туй – милли бәйрәм икән, ул милли булырга тиеш, ә халыклар дуслыгына багышланган массовка түгел.

Безнең татар бит бер-берсеннән уздырмакчы була. Ул артистлар чакыру ярышын бүтән файдалырак эшкә – йолаларны торгызуга бирсәң... Авылларда бит төбәк тарихлары белән кызыксынучылар бар, шулар белән ниндидер сценарийларын эшләп була. Туган як тарихын шунда яшәүчеләр генә яхшы белә бит. Һәркем үз төбәген күрсәтергә тиеш.

Милли үзаңнан тора инде. Якутларда милли үзаң көчле, татарларда – түбән, шуңа күрә аның бәйрәме дә шундый. Якутлар аз санлы халык булса да, шундый масштаблы итеп үткәргәннәр. Анда бөтенесе катнаша, безнең бит Сабан туенда күбесе тамашачы булып йөри, уенга да керми. Аның татар дигәне дә, йолаларын, традицияләрен генә түгел, телен дә белми.

Элек чәчү алдыннан бәйрәм иткәннәр, хәзер Сабантуй белән җыен икесе бергә кушылды. Җыен ул чәчүләрдән соң булган, берничә авыл бергә җыелып, бәйрәм иткән. Күрше авыл егетләре белән кызларын таныштыруның бер чарасы да булган ул.

Тарихчы, җәмәгать эшлеклесе Айрат Фәйзрахманов:

– Авыл Сабан туйлары кызык, күркәм гадәт, үз традицияләре бар. Сабан туе күбрәк бер-берсен белә торган кешеләр бәйрәме булган, күршеләр общинасы кысаларында уздырылган. Авылларда әле шуның тәме бар.

Ә шәһәр Сабан туйлары зур концертка әверелә. Кызганыч, кеше анда күбрәк тамашачы буларак катнаша. Актив катнашучы буларак түгел, күзәтүче буларак кына.

Соңгы елларда сорыйсың – күпләр шәһәр Сабан туена йөрми, чөнки елдан-ел шул ук тамаша диләр, күбрәк мәдәни-массакүләм чарага әверелгәнгә күрә, кеше йөрми. Шәһәр көне, Республика көненнән әллә ни аерылмый да. Бары тик көрәш, тагын берничә ярыш булуы белән генә аерыладыр. Сабантуйның тәме соңгы арада әллә ни тоелмый.

Шәһәр Сабан туйлары күбрәк мәйданчыкка бүленеп, күршеләр Сабан туе рәвешендә булырга тиештер. Миңа калса, шәһәрдәге һәр мәдәният йорты, һәр зур мәдәни оешма төрле мәйданчыкларда Сабантуй уздырырга мөмкин. Кечкенә мәйданчыкларда Сабантуйлар узса, күбрәк кеше актив катнашучы булып килер иде.

XIX гасыр литографияләрен карасак, Казан Сабан туенда атлар чабышы, көрәшчеләр күренә. Ул традицияләр сакланган, ләкин күзләрендә азарт бар дип әйтимме... Монда бары тик профессионаллар гына булырга тиеш түгелдер, монда гади кешене дә актив катнаштыру мөһим. Балаларны традицион милли уеннарга күбрәк катнаштыру өчен күбрәк мәйданчыклар кирәктер.

Әйтик, якутларда Сабантуй форматы гына түгел, җыен традицияләре күренә. Алар тамаша гына карамый, һәрберсе актив катнашып, аралашып йөри. Күп мәйданчыкларга бүленешеп, яңадан зур мәйданга җыелалар. Җыен форматы кызык ул. Бәйрәмдә һәркем актив катнашырга тиеш.

Гөлнар ГАРИФУЛЛИНА.

intertat.tatar.

Мәдәни җомга
29 июль
№29, 2022

Дәвер моңын саклаучы

(Әлфия Ситдыйкова иҗатына күзәтү)

Һәр язучы – үз иҗатында кабатланмас, үзенчәлекле шәхес. Ул чынбарлык күренешләрен үзенә генә хас хисләр һәм тойгылар, фикерләр белән сугара. Бу күренеш язучының тәрҗемәи хәле, рухи тәҗрибәсе белән бәйле. Әлфия Ситдыйкова иҗаты белән дә бу шулай. Г.Гыйльманов аны «кайнап торган тормыш, язмыш эченнән калыккан каләм иясе» дип бәяли, әдип Ф.Сафин да сүзен шушы ук рухта җиткерә.

Ә.Ситдыйкова Актаныш районы Кузкәй авылында туа. Пучы урта мәктәбен тәмамлагач, Чаллыга килә. Шәһәрдә яңа төзелешләр чоры. Кызны яшьлек романтикасы чолгап ала. Эштән арып-талып кайтса да, каләме белән хисләрен түгәргә җай таба. Шәһәрдә «Лэйсән» әдәби берләшмәсе барлыгын белеп алгач та, анда йөри башлый. Тик, тормышында сынаулар булып, иҗатын берара туктатып торырга туры килә. Хәер, аның каләме һәм зиһене тормыш фәлсәфәсендә үз фикерен җиткерергә «сүл туплап» торгандыр.

Үкенерлек түгел язмыш,
Бәхетлерәк куплардән.
Сыгылмый яшәр көч таптым
Тормыш салган йөкләрдән.

Бүгенге көндә Ә.Ситдыйкова поэзия һәм проза жанрларында уңышлы иҗат итә. Ф.Сафин «Офыгы киң, күге биек» мәкаләсендә аны «үз укучысын фикердәшенә әйләндерә алырлык серле шагыйрә» дип бәяләде. «Җанда кабынган учак» (2004, Яр Чаллы); «Утлы җимеш» (2011, ТКН);«Тансык бәхет»(2012, ТКН); «Яктылык сулышы» (2017, ТКН) җыентыкларында дөнья күргән һәм «Казан утлары», «Мәйдан», «Шоңкар», «Мәдәни җомга» кебек газета-журналларда даими басыла килгән лирик парчалары моңа инандыра.

Ә.Ситдыйкова поэзиясендә хис-тойгыларын җырлауда шәхси төсмерләр бар. Түбәндәге юлларда автор моны ул үзе бик ачык итеп гәүдәләндерә:

Үз максатым, үзем яулар үрем,
Үзем генә җырлар җырым бар.

Ә.Ситдыйкова тамырларының җир кешесенеке булуы белән чиксез горурлана һәм шуның белән үзен бәхетле саный:

Җирдә туып, җирдә үстем бит мин,
Җиргә бәйле бөтен язмышым.
Тамырларым илем туфрагында,
Тоеп яшим җирнең сулышын.

Лирик героеның хыял-омтылышлары гади җир кызыныкы: сөелеп-сөеп яшәү, туган җиргә, туган телгә мәхәббәтне, тугрылыкны саклау. Юкка гына халык шагыйре Р.Гаташ шагыйрәнең мәхәббәт лирикасын: «Син – халкың өчен тарихи әрнүләрне милли гамь касәсеннән даими эчеп тә, барыбер горур исемеңне саклап киләсең. Өстәвенә ир-атларның (шагыйрьләрне әйтүем) чуар йөрәген дә аңлап, хәтта аңа кушылып, бер җанга әверелеп, үз булып яши алу халәтенә ия бит син, Хауабыз таифәсе! Бу үзе үк, хатын-кыз дигән олуг затның матурлык белән бергә дөньяны саклау, яшәтү, дәвам итү миссиясе түгелмени?» – дип бәяләми.

Мәхәббәт лирикасында «мин» күңелендә мәңге бетмәс моң. Әмма лирик герой чын сөю барлыгына ышана, шушы хисне зурлый белә. Мәхәббәтендә югалтулар, хаталанулар булса да, ул бу хисләренә рәхмәтле. Чөнки күңеле нәкъ менә сөюдән илаһи бөеклеккә ашкына:

Хыял түгел, чынбарлыгым
Кутәрә бит өскә.
Сине күргәч аңладым мин –
Бәхет нинди төстә.

Шагыйрә кичерешләренең катлаулылыгын, нечкәлеген тормышчан, шушы хисләрдән туган ачык фикерләрен төгәл, нәфис сурәтләр белән җиткерә:

«Калдыр мине!» – диеп кабатлыймын,
Тыңларсың дип курка йөрәгем.

Ә.Ситдыйкова – көчле рухлы, максатчан шәхес. Ул югалтулар артыннан табышлар киләсенә ышана, өмет хисен сүндерми. Аның бу сыйфаты һәр әсәрендә чагылыш таба.

Абынсаң да, нык бул, егылма.
Егылсаң да,шундук торып бас!
Учак як та, аннан казан ас.
Соклансыннар күреп үзеңне.
Бәхет баскан чаклар була аз.
Көен җуйган чакта моңлы саз,
Капламасын болыт йөзеңне!

Көчле кешеләр холкына хас күркәм сыйфат бар. Ул – тормышта язмышына, хәтта аның бик үк уңайлы булмаган борылышларына да шөкер итү. Ә.Ситдыйкова үзенә насыйп булган язмышны рәхмәте белән кабул итә.

Рәхмәт, язмыш, каршылыклар белән
Сынайсың син минем ныклыкны.
Җиңелү һәм җиңү барын аңлап,
Чыныктырып яшим холыкны.

Язучының рухи ныклык, әхлак турында уйланулары, идеаллары татарның гасырлардан килгән яшәеш кануннарына корылган. Әсәрләрдә татар образлы фикерләвенә хас булган образ-детальләр килешле итеп урын ала. Мәсәлән, автор табигать сурәтләрен кичерешләренә ялгап җибәрү, киресенчә, хисләрне табигать сурәтләре белән тирәнәйтү алымын яратып куллана.

Мин сагынсам, болытларга карыйм,
Сәлам юллап синең тарафка...
Синнән килгән болыт эленеп калган
Өй янында үскән наратка.

Аның тәсләр поэтикасыннан файдалану осталыгы белән сокландыра.

Язмышына әгәр язган булса сагыш,
Яба вакыт сары яулык алсу йөзгә.
Күңел күген кукселәтеп, болыт йөзә,
Аваз сала кара төндә әрсез байгыш.

Ә.Ситдыйкова ишарәләп, кинаяләп язучылардан түгел. Әсәрләрендә күңел халәте, җан хәрәкәте нәкъ менә гадилек, тормышчанлык, ихласлык белән йөрәк түренә барып тоташа. Бәлки шуңадыр да, авторның байтак шигырьләре көйгә салынган, җыр булып яңгырый.

Шагыйрә буларак, Ә.Ситдыйкова поэма жанрында да уңышлы иҗат итә. Аның дистәдән артык поэмасы бар. «Язмышлар ярында», «Буталган язмышлар», «Кумер базы», «Өммегөлсем», «Хәсән Заманов» кебек әсәрләре чорның, катлаулы язмышларның шигъри тел белән язылган документаль бәяннары булып тора.

Авторның сәяхәтнамә итеп язылган әсәрләре дә бар. Аларда автор тынгысыз, эзләнүчән, кызыксынучан табигатьле зат буларак гәүдәләнеш ала. Авторга сәяхәтләр милли үзенчәлекләрне, тарихи үткәнне ныграк аңлау, гыйбрәт алу өчен бик тә файдалы, әмма:

Чит илләрдә кеше кунак кына,
Үз җиреңдә солтан, уйласаң.
Үз халкыңа, туган төбәгеңә
Кирәк булып яшәү – олы бәхет,
Әйләнгәндә дөнья-куласаң...

Язучы көннән-көн иҗат офыкларын киңәйтә, каләменең мөмкинлекләрен, ача, куәтен көчәйтә бара. 2019 елда аның күләмле тәүге проза әсәре – «Дөнья тәгәрмәче» повесте дөнья күрде. Аны укыгач, Ә.Ситдыйкова өчен шигърияттән прозага күчү дә берни тормагандыр сыман тәэсир кала. Сюжет вакыйгаларының тормышчанлыгы, документальлеге шуның белән аңлатыла. КАМАЗ тарихындагы байтак вакыйгаларның шаһиты булган һәм шуны күңеленә сеңдергән автор шул чор рухын төгәл җиткерә алган. Әсәрнең үзәк герое – Мәдинә, авторның үзе сыман, яшьлек чакыруына ияреп, зур төзелеш башланган шәһәргә килә. Автор бу образны барлык күңел байлыгын салып иҗат итә. Ул аңа зур идея – эстетик вазифа йөкли. Кеше хезмәттә үзенең асыл көчләрен тормышка ашыра. Геройның балачагы сурәтләреннән башлап, КАМАЗда хезмәт кую чорын тасвирлау шушы караш белән сугарылган. Шигъри җанлы, хыялый кыз үзе кебек уртак яшьлек дәрте белән янган егет-кызлар янәшәсендә тырышып хезмәт куя. Бөтен ил башлаган төзелешкә үз өлешен кертү белән чиксез горурлана. Ә.Ситдыйкова гади генә хезмәт процессын да шагыйранә матур итеп сурәтли.

Автор Мәдинә образы аша «кешене өмет һәм мәхәббәт яшәтә» дигән фикер сугара. Мәхәббәт – кешегә Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән иң зур бүләк ул. Яшь кеше ышанып шушы бәхетне көтә. Мәдинәгә әлеге серле хисне татырга насыйп була. Әмма дөнья тәгәрмәче тигез юлдан гына бармый шул. Мәдинәгә дә хыянәт ачысын татырга туры килә. Ләкин кыз бирешми. Калебенә иҗатлык сәләте салынган кыз үзен алда кызыклы язмыш көтүенә, иҗаты белән дөньяга сафлык, садәлек өләшеп, бәхетле булачагына ышана.

Мәдинәнең балаларына мәхәббәте, мөнәсәбәте бүгенге яшьләр өчен үрнәк. Мәдинәгә балаларын ялгыз үстерергә туры килә. Көчле ихтыярлы хатын аларны җил-яңгыр тидерми, үз канаты астында тәрбияли. Тормышның иң авыр вакытларында да рухи ныклыгын саклап калган Мәдинә укучы күңелендә соклану уята.

Ә.Ситдыйкова 2021 елда «Дингез суы тозлы ул» романын төгәлләде. Әсәрнең исеме идея йөкләмәсе белән тыгыз бәйләнешле итеп сайланган. Диңгез сәнгать дөньясында зурлыкны, олылыкны белдергән символ рәвешендә яңгырый. Әсәр нигездә дөньядагы барлык назны үз күңеленә сыйдырган, кешене җан җылысы белән йөрәкләрне җылытып яшәүче хатын кызларга багышланган. Романны ана мәхәббәтенә мәдхия, дип тә бәяләргә булыр иде. Әсәр биш кисәктән тора. Һәр кисәк бер гыйбрәтле вакыйга – хәлне бәян итә. Аларны гомуми тематика һәм идея берләштерә. Ана – кешелек дөньясын яшәтүче һәм яшәртүче зат. Аның күңеле тирән диңгез сыман. Баласының язмышында искән һәр җилгә диңгез сыман дулкынлана.

Китапта язмышлары бәян ителгән геройларның прототиплары бар, ләкин автор вакыйгаларны чынбарлык итеп кабул итмәүне үтенә. Геройлар – сәнгатьчә гомумиләштерелгән. Мондый язмышлы кешеләр һәр авылда бар.

Лилия ХӨСНЕТДИНОВА,
филология фәннәре кандидаты.

Әлфия СИТДЫЙКОВА

Ышанмадык ул чагында яшьлегебез үтәренә...

СӨЮ КАДЕРЕ

1

Син – язым! Син – назым! Кабыздың яшьлектә мәхәббәт учагын.
Син күрдең, син белдең, яндыргыч, көйдергеч ялкынлы ут чагым.

Ул учак сүнмәдә һаман да. Ялкыны үрләдә күкләргә.
Икәүләп кичергән ул хисләр, тойгылар бирелми күпләргә.

Талларда сайраган былбылым! Моңнарың үрелде гөлләргә.
Син булып атты да таңнарым, нур булып ялганды көннәргә.

Чәчәкле җәйләрем син булдың. Патшасы җиләкле җәйләрнең.
Ничә ел ял итте күңелем, үз итеп болының, җәйләвең.

Челләдә дым көткән чагында, яудың син беренче яңгырдай.
Ягымлы карашың күңелгә төнен дә нур сипте булып ай.

Назладың җил булып эсседә. Су булдың сусаган чагымда.
Туңганда «Җылын!» дип син миңа, юл ачтың җаныңа җай гына.

2

Мәкер юк, алдау юк арада. Манмадык көннәрне карага.
Хиссият диңгезен кичкәндә, чит-ятлар кермәде арага.

Ничә ел син диеп җан ату, мавыгу түгел ул, ярату.
Шик кертеп күңелләр түренә, булмады хисләрне каралту.

Кояшлы көннәрем күп булды. Йолдызлар яктыртты төнемне.
Гашыйклар көнләшеп күзәтте, чәчәккә күмелгән гөлемне.

Беркем дә өзәргә кыймады. Шау чәчәк бүген дә бакчамда.
Керерсең, күрерсең бар ямен, капкасын аз гына ачсам да.

Тик сиңа ачыла ул капка. Ятларга бикләдем keләсен.
Гел сине зарыгып көтәмен, беләмен яңадан киләсең.

3

Ничә ел үтсә дә исемдә. Тәү күргән мизгелем хәтердә.
Мин сине беренче күргәндәй, яратам икән бит хәзер дә.

Сөюнең кадерен беләм мин. Син миңа шулкадәр кадерле.
Йокысыз төннәрем яңарта, син – минле, мин синле хәтерне.

Син булдың таяныч һәм терәк, абынган чагымда ялгышып.
Сайрадың былбылдай өздереп, җанымда чайпалса сагышым.

Яшәргә көч-куәт өстәдең. Яңадан ачтың син төсләрне.
Яңарттың йөрәгем түрендә пыскыган, сүрелгән хисләрне.

Акладың, якладың, сатмадың. Тугры дус булдың син һәрвакыт.
Төбәдең карашың күземә, үз итеп, төз итеп, яратып.

Чагылдым мин синең күзләрдә, синең дә күзләрдә мин идем.
Акылың, асылың, талантың алдында түзмәдем, баш идем.

4

Ак булып, саф булып сакланды күңелдә самими хисләр дә.
Мин – сине, син мине сагындык, буранлы, давыллы кичләрдә.

Мин сиңа хыянәт итмәдем... Әрнетмә җанымны уй белән.
Мин бит ул караңгы төнеңдә яп-якты нур булып түгелгән.

«Бердәнбер!» – диясең, ышанам. Сөюне вакытлар сынады.
Ышанып яшәрлек көч бирә йөрәккә мәхәббәт сынавы.

Син – минсез, мин синсез бу дөнья кайгыдан каралыр шикелле.
Син барга, мин барга якты ул. Язлардай, кызлардай сөйкемле.

Тургайлар күкләрдә атынып, җыр суза мәхәббәт турында.
Син язган нотаны таныдым, тылсымлы табигать җырында.

Синең көй, минем көй яңгырый. Тургайлар ул көйне яңарткан.
Мин сине беренче күргәндәй хәзер дә өзелеп яратам.

ТОМАН

Син – яшь нарат, мин – яшь каен. Ап-ак томан күтәрелә.
Ышанмадык ул чагында яшьлегебез үтәренә.

Ак томаннар таралды да, озын юлга дәште еллар.
Сәфәр чыктык. Күзләр – күздә, аерылмады кулдан куллар.

Җилләр исте. Диңгез кичтек. Дулкын бәрде күңел-ярга.
Сизмәгәнбез юллар аеры. Син бер ярда, мин бер ярда.

Гомер үтә. Үкенечләр җан түрендә яши һаман.
Ялгыз нарат... Сары каен... Арабызда куе томан.

ШАУЛЫЙ ДИҢГЕЗ

Шаулый диңгез...
Җил өрәдер...
Җилкәнен киргән кораб!
Дәрдемәнд

Тормыш – диңгез. Диңгез шаулый. Дулкын кайный. Йөзә кораб.
Йомычкадай бөтерелә. Дулкын басса эшләр харап.

Мачта иңри. Шомландырып ыңгыраша, сулкылдый да.
Ә җил усал. Зур корабны бора уңга, бора сулга.

Кораб тулы халык өнсез. Курку баскан йөрәкләрне.
Дога укып ялваралар, исән калу теләкләре.

Шаулый диңгез. Кайный дулкын. Кораб йөзә. Диңгез кичә.
Дулкын белән өскә менә, дулкын белән аска төшә.

Котылырмы бу бәладән, батып калыр микән кораб.
Йомычкадай бөтерелеп йөзә кораб алга карап.

ҖАНГА ДӘШҮ

И нәзберек, нәфис җаным! Күпме яра яши синдә.
Күпме көннәр хыянәттән әйләнделәр кара төнгә.

«Кагылмагыз!» – дип дәшсәм дә, гел читләтеп үтмәделәр.
Кемнәр генә җилдәй исеп, тәрәзәмә чиртмәделәр.

Түздең ниләр хисабына? Бирешмәдең давылга да.
Яндың дөрләп, гайбәт сүзләр уктай килеп кадалганда.

Тыеп калдың ярсуларың, өермәгә әйләнмәдең.
Кыю җавап кайтардың син, телен өзеп бәйләнгәннең.

Шуңадырмы, бүген дә син яңа туган сабый кебек.
Горурланып керәсең син яңа көнгә балкып, көлеп.

АПРЕЛЬ БУЛЫП ЯШӘР ӨЧЕН

Апрель керә җанга өмет булып....
Наис Гамбәр

Апрель булып килгән идең миңа,
Өмет булып, мәңге сүнмәслек.
Агып киттең, язгы ташу судай,
Мин идемме өзелеп сөймәслек?!

Кояш булып яндым, күңел күгем
Балкып торсын, диеп, нурыннан.
Ул чакта бит дөнья яңгырады
Җанга тулган сөю җырыннан.

Кошлар кайтты һәр яз туган якка,
Канатлары юлда талгандыр.
Апрель булып килгән идең миңа...
Яратуың бәлки ялгандыр.

Китмәс идең мине ялгыз итеп.
Ташып ага сагыш елгасы.
Апрель булып яшәр өчен җирдә
Эх, яңадан җиргә туасы!!!

Ник калмадың минем янда, яшьлек?!.

КҮЗЛӘРЕҢ ЯКТЫСЫ

(Триптих)

I

Көн үтте, дөньяны бар иткән
Раббыга мең рәхмәт! Төн туды...
Күзләрең нур чәчеп яктыртты
Төн буйлап барачак юлымны.

Уйлыймын, көнгәме, төнгәме
Баш иеп әйтергә рәхмәтне.
Йолдызлар елмаеп эндәште:
«Табышу, кавышу рәхәтме?!»

Сулышың тойдым да бер минут
Шым калдым алалмый тынымны,
Күземнән түгелде энҗе яшь,
Чылатты, чылатты толымны.

Җаныма наз тулган мизгелдә
Әллә син, әллә төн үзгәрде.
Күк буйлап йөздә тик ай тулып,
Җиһанны һәм безне күзләде.

II

Ул көн үткәч, кинәт кояш сүнде,
Кайгысына түзә алмады.
Әле ярый син янымда идең,
Синең караш таңга ялгады.

Уйламаган идем, сөю көчең
Йолып алыр диеп упкыннан.
Кабат кабынып, яшәр өчен җирдә
Мин тормышка ныклап тотынам.

Таң сызылды, кояш чыкты балкып,
Йөрәк типте шашып, тилереп.
И Ходаем, сакла җан дустымны,
Йөртә күрмә, язмыш, тилмертеп.

III

Җырларыма күчкән яшьлек дәрте
Сүрелмәгән әле, сүнмәгән.
Ул чакларда күпме ялгышылган,
Күзләр әле күпне күрмәгән.

Ал хыяллар, татлы газаплардан
Өзелмәгән икән тавышым.
Рәхмәтлемен үткән елларыма,
Сиздермәгән гомер агышын.

Көзгә кергәч кенә аңладым мин
Яшәүләр шул булган лабаса.
Хәзер күрәм инде, аңлыйм барсын,
Үткәннәрне уйлап моң баса.

Яннан яшьнәп узып киткән яшь чак,
Кайтавазы исән күңелдә.
Җырларыма күчкән яшьлек дәрте
Яшәү көче өсти бүген дә.

«Бүгенгеләр аңламаса, киләчәк буынга калыр»

(Рафис Корбанның «Җидегәннән төшкән нур» романына бәяләмә)

2021 елда Рафис Корбанның Нәкый Исәнбәт турындагы «Җидегәннән төшкән нур» дигән романы дөнья күрде (Мәйдан, 2021, №9-11). Соңгы сүздә Р.Корбан әсәрдә Н.Исәнбәт тормышының 45 ел гомерен үз эченә алуы турында искәртә. Романны язганда, язучы «Җидегән» эше турында матбугатта басылган документаль материалларга, Н.Исәнбәтнең замандашларының хатирәләренә (Г.Ибраһимов, К.Нәҗми, Г.Кутуй, Г.Нигъмәти, С.Рәмиев, Һ.Такташ, Х.Туфан, Ф.Кәрим, Т.Ченәкәй) таянган. Дәверне мөмкин кадәр тулырак ачу өчен роман авторы татар язучыларының китапларын һәм татар галимнәренең хезмәтләрен файдалана (С.Хәким, Ә.Еники, Ф.Галимуллин, Ч. Зарипова-Четин). Романның үзәген Н.Исәнбәтнең хатыны – Гөлсемнең вафатына кадәр язып калдырган истәлекләре тәшкил итә (Нәкый Исәнбәт: фәнни-популяр җыентык. / Төз. М. Хәбетдинова – Казан: Җыен, 2021. 398–454 б.).

● Давыт Юлтый, Нәкый Исәнбәт, сукыр Фәррах һәм Ченәкәй. Уфа.

Әдәбият белгече Гомәр Даутов үзенең романга карата язган бәяләмәсендә Р.Корбан әсәрендә 1920 елларда иҗат иткән язучыларның образлары мәңгеләштерелгән дип билгеләп. Роман авторы аларның лакланган-шомартылган образларын түгел, ә борчу-хәсрәтләре, ният-омтылышлары булган тере образларын сурәтләгән (Даутов Г. Каләм фикер уята / Г.Даутов // Мәйдан. – 2022. – №2). Үз алдына укучыларның игътибарын җәлеп итү максатын куеп, Р.Корбан милләтнең бөек улларының биографиясендә булган «шикле» фактларны казып чыгармый, ә «гаепсездән гаепле» булып кала торган вәзгыятьтә, кемгә ышанырга белмәгәндә, психологик яктан үзенең геройларының эчке дөньясын ачарга омтыла, шулай ук XX гасырның беренче утыз еллыгында татар җәмгыятендә булган вакыйгаларның эчке механизмнарын документаль төгәллек белән аңлатырга тырыша.

Р.Корбан әсәрендә идея-әхлакый проблематика әйдәп бара. Язучы игътибарын шәхес башлангычына юнәлтә, аны персонажларының идея-әхлакый асылы кызыксындыра. Романчы буларак, Р.Корбанның игътибар үзәгендә кешенең тормышка карата позициясе һәм аның яшәү мәгънәсе, дөреслек һәм гаделлек, дуслык һәм хыянәт турындагы сорауларга җавап бирергә омтылышы тора. Романның баш героеның хакыйкате абруйга түгел, ә үзенең тормыш тәҗрибәсенә нигезләнә. Үзенең тормышка карата күзаллауларын, идея-әхлакый кыйммәтләрен булдырып, Р.Корбан романының герое шул рәвешле шәхси әхлакый җаваплылык мәсьәләсен дә хәл итә.

Роман авторы 1929 ел ахырында – 1930 ел ахырында «Татар пролетар язучылары ассоциациясе сафларын чистарту» кысаларында көчәеп киткән «Җидегән» эше буенча кампанияне җентекләп күзәтә (Сафа Бурган. К чистке ТАПП). «Җидегән» эше буенча кулга алыну турындагы хатирәләрендә Н.Исәнбәт 1930 еллар башына Татарстанда «эксплуататорлар сыйныфын юк итү» процессы киң колач алып, язучылар сафларын тар-мар итүгә дә әверелгән иде, дип яза. Әдәби тормыш «фронт» дип йөртелә башлый, РАПП, ТАПП (1928-1932) исә торган саен «хәрби штаб» статусын ала бара. Әлеге «чистарту»ларның «генералы» вазифасын җитәкчеләрнең берсе, халык алдында һәрвакыт бары тик хәрби киемдә генә күренгән Кави Нәҗмигә башкарырга туры килә. Трибуналардан ярсый-ярсый гаеп ташлаулар, халык алдында каргышлар яудыру, тәүбә итүләр модага керә... Ашык-пошык кына «дөньяны шаулаткан эшләр» оештырыла башлый... Чынлыкта исә, Н.Исәнбәт фикеренчә, әлеге процессларның максаты сәясилектән бигрәк, шәхси ихтыяҗларны канәгатьләндерүдән гыйбарәт була – карьера ясарга теләүче язучылар әдәби мәйданны көндәшләреннән – талантлы язучылардан «чистарткан» (Исәнбәт Н. Җидегәнчелектә гаепләнү елларым).

ТАССРда 1929 елда башланып киткән «Җидегәнчелек» эше, тикшерүчеләр тарафыннан «...бу эшчәнлек белән гаепләнүчеләрнең совет чынбарлыгы чикләрен узып киткән җинаять кылуларын раслаучы материаллар табылмау сәбәпле, 114819 номерлы эш тукталыла һәм кулга алынучылар азат ителә», дигән карар әле 1930 елда ук чыгарылган булса да, әзәрлекләүләр 1960 елларның урталарына кадәр дәвам итә. (Вәлиев Р. Болак арты республикасы. Казан: ТКН, 1999).

Р.Корбан романда ВКП(б) өлкә комитеты хезмәткәре Г.Касыймов, татар язучылары лидерлары Г.Ибраһимов һәм К.Нәҗми башында «туган» «Җидегәнчелек» эшенең ничек әвәләнүен, асылда сул эсерлар белән аларга каршы торучыларның шәхси исәп-хисапларын баналь рәвештә хәл итүгә әверелгән бернәрсә генә булуын ышандырырлык дәлилләр белән күрсәтеп бирә алган. Эш башта Казанда, аннары Мәскәүдә «җимерелә». Аны оештыручылар Н.Исәнбәтне дә, Г.Кутуйны да «үлем җәзасы»на илткән маддәгә китереп җиткерә алмый. Сорау алулар вакытында Н.Исәнбәтнең Уфада татар һәм башкорт язучыларының бер-берләренең әсәрләрен тугандаш республикаларда бастырып чыгару турында килешүләр алып барган табын артында сөйләшүләрдә катнашмавы билгеле була. Тикшерүчеләр шулай ук җиденче «җидегәнче»нең кем булуын да (Т.Ченәкәй, С.Кудаш, С.Агиш, Г.Кутуй, Н.Исәнбәт, Г.Минский) ачыклый алмый.

Романдагы «гаепсездән гаепләләр» вәзгыяте сәяси-иҗтимагый эчтәлек белән дә катлаулана. Р.Корбан сүз уңаеннан гына Г.Ибраһимовның, Г.Касыймовның электә сул эсерлар булуын искә төшереп үтә, шулай да бу мәсьәләдә артык тирәнгә кермәүне хуп күрә. Сул эсерлар крестьяннарның мәнфәгатьләрен кайгыртучы сәяси партия буларак, халыкчылык хәрәкәтеннән үсеп чыга, алар Россиядә самодержавиене бәреп төшерү өчен зур тырышлыклар куя, үзләренең программаларында идея ягыннан көндәшләренә каршы террор кулланугa юл куя. Н.Исәнбәт «толстойчы» буларак, җәмгыятьне кан коюю аша түгел, ә рухи үсеш аша үзгәртү яклы була. Аны шәхси этика идеяләре һәм шәхеснең үз-үзен камилләштерү бурычлары җәлеп итә, шуның өчен дә ул сул эсерларга һәм аларның эш ысулларына каршы тора. Р.Корбан романында баш геройның идея-әхлакый эзләнүләре аның үз «дөреслеге» белән чынбарлык фактларының һәм башка тормыш фәлсәфәләренең бәрелеше аша үтә.

Романның төп сюжет сызыгы Н.Исәнбәтнең язмыш сызыгы белән бәйле. Язучының тормыш иптәшенең хатирәләренә таянып, Р.Корбан энциклопедист галим гомер юлының беренче 45 елын тәфсилләп сурәтли. Роман авторы Н.Исәнбәтнең педагог, фольклорчы, шагыйрь, драматург, җәмәгать эшлеклесе буларак эшчәнлеген детальләрдә күрсәтеп бирә алган. Р.Корбан 1930 елларда дошман элементлары белән сәяси каршылыкларның гаилә мөнәсәбәтләренә тискәре йогынтысын психологик төгәллек белән күрсәтә. Әтисе Сиражетдин Закировның мулла булуы сәбәпле, Н.Исәнбәт әтисе белән араларын өзәргә мәҗбүр була. Г.Исәнбәт хатирәләре нигезендә Н.Исәнбәтнең әтисенең образын торгызып, Р.Корбан укучыларның игътибарын Сиражетдин мулланың Россиядәге иң танылган мөселман дине әһелләренең берсе Зәйнулла ишан Рәсүли (1833-1917) шәкерте булуына юнәлтә. Әмма остазыннан аермалы буларак, Нәкый Исәнбәтнең әтисе ишан булып, мәхәллә кешеләре хисабына яшәүгә үзенең имана җирендә тир түгеп, кибетендә сату итеп дөнья көтүне хуп күрә.

Сиражетдин мулла Малаяз авылы мәхәлләсен җитәкләгән һәм авылдашлары аны нык хөрмәт иткән (Нәкый Исәнбәт: фәнни-популяр җыентык. / Төз. М. Хәбетдинова – Казан: Җыен, 2021). Р.Корбан язучының әтисе образын тасвирлаганда, игътибарны Сиражетдин мулланың милли мәсьәләләрдәге фикерләренә юнәлтә (шагыйрь М.Гафуриның милләтенә кагылышлы бәхәсне карагыз) (Мәйдан. – 2021. –№10). Н.Исәнбәтнең иҗади башлангычларына төрле яклап теләктәшлек белдереп торган энисе Таибә абыстай роман авторының игътибарыннан читтә калган. Күрәсең, Р.Корбан Н.Исәнбәтнең «Бәби чак» дигән автобиографик повестенның материалын игътибарсыз калдырган (Исәнбәт Н. Бәби чак // Мирас. 1999. № 1; 2000. № 1). Романда Н.Исәнбәт

тугрылыклы ир, күпбалалы гаилә башлыгы, яраткан әти итеп тасвирлана. Роман авторы Н.Исәнбәтнең иҗади эшчәнлегенең нәтиҗәләрен сурәтләүгә зур игътибар бирә. Р.Корбан «Һиҗрәт», «Портфель», «Миркәй белән Айсылу» драма әсәрләренең, авторны кулга алуга, әдәбияттан читләштерүгә, әсәрләрен бастыруны тыюга кадәр китереп җиткергән «яңгыравык кампанияләр»не китереп чыгарган «Идегәй» дастанының җыелма текстының, «Татар балалар фольклоры», «Татар халык табышмаклары» җыентыкларының язылу тарихларын торгыза. Р.Корбан 1941 елның августында Мәскәүдә узарга тиеш булган, ләкин Бөек Ватан сугышы башлану сәбәпле узмый калган Татар сәнгате декадасына әзерлек вакытында Н.Исәнбәтнең ролен тарихи төгәллек белән күрсәтә. Роман авторы Н.Исәнбәтнең Бөек Ватан сугышы алдыннан һәм сугыш вакытында язган әсәрләрнең («Идегәй», «Хуҗа Насретдин», «Түләк», «Мәрьям»,«Җирән Чичән белән Карачәч Сылу», «Нур Зәһит», «Гөлҗамал») гаять катлаулы сәхнә язмышы турында уйлана.

Н.Исәнбәт образы романда режиссёр Мәкәрим Мәһәдиев, язучылар Кави Нәҗми, Гадел Кутуй, әдәбият галиме Габдрахман Сәгъди белән дуслык һәм иҗади элемтәләрен тасвирлау аша аеруча нык ачыла. Документаль төгәллеккә ирешү өчен, Р.Корбан романга ТАПП сафларына керү өмете белән Г.Нигъмәти кушуы буенча Т.Ченәкәйнең «Идарәгә ачык хат»ы текстын тулысы белән кертеп җибәрә (Мәйдан. – 2021. –№10). Хат «Җидегән» эшен башлап җибәрү өчен сәбәп була. Романчы интриганнарның оста кулы белән язучыларның дусларының да шушы ятьмәгә килеп эләгүен күрсәтә. «Җидегән»нең псевдоэгъзалары «фаш итүчеләр» сафларында Һ.Такташ, Ф.Кәрим, Х.Туфаннарның булуына шакката. Р.Корбан үзенең текстына ул шагыйрьләрнең фаш итү максатыннан язылган шигырьләрен дә кертә (Ф.Кәрим «Җыен сатана», Һ.Такташ «Бозык телефон») (Мәйдан. 2021. –№10). Безгә мәгълүм булганча, төрмәдән чыгу белән, Н.Исәнбәт Һ.Такташның фатирына килә, әмма сөйләшү килеп чыкмый, чөнки язучылар икесе дә әлеге хәлләрнең фаҗигале нәтиҗәләреннән коты алынган хәлдә була (Исәнбәт Н. Һади Такташ // Һади Такташ : фәнни-популяр җыентык / Төз. Лена Гайнанова. – Казан: Җыен фонды, 2020).

Р.Корбан әдәби төркемнәр арасындагы көрәш тарихындагы «ак таплар»ны бетерергә омтыла, шуңа да Н.Исәнбәт белән Г.Ибраһимов, Н.Исәнбәт белән Г.Касыймов арасындагы каршылыкның алшартларын җентекле тасвирлый. Г.Ибраһимов белән Г.Касыймов Уфадагы сул эсерларның актив әгъзалары була, аларның эшчәнлегендәге террорчыл ысулларны Н.Исәнбәт «толстойчы» буларак кабул итми. Аның ышанычына, элекке эсерлар Казанга килгәч, «төсләрен үзгәртергә» мәҗбүр булып, большевикка әйләнсә дә, асылда карашларын тамырдан үзгәртмәгән һәм репрессия елларында яңгыравыклы процесслар оештыруда террорга һәвәслекләрен кулланган һәм тиздән үзләре дә шуның корбаннары булган. Р.Корбан әдәби мәйдан тоткан лидерларның – персонажларның диалогларын аларның газеталардагы чыгышларына таянып, бизәкләр кертмичә генә торгыза. Г.Даутов белән килешеп, без дә шуны әйтәбез: Р.Корбан хәзерге заманның 1920-1930 елгы сәяси чынбарлыктан ераклашкан укучыларын чиркану тудырмас өчен әлеге чыгышларның риторикасын «шомартып» биргән (Даутов Г. Каләм фикер уята // Мәйдан. 2022. №2).

Роман авторы язучылар мохитендәге «халык дошманнары» белән көрәшкә әйләнеп киткән иҗтимагый шашыну, истерияне, җәмгыятьне биләп алган куркү атмосферасын җентекләп тасвирлый. Р.Корбан Н.Исәнбәтнең танышлары һәм дуслары даирәсенең тараюын чынбарлыктагыча итеп сурәтли. Язучы милли интеллигенциянең дистәләрчә вәкиленең төрле ярлыклар тагылган язмышын кыскача гына атап уза: «фабрикант улы», «мулла малае», «җидегәнче», «милләтче», «панисламист»... Әсәрдә Т.Ченәкәй, Г.Кутуй һәм агалы-энеле Сәгъдиләрнең язмышы җентекле сурәтләнә, аларның язмышының фаҗигале еллары Н.Исәнбәт биографиясенә дә күләгә булып төшә. Романда милләтнең СССРдагы сыйнфый көрәш һәм репрессияләрнең корбаннары булган дистәләрчә талантлы улларының исемнәре телгә алына. Аларның һәркайсы үзенчә кемнең дус, кемнең дошман икәнен ачыкларга тырыша. Аларның барысы да җәдитчеләр чорында фикердәшләр булган, яшь вакытларында мәгърифәтчелек идеаллары белән мавыккан, гомерләрен татар халкына хезмәт итүгә багышларга карар иткән. Г.Сәгъди романның ахырында үз буынының җәмгыять алдында нинди гаебе барлыгын аңлый алмый азаплана, ни өчен бу җәмгыять бик күпләрнең гомерләрен кыйды, бик күпләрне газапларга дучар итте дигән сорауларга җавап эзли. Нәкый Исәнбәт якташы булган бу галимнең сүзләренә җавап итеп болай ди: «Гомерем әрәм үтә дип уйламыйм. ...Бүгенгеләр аңламаса, киләчәк буыннар өчен калыр» (Мәйдан. – 2021. –№9).

Миләүшә ХӘБЕТДИНОВА,
әдәбият белгече.

Әйтем-тәгъбирләр энциклопедиясе

«Патшалар дуамаллыгы халыкка һәрчак михнәт китерә» – Гораций егерме гасыр элек әйтелгән бу канатлы гыйбарә, башка бик күп шундый затлы сүзтезмәләр кебек, бүген дә актуаль түгелме? Бүген дә аерым дәүләт җитәкчеләре, тынычлыкта яшисе, дөньяны нурлырак, камилрәк итәргә тырышасы урында, аны яңадан бүлгәләргә ашкынмыймы, планетаны берничә кат юкка чыгарырлык атом коралы хәстәрләнмәгәнме? Хәстәрләнгән. Чөнки бүгенге патшалар да вакыт тузанга әйләндерәчәк матди кыйммәтләр өчен тарткалаша, сүзнең, акыллы фикернең бәясен белми, танымый. Ни кызганыч, Платон хыялланган «Философлар - патша, патшалар - фәлсәфәче» булган заманнар җитмәде шул әле...



Платоннан башлап, узган гасыр акыл ияләренә кадәр тупланган гыйлем, фикер, тормыш тәҗрибәсенең күләме ифрат та зур. Үткән өч мең ел эчендә җыелып килгәнне үзләштереп бетерү мөмкин дә түгел. Мәгълүмат, фикер дигәндә, гади кеше дә, гыйлем ияләре дә күп язарга, күп сөйләргә гадәтләнгән. Гәрчә «Күп сүз – чүп сүз» диелсә дә. Галимнәр раславынча, кеше, колагы ишеткәннең бары яртысын гына эләктереп ала, эләктергәннең барысын да аңламый, аңлаганның бик аз өлешен генә исендә калдыра. Чөнки күпчелек очракларда фикердә тыгызлык, үтемлелек, мәгънә җитенкерәми, аңа канат куелмаган. Ләкин бу хәл кагыйдә түгел, чөнки фикернең асылы, үтә дә төгәле, хәтергә уелу үзлегенә ия булганнары да күп. Нәкъ шундый гыйбарәләрне, сүзләрне без канатлы дип әйтәбез дә инде. Нәкъ менә канат үскәнгә алар аңлаешлы гына түгел, тәэсирле, җанлы һәм дә шул сәбәпле озын гомерле. Берничә сүздән торган лаконик җөмлә, әһәмияте, фикер сыешлыгы буенча дистә, хәтта йөз кәлимәне алыштыра да буыннан буынга күчә, башка телләргә, халыкларга тарала, китапларда, матбугатта кабатлана, яшәешебезне мәгънәлерәк, яктырак итә.

Канатлы сүзләрне өйрәнүче, системага салучы, популярлаштыручы, хикмәтле гыйбарәләрнең татар әдәбиятында, вакытлы матбугатта кулланылышын җентекләп барлап чыгып, хәтсез китаплар бастырган Илгизәр абый Гыйззәтуллин минем тормышка үзенең Казанда, «Заман» нәшриятында 2020 елда чыккан академик басмага тиң затлы китабы аша килеп керде. Бауман урамындагы элекке Матбугат йорты бинасына урнашкан китап кибетенә эш арасында кыска гына вакытка сугылып, ул елны шуннан «эләктереп» чыккан бердәнбер китап булды ул. Эләктерми ни, канатлы кәлимәләргә багышланган татарча басманы беренче очратуым иң. Хикмәтле сүзләргә беркайчан да битараф булмаган кешегә чын табыш булды ул. Овруцкий дигән авторның «Канатлы латин әйтемнәре» («Крылатые латинские выражения») китабын узган гасырның сиксәненче еллар азагында, язу эшенә әле якын да килмәгән вакытта «сөреп» чыкканнан бирле төрле авторлардан калып, яшәешебезнең асылын ачуга дәгъва иткән һәм дә ачкан канатлы сүзләргә мәхәббәтнең сүрелгәне булмады. Үзем эшләгән «Ватаным Татарстан» газетасында, шунда чыккан язмаларда да теләп кулландым аларны. Әдәби әсәрләр язганда да әйтәсе килгәнне шундый тәгъбирләр белән көчәйткән чаклар булды. Һәм менә килеп Илгизәр абый төзегән татарча басма, татарча канатлы сүзләр дә урын алган саллы китап. Ул инде хәзер өстәл китабым дәрәҗәсендә.



2020 елгы ул уникаль басма дигәндә, анда урын алган дүрт йөзләп канатлы тәгъбирнең башта һәрберсенең килеп чыгышы кыскача аңлатылган, авторы әйтелгән. Аннан соң курсив шрифт белән татар шагыйрь, язучылары, публицист, журналистлар тарафыннан ул сүзтезмәләрне куллануга мисаллар, үрнәкләр китерелгән. Илгизәр Гыйззәтуллин төзегән, һәммәсе дә бер исем белән «Канатлы сүзләр» дип аталган башка китапларның да архитектурасы шундый кимәлдә. Сүзнең кадерен белгән, сөйләмен, телен баетасы килгәннәргә китапларның зарурлыгы, файдасы бәхәссез. Ә инде каләм иясе өчен, бигрәк тә дөньяның, кеше затының асылын аңларга тырышып язганнар өчен ул хезмәтләр чын бер хәзинә дияр идем. Кешелек гасырлар буе туплап, җыеп килгән кыска, ләкин ифрат та оста әйтелгән сүзләрдән дә саллырак гыйбарәләрне язу эшендәге кеше ул басмалардан алмыйча, каян алсын, ничек күңеленә салсын, исендә тотсын? «Китап – белем чишмәсе» дисәләр дә һәр китап та кешегә белем бирми бит. Канатлы сүзләр үзләре дә, аларны бәйләм-бәйләм итеп туплаган ул җыентыклар да - чып-чын гыйлем чыганагы. Алар үзләренә рухи, әхлакый байлыкны, гасырлар акылын шундый күләмдә сеңдергән ки, әйтеп, аңлатып бетерерлек түгел.

Чираттагы җыентыкка килгәндә исә.......

«Заман» һәм «Матбугат йорты» нәшриятында чыккан китаплардан аермалы буларак, җирле матбагаларда дөнья күргән калган китапларның кечкенә тиражларына игътибар иткәннән соң, без хикмәтле сүзләрне, аны татар телендә төзүче фидакяр кешене бәяләп бетермибез дигән фикер дә ярала. Инде шактый өлкән яшьтәге тыңгысыз Илгизәр абый китапны җентекләп төзеп кенә калмый, аны үз хәләл акчасына чыгара да бит әле. Шул рәвешле ул милләтне күтәрә, каләм әһелләре – язучы, журналистлар даими күз уңында тотар, файдаланыр басмалар тудыра. Чөнки ул, укып белүемчә, татарда гына түгел, бөтен төрки дөньяда канатлы сүзләрдән торган сүзлекләр төзегән чын, кабатланмас мәгърифәтче.

Наил ШӘРИФУЛЛИН,
журналист.

Солтан ШӘМСИ

Идегәй мирзаның шанлы көннәре

Тәхетеннән куылганнан соң Алтын Урда ханы Туктамышның Литва кенәзе Витовт канаты астына кереп сыенуы, аның белән сүз берләшеп, Алтын Урдага каршы яулар оештыруы Идегәй мирза өчен җитди бер мәсьәләгә әверелә. Бу вакытта кырык җиденче яше белән барган Идегәй мирза (1352 дә туган) язмышының иң биек баскычына күтәрелә. Аның кискен борылышлар, канкойгыч бәрелешләрдә узган гомере, максатына ирешү өчен тәхет тирәсендә фетнәләр оештыру, кирәк чакта аркадашлар табып, кирәге беткәч, алар белән араны өзә белүе, күп еллар ят җирләрдә яшәве – барысы да хакимиятнең иң югары баскычына күтәрелү, Алтын Урда тәхетенә Күк Урданың Тимермәлик хан белән апасының улы Тимер Котлыкны куеп, аның исеменнән ил белән идарә итү өчен эшләнә. Инде барысына да ирештем, татар дәүләтенә хуҗа булдым дигәндә генә Литва кенәзе Витовт һәм тәхеттән куылган Туктамыш хан аның бәхетен тартып алмакчы. Аңа бит хәзер сугыш-орышларсыз гына яшисе, Аксак Тимер яуларыннан соң имгәтелгән татар дәүләтен торгызу, ныгыту, тормышны көйләү белән шөгыльләнәсе иде. Ул үзе дә сугышлардан, кан коюлардан тәмам туйды, инде сакалы чаларды, иллегә җитеп килә. Әмма, язмыштан узмыш юк, күрәсең. Адәм баласы тәкъдирендә язылганның барысын да кичерергә тиештер...

Туктамыш хан Идегәй мирзаның илне ныгыту буенча ясаган һәр адымын көнләшеп һәм үчегеп барлап тора. Туган һәр көн дошманының хакимиятен ныгыта баруын һәм, киресенчә, аның өчен тәхетне кайтарып алу ихтималын киметә төшүен ул эчтән кимерелеп, хафага төшеп күзәтә. Көннәрдән бер көнне, түземе төкәнеп, ул кенәз Витовт белән ныклап торып сөйләшү өчен Вильно (Вильнюс) каласына чыгып китә. Аның күңелендә мәгълүм бер уй-ният тәгаенләнеп, ул аны кенәз Витовтка түкмәкче була.

Күрешкәч ул аңа уйлаганын ачып сала:

– Бөек кенәз! Синең өчен сер түгелдер – Ходайның һәр бирмеш көне Идегәйнең көчен-куәтен арттыра, хакимиятен ныгыта. Ул инде Урдада үзен чын хуҗаларча тота, иркенәеп китеп эш йөртә, гәрчә тәхетенә Тимер Котлыкны утырткан булып кыланса да... Әйдә, берләшик, ярдәм ит миңа...

Бу сүзләрне әйткәндә Туктамыш ханның йөзенә күксел тимгелләр бәреп чыкты. Моны кенәз Витовт та күреп алды, эчтән генә: «Тәхеттән куылган хан хәлендә калырга язмасын», – дип уйлап куйды, тик йөзенә чыгармады.

– Кодрәтле хан! – диде ул, Туктамыш ханны юатып.– Сиңа мәгълүмдер – тәре йөртүчеләр, Ливон ордены белән мөнәсәбәтем шактый катлаулы. Аннан соң Новгород белән Мәскәү мәсьәләсе дә хәл ителеп бетмәгән. Бу очракта ашыгу кирәк микән? Миңа ике тарафта сугыш алып бару авырга туры киләчәк.

– Узган ел бит Донга чаклы җиттек, күпме ганимәт малы, даладан терлек-туар куып алып кайттык. Берләшеп эш итсәк, безне беркем туктата да, җиңә дә алмаячак...

– Узган елгы яу бер җилләнеп кайту гына булды. Чынлап тотынсаң, сугыш озакка сузылачак, көч күп кирәк булачак.

Туктамыш хан, аның икеләнеп торуыннан файдаланып, соңгы дәлилен китерергә булды, шуның белән Литва кенәзен ризалаштырырга өметләнде:

– Бөек кенәз! – дип кабатлады ул, аннан дусларча елмаеп, үз итеп. – Кадерле Витовт! Әйдә без синең белән шундый килешү төзик. Мин сиңа бик тә әйбәт шартлар тәкъдим итәм.

Кенәзнең кашлары өскә сикереп, дуганалып алды:

– Нинди?

– Әгәр дә миңа тәхетемне кайтарырга ярдәм итсәң, Алтын Урданы үзара бүлешербез. Мәскәү кенәзлеге, Новгород, Псков, шуңа өстәп Тверь белән Рязань синеке булыр. Ә инде Сарай белән Хаҗитарханны, Азакны, Болгарны, Иделдән көнчыгышта яткан далаларны мин үземә калдырырмын. Риза бул. Бәхетеңнән баш тартма...

Ачыктан-ачык әйткәндә, Туктамыш ханның тәкъдиме Витовт үзе уйлаганнан да кызыклырак һәм отышлырак булып чыга түгелме? Эш болайга киткәч, бәлки, чыннан да, бу зур уенны башларгадыр? Туктамыш тәхетеннән куылса да, аның хан исемен берәү дә тартып алмаган. Санап чыгылган олыслар, калалар барыбер аныкы санала, тарафдарлары күп. Зур көч туплап, сугышны уңышлы тәмамласалар – күпме җирләр Литва кенәзлегенә килеп кушылачак. Ә бу байлык, кодрәт, шөһрәт дигән сүз. Җавап бирмичә торган арада кенәз Витовт шуларны уйлап алды.

– Ярый, – диде ул, Туктамыш ханга кулын сузып. – Тәкъдимең бик кызыклы. Кабул итәм.

Әлеге карар кенәз Витовтның планнарын үзгәртте, ул зур яуга әзерлек чаралары күрде. Польша короленә һәм Ливон орденына мөрәҗәгать итте. Польша короле Ягайло, кенәз Витовт сораган күләмдә үк бирмәсә дә, аңа хәрби көч белән ярдәм итәргә булды. Ливон рыцарьларын үз ягына аудару өчен, Витовт аларга Жемудь кабиләләре яшәгән җирләрне бүләк итте, шуның бәрабәренә булачак яуда тимердән киенгән рыцарьлар да катнашырга тиеш иде.

Бу хәзерлекләрне Мәскәү кенәзе, кенәз Витовтның кияве Василий Дмитриевич та бик шомланып күзәтте. Әле 1395 елда ук кенәз Витовт киявеннән Смоленскины тартып алган иде. Дөрес, Смоленскины турыдан-туры Мәскәү җирләренә кертә дип әйтеп булмый, әмма барыбер Литваның һаман киңәя баруы аны нык борчый иде. Аннан каенатасының Новгородка күзе кызуы да аны бик нык борчый. Хатыны Софьядан ишетүенә караганда, узган ел (1398) Ливон рыцарьлары катнашында Новгород белән Псковка яу йөрергә килешкән булганнар. Яу уңышлы чыкса, Новгород – каенатасы Витовтка, Псков – немец рыцарьларына калачак икән.

Әмма Туктамыш хан белән килешү төзү кенәз Витовтның планнарын үзгәртте, аның каршында тагын да зуррак мөмкинлекләр ачылды.

Идегәй мирза да Литвада «шөһрәтле качак» рәвешендә яшәгән Туктамыш ханның хәрәкәтләрен борчылып күзәтте. Тәхетне кайтарып алу өчен аның Витовтны яуга тартырга омтылачагы Идегәй мирза өчен ачык иде. Әмма кайчан? Яу көтмәгәндә башланмасмы? Аны менә нәрсә борчый иде.

Якын арада зур сугыш алып барасы килми иде Идегәй мирзаның. Хәзер аңа илне ныгыту өчен тыныч еллар кирәк. Әмма теләсә-теләмәсә дә, гаскәр туплый башларга, яуга әзер торырга булды ул. Шул ният белән тәхеткә утыртылган Тимер Котлык ханга урдасын Литва чикләренә, Днепр тирәсенәрәк күчерергә киңәш итте, чөнки дошман ил әченә үтеп керсә, көрәшү кыенга туры киләчәк.

Кенәз Витовтның зур яуга әзерләнүен белеп торса да, Идегәй мирза бер чара кулланып, аны сынап карарга булды – аңа хат юллап, шул хатта Туктамыш ханны үзенә кайтаруны таләп итте. «Качкын Туктамышны миңа кайтар, ул – минем дошманым. Аның исән-сау килеш синдә яшәп ятуы тормышымның ямен ала, кәефемне боза», – диелгән иде ул хатта.

Әлбәттә, Идегәй мирза бер каптырмалы затлардан түгел, кенәз Витовтның Туктамыш ханны бирмәячәген белеп тора, андый эшне үзе дә хупламаган булыр иде. Бу дошманны сынап карау гына иде. Кем белә, бәлки, күрше мәмләкәттән шундый хат килгәч, Литва кенәзе ханга ярдәмнән баш тартыр...

Бераз көттереп булса да, Литвадан җавап килде. Аны китергән чапкынны тиз арада бәкләрбәк Идегәй мирза каршына китереп бастырдылар. Ул түкми-чәчми кенәз Витовтның сүзләрен тапшырды: «Мин сиңа Туктамыш ханны бирмәячәкмен, Тимер Котлык хан белән үзем күреп сөйләшергә телим», – дип, аны санга сукмыйча җавап бирде кенәз Витовт.

Җавапның Идегәй мирзаны кимсетү өчен махсус җибәрелгәне ап-ачык иде. Татар дәүләтендә хан син түгел, Тимер Котлык, кая кысыласың, дигән фикер анда ярылып ята иде. Мондый тупас җавап сугыш игълан итүгә тиң. Шулай Литва кенәзе, Алтын Урдага китереп сугарга җыенуын сиздереп, Аксак Тимер яуларыннан соң һаман аякка баса алмаган мәмләкәтегездә миңа, Литваның олуг кенәзе, Кейстут углы Витовтка каршы торырлык көч бармы соң, дигән тәкәббер сорау да куя сыман.

2

Кенәз Витовт яуга чынлап әзерләнә башлады. Аның үз гаскәренә Туктамыш хан татарлары, көньяк рус кенәзлекләре полклары, поляклар һәм тәре йөртүче Ливон ордены рыцарьлары да өстәлде. Шулай йөз мең чамасы гаскәр тупланды. Заманның соңгы казанышлары кимәлендә коралланган бу гаскәрдә хәтта махсус тупчылар бүлеге дә бар иде. Шуңа күрә кенәз Витовт сугышның җиңү белән тәмамланасына нык ышана, шушы көч белән татар илен яулап алырга җыена иде.

Менә яу татар даласына таба кузгалды. Сугыш кирәк-ярагы, азык-төлек төягән олаулар әллә ничә чакрымга сузылды. Алар тиз бара алмый, шуңа гаскәргә дә акрын хәрәкәт итәргә туры килә. Бераздан хәл ачыкланды – татарлар Днепрның сул кушылдыгы саналган Бурсыклы елгасы буенда (рус чыганакларында Ворскла дип атала) тора, Тимер Котлык хан урдасы шунда урнашкан. Тик дошман татарларның төп көчләре Идел-Азак буенда, Идегәй мирза кулында булуын, монда исә Тимер Котлык ханның берничә төмәне генә торуын белми иде. Белсә, бәлки, килә-килешкә орышка да кергән булыр иде.

Дошман явы якынлашкан саен Тимер Котлык хан урдасында хәвеф арта, төмән башларының да, гади сугышчыларның да йөзе караңгылана барды. Ни өчен дигәндә, хәбәргәрләр китереп торган хәбәрләр бер дә өметкә урын калдырмый – дошман бихисап зур көч белән килә, шушы көч күңелләргә шом сала. Менә кенәз Витовт явының маңгай полклары Бурсыклыга килеп үк туктады, ә арттан килүче гаскәрнең иге-чиге күренми.

Шулай өч көн буе Бурсыклы ярына дошман явы агылды. Дүртенче көнгә киткәч, Тимер Котлык хан иртән иртүк, калкурак бер төшкә менеп, дошман ягына күз салды һәм шунда йөрәге «жу» итеп куйды, тәнендә салкын тир бәреп чыкты. Ул төмән башлары белән бәкләрне, әмирләрне ашыгыч киңәшмәгә җыярга боерды.

(Дәвамы киләсе санда).



Гомер озынлыгына бәрабәр эшләр

Җитлеккән тәнкыйть – нык үскән әдәбиятның юлдашы. Ул үсешнең аеруча үрчемле вакытында гына үзенең барлыгын сиздерә. Татар әдәбиятына мөнәсәбәттә бу ХХ йөз башына, бөек Г.Тукаебыз «Тәнкыйть – кирәкле шәйдер!» дип чаң суккан вакытка туры килде. Җ.Вәлиди нәкъ шушы елларда тәнкыйть мәйданына чыкты. Театр сәнгатен булдыру өлкәсендә хәрәкәт барлыкка килү Г.Кәрамнең каләменә йөгереклелек өстәде. Г.Исхакый, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов кебек әдипләребез дә бу хакта уйланмый кала алмады. Егерменче-утызынчы елларда Г.Сәгъди, Г.Нигъмәти, Г.Гали, Г.Рәхим, Г.Толымбайлар үзәккә чыкты. Утызынчы елларга таба М.Гайнуллин, Х.Госман, Г.Кашшаф, З.Искужин, М.Мамин, Г.Халит, Х.Хәйри кебекләр пәйда булды. Аларның байтагы шәхескә табыну елларында һәлак ителде. Алтмышынчы-җитмешенче елларда Н.Юзиев, И.Нуруллин, А.Сайганов, М.Җәләлиева, Р. Мостафин, Ф.Мусин, Ф.Хатипов, Ф.Миңнуллиннар әлеге өлкәдә үзәк урында торды.

Шундыйларның берсе Рифат Хәсән улы Сверигин иде. Берничә көннән аңа 90 яшь тула. Бу очракта «сөбханалла» дип әйтәсе килә. Бу яшькә килеп җиткәннәр бар-барын, әмма һәм саулык-сәламәтлек белән, һәм иҗади халәттә әлеге чикне атлап чыгучылар шактый сирәк була. Бәхеткә, чордашыбыз, каләмдәшебез һәм хезмәттәшебез Р.Сверигин әнә шулардан.

Моннан дүрт ел элек Кукмара районының Ядегәр мәктәбендә республикакүләм конференциядә булдык. Юлдашым Рифат Сверигин иде. Аңа мөнәсәбәт бик хөрмәтле, хәтта аеруча җылы кебек тоелды. Моның сере тиз мәгълүм булды. Рифат Хәсән улы илленче еллар ахырында, әле 27 яшендә, биредә мәктәп директоры булып эшләгән икән. Бу хакта мәктәп музее белән танышканда белдек. Баксаң, әлеге мәктәп мәчет бинасында урнашкан булган. Мондый бинада тулы канлы белем һәм тәрбия бирү мөмкинлекләре булмый. Яшь чак, тәвәккәл вакыт, Р.Сверигин тота да Мәскәүгә китә (мәсьәләне Татарстанда гына хәл итеп булмас дигәнме?), ил башкаласындагы мәгариф министрлыгындагы җитәкчеләрне шушы авылда яңа мәктәп төзергә кирәклегенә ышандыра һәм 224 укучыга исәпләнгән мәктәп бинасын төзү өчен проект та алып кайта. Инде Аксубай районының Иске Ибрай авылында алман телен, Кукмара районының Ош-Юмья мәктәбендә рус телен укытып, кешеләр белән аралашуда күпмедер тәҗрибә туплаган, чатнатып төрле телләрдә сөйләшә белүе дә тәэсир итми калмагандыр, аның гозеренә уңай караш белдерәләр. Әмма сүз белән мәктәп төзеп булмый, чиновникларның бюрократия киртәләренә бәрелеп, бу эш хыял гына булып кала.

Шуңа борчылып йөргән көннәрдә, туган авылы Байлар Сабасына кайткач, Рифат яшьтәше Азат Әхмәдуллинны очрата. Ул, университетны тәмамлагач, ике ел Тубыл педагогика институтында укытып кайтканнан соң, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалында эшли һәм аспирантурада укый икән. Сабакташының сөмсере коелуын күреп, Азат Гыйльмулла улы шундый киңәш бирә.

– Мин эшли торган институтта аспирантлар кабул итү башлана. Син ул мәктәбеңдә картайганчы, институтка урнашып, фәнни эзләнүләр, һәртөрле ачышлар, әдәби тәҗрибәләр ясасаң, яхшырак булмасмы?.. Сиңа Гали Халит җитәкчелегендәге әдәбият секторына керергә кирәк. Имтиханнар өч фәннән: татар әдәбияты – монысын шиксез бишкә бирәчәксең, икенчесе – марксизм фәне, тагын чит тел – алман теле, анысы үзеңнеке инде. Син бит Иске Ибрай немецы...

Р.Сверигин, имтиханнарны уңышлы узып, аспирантурага кабул ителә, аңа җитәкче итеп, чыннан да, Гали ага Халитне билгелиләр. Әдәбият белеме өлкәсендәге абруйлы галим карамагына эләгү бер яктан зур җаваплылык, икенче яктан мондый зат белән эзләнүләр алып бару арка терәгеңнең нык булачагы турында да сөйли. Ул инде сине юлда ярты-йорты хәлдә калдырмас. Шулай булып чыга да. Алар, озакка сузмыйча, бергәләп кандидатлык диссертациясенең темасын билгели – «Фатих Хөсни һәм аның прозадагы осталыгы» һәм, җиң сызганып, эшкә керешәләр.

Бу еллар турында Р.Сверигин болай искә ала:

– Диссертацияне мин бик яратып һәм үз-үземә ышанып эшләдем, чөнки җитәкчемнең киңәшләрен, юл күрсәтүен тоеп тордым. Нәтиҗәдә әдип турында китабым, татар һәм рус телләрендә күпсанлы мәкаләләрем басылып чыкты, диссертациям дә уңышлы якланды. Шулай итеп, әдәбият фәне, әдәби тәнкыйть өлкәсенә кулымнан тотып кертүчем Гали абый Халитов булды.

Галим кешегә диссертация яклау белән эш бетми. Син инде үзеңнең алдагы эшчәнлегең белән шушы фәнни дәрәҗәңне көннән-көнгә, елдан-елга чарларга, тагын да югарырак кимәлдә үстерә барырга тиеш. Ул елларда милли рухыбыз гаме белән яшәүче галимнәребез М.Гайнуллин, Г.Халит, М.Хәсәнов, Н.Юзиев, Ф.Мусин, Ш.Абилов, Р.Гайнанов, Н.Гыйззәтуллин һ.б. татар әдәбиятының күп томлы тарихын язу мәсьәләсен күтәреп чыга, зур хезмәтнең план-проспектын да төзиләр. Ул А.Әхмәдуллин редакторлыгында басылып та чыга. Г.Ибраһимов исемендәге институт галимнәренә тагын университетта һәм педагогика институтларында эшләүче зыялыларыбыз да өстәлә. Аларга да, аерым чорлар, авторлар турында язу өчен, темалар бүлеп бирелә. Шул уңайдан Р. Сверигинга да өлеш чыгаралар. Дөрес, ул 1972 елда Казан педагогика институтына күчә. Әмма бу әлеге эшкә комачаулык тудырмый. Әлеге томнарда аның Ф.Хөсни, Ә.Еники, А.Гыйләҗев иҗатларына багышланган мәкаләләре, ул төзегән әдәби хроника урын алды.

Мин аны Казан пединститутында эшли башлаганнан бирле, ягъни нәкъ илле ел беләм икән. Аны биредә бик тиз үз иттеләр. Бик ипле, җыйнак, төгәл, фәнен яхшы белә. Лекцияләрендә, кемнәрдер кебек, фәнни терминнар артына яшеренеп, галимлеген күрсәтү өчен, ясалма рәвештә катлауландырып сөйләми, мөмкин кадәр аңлаешлы, гади бәян итә. Безнең мөнәсәбәтләрне якынайткан тагын бер нәрсә – ул да булса укыта торган курсларыбыз булды. Ул вакытта факультетның уку планында милли мәктәпләрдә укытачак кадрларны әзерләгәндә җирле шартларны исәпкә алып кертелгән бүлек бар иде (аны 2007 елда гамәлдән чыгарулары укытучы кадрларны әзерләүне бик авыр хәлдә калдырды). Менә шул план буенча без булачак рус теле һәм әдәбияты укытучыларына да татар теле һәм әдәбияты буенча шактый төпле белем бирә идек. Татар мәктәпләрендә рус теле һәм әдәбияты укытучысы булачак студентларга Рифат Хәсән улы татар әдәбияты дәресләрен бирде. Рус сүз сәнгатен яхшы белүе өстенә бу телдә камил сөйләшүе аңа абруй яуларга ярдәм итте. Тагын шунысы бар: мин эшләгән ТРО, ягъни татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты белгече булачак студентларга «Татар һәм рус әдәбиятлары бәйләнешләре» дигән күләме буенча зур курс бар иде. Лекцияләре 70, гамәли дәресләре 40 сәгать. Аны элек Абдулла Сайганов дигән зур галимебез укыткан. Кызганыч, ул вафат булды. Әлеге курсны алып баруны миңа тапшырдылар. Эшне башлап җибәргәндә, Р.Сверигинның ярдәмен шактый тойдым.

Моннан тыш Рифат Хәсән улы егерменче гасыр әдәбиятыбызны татар бүлегендә укытты. Зур галимә, күренекле укытучыбыз Мәдинә Шәйхи кызы Җәләлиева белән берлектә әлеге бик тә бай, катлаулы курсны алар күп еллар бергәләп алып барды. Мәдинә апабыз бакыйлыкка күчкәч, бу очракта да безгә Р.Х. Сверигин белән коллегалар булырга туры килде.

Кафедрабыз даими рәвештә «Гыйльми язмалар» дигән җыентык бастырып килде. Р.Сверигин аның һәр чыгарылышында яңача фикерләүгә, әдәби әсәрләргә үзенә хас булган алымнар белән бәяләүгә нигезләнгән мәкаләләр белән катнашты. «Характер һәм психологик дөреслек», «Хәзерге татар прозасында әдәби стиль үзенчәлекләре мәсьәләсе», «Кави Нәҗми хикәяләрен өйрәнү тәҗрибәсеннән» һ.б. мәкаләләре үз вакыты өчен яңа карашларны яктыртулары белән отышлы иде. Ул аларның кайберләрен 1985 елда «Яңа герой һәм яңа алымнар» исемле китабына да урнаштырды. Анда Г.Бәширов, Ә.Еники, Ф. Хөсни, Р.Төхфәтуллин, А.Расих иҗатлары шактый җентекле һәм фәнни яктан нигезле итеп тикшерелә, алар иҗатының төп хасиятләре ачыла. Шул ук вакытта Р. Сверигин җанлы татар әдәбиятының йөрәк тибешен дә күзәтеп яшәде. Аның М.Юныс, Ә.Баян, В.Имамов, А.Хәлим, Ф.Бәйрәмова, Ф.Садриев, Н.Гыйматдинова, Н. Хәсәнов, Ә.Гаффар һ.б. иҗатларына карата матбугатта, язучыларның ел йомгакларында ясаган чыгышлары игътибар белән каршы алына килә. Чөнки алар вакытлы тәэсирләргә бирелеп, сәяси таләпләргә туры китереп түгел, бәлки ныклы эстетик өйрәнүләргә, фәнни табышларга, дөреслеккә инанып ясалган нәтиҗәләрдән гыйбарәт була. Аның шәкертләреннән берсе, күренекле галим Әлфәт Закирҗанов аңа багышланган мәкаләсен юкка гына «Таләпчән тәнкыйтьче» дип атамагандыр (Казан утлары.2012. № 8).

Шушы әдәбиятчыбыз, 70 яшенә якынлашып килүенә карамастан, Язучылар берлеге әгъзасы булмаган икән. Мин моны шушы иҗат оешмасына җитәкче итеп сайлангач кына белдем һәм идарә утырышында әлеге гаделсезлеккә чик куярга кирәклеген әйттем. 2000 елда Рифат абыебыз да кесәсенә язучы булуын раслаган билетын салды. Шуннан соң аның иҗат активлыгы да арта төште. Кешегә җылы сүз әйтелүе, уңай караш белдерелүе бик тә кирәк шул. Әмма ул сүз, Г.Тукаебыз әйтмешли, «мөддәте тулганда пешкәч, кызаргач һәм матур булгач, җитешкәч», ягъни үз вакытында әйтелсә яхшы була.

Р.Сверигинның гомер буена тугрылык саклаган тагын бер шөгыле бар, ул да булса – спортка мәхәббәт. Аның һәрвакыт хәрәкәттә булуы сокландыра да, гаҗәпләндерә дә. Ул әле чаңгы ярышында, әле йөгерешчеләр арасында. Җитмешенче елларда ул берничә тапкыр Казан-Кокушкино арасында марафон чабышларында катнашты, хәтта илле чакрым арага да йөгерде. Шуңа күрә ул бүген дә сафта, тәне дә, фикер йөртүе дә сәламәт. Алга таба да шундый ук матур гомер насыйп булсын.

Фоат ГАЛИМУЛЛИН,
КФУ профессоры.

Мәдәни җомга
29 июль
№29, 2022

● Риваятьләрдән калыккан Акбүзатка һәйкәл.

●Без Собханкул авылы янындагы кыя өстендә.

ШҮЛГӘН-ТАШ

Башкортстанга июнь ахырында ясаган сәяхәтебезнең иң күңелле һәм мавыктыргыч өлешен язмый калдыру гөнаһ. Әүвәл Бәхтияр Канкаев ватанын, бунтарь Зәки Вәлидине дөньяга биргән Ишембайдагы Көзән авылын күрүне төп максат итсәк тә, шәхсән үзебез өчен дә бер бүләк ясыйсы килә иде. Башкортстанда инде 70 елга якын яңгыраган, соңгы чорда аның йөзек кашына әверелеп килгән тагын бер табигый һәйкәл – бер Рәсәйне генә түгел, хәзер инде барча Европаны соклandырган бөек Шүлгән-Таш мәгарәсе дә бар бит әле! Аның хакында дистә еллар буе ишетеп яшибез, аны күргән бәхетлеләр авызыннан ишетеп көнләшәбез, ә без-бичаракайларның шуны барып манзара кылганы юк, шуңа күрә әлеге сәяхәттә Шүлгән-Ташны күреп кайту үзебез өчен дә олы бүләк булыр, дип билгеләгән идек. Бик интексәк, аңа илтә торган юлны үзебез дә эзләп таба ала идек, ләкин Өфө каласында безнең якын дустыбыз – «Шоңкар» журналының баш мөхәррире, соңгы еллардагы башкорт әдәбиятының иң өметле вәкиле Айгиз Баймөхәммәтов та бар бит әле. Азамат егет белән алдан ук сүз беркеткән идек. Инзер каласының «Урал» кунакханәсе каршында очраштык та, «аның арбасында» юлга кузгалдык без.

Белорет районы буенча Бөрҗәнгә йөз тотып барабыз. Белорет – Башкортстандагы иң зур район, аның мәйданы Чечен республикасына тиң. Ике якны да әле таш кыялар, әле мәһабәт урман каплаган тарлавыклар аша алга ашыгабыз. Ара-тирә урманнар ачыла да, астагы инеш-елгалар буена сыенган авыллар тезелешеп кала. Адым саен диярлек кисәтү язулары: «Атлар көтүе килеп чыгуы мөмкин, сак булыгыз!» Озак көттермичә, чыннан да, юл читендәге иңкүлекләрдә «башкорт» атларыннан хасил табуннарның утлап йөргәне күренә. Соңгы елларда ут күршеләр «башкорт» токымлы атлар үрчетү белән бик нык мавыга шул, Уфадагы төп ипподромда атна саен 6-7 районнан килгән командалар узыша. Аңа өстәп, һәр районда диярлек кымыз ясау остаханәләре, димәк, махсус фермалар бар. Ә без, гадәттәгечә, «башкорт атларының тарихка кергәне юк, Бату хан яуларында да, Алтын Урда чорында да кешелек фәкать татар атларын гына танып белгән!» – дип күкрәк суккан булабыз, әмма Татарстанда бүген сыңар кымыз фермасын көндез чыра яндырып эзләсәң дә, табып булмый. Без әнә шундый «булдырабызлар» токымыннан гына...

Айгизебезнең ятимнәр йортында үскән егет икәнен белә идек инде. Тау итәкләренә җәелеп урнашкан зур гына бер авыл уртасына житкәч, ул үзенең машинасын «Заһир Исмәгыйлов исемендәге социаль-мәдәни үзәк» дигән язмасы да булган сокландыргыч бина алдына китереп туктады. Без дә аның янәшәсендә урын алдык.

– Менә, мин үскән Сәрмән авылы шушы була инде. Тик үзем тәрбияләнгән ятимнәр йортын гына илтеп күрсәтә алмыйм, аны биш-алты ел элек ябып өлгерделәр.

Мәдәният сараена иңгәч, җирле үзидарә башлыгы Гаетбай агай Әюпов белән дә, китапханәчеләр, мәдәният хезмәткәрләре белән дә гәпләшеп алдык. Аннары район үзәкләрендә корылган мирасханәләрдән һич тә кайтыш булмаган музей белән таныша башлагач, Сәрмән авылы үзенең тиңсез тарихы белән таң калдырды.

Шушы сыңар авыл 1920-1930 еллар үрендә Башкортстан өчен сәламәтлек саклау министры Кинҗәбай Ишмөхәммәтовны, мәгариф министры Ибраһим Абызбаевны, азык-төлек һәм игенчелек министры Шаһиәхмәт Даутовны үстереп биргән. Ни кызганыч, НКВД җәлладлары кузгаткан «кызыл террор» башлангач, 1937 елда өчесен дә атып үтергәннәр... Безнең Айгиз Баймөхәммәтов та тәрбияләнгән ятимнәр йортында СССРның халык артисты дәрәҗәсенә ирешкән, «Салават Юлаев» фильмында төп рольне башкарган Арслан Мөбарәков та үсеп чыккан. Шушы ук Сәрмән башкорт халкына атаклы композитор, СССРның халык артисты, дистә еллар буена Композиторлар берлеген, Уфадагы сәнгать

●З.Исмәгыйлов кызы Ләйлә белән. Уфа, 2000 ел.

●Уфада Заһир Исмәгыйловка куелган һәйкәл.

институтын җитәкләгән Заһир Исмәгыйловны да үстереп биргән. Әле үзләре китеп барса да, җеп очлары барыбер югалмаган, Арслан әфәндене кызы – балерина Гөлия дә РСФСРның халык артисты исемен яулаган, Заһир аганың кызы Ләйлә бүген үзе этисе нигезләгән сәнгать институтын җитәкли... Ун ел буе Башкорт дәүләт университеты ректоры булып торган Мөхәммәт Харрасов та – шушы Сәрмәннеке. Саналганнар янәшәсендә беркадәр күләгәдә калган, әмма үз заманасының маяклары булган дистәләгән талант... Шаккатудан баш чайкамый һич тә мөмкин түгел. Үзебезне никадәр генә күккә чөймик яисә күкрәк сукмыйк, безнең Татарстанда букадәр талантлар үстереп бирә алган бер генә авыл да юк бит...

Инде алга таба кузгалган гына идек, 5-6 чакрымнан соң ук Айгиз янә юл читенә туктап урын алды.

– Менә монысы 1556 елда чаңгылар көйгән көе Казанга барып, Явыз Иван калдырып киткән наместник каршына тезләнгән һәм бөрҗән ыруы исеменнән башкорт халкының үз теләге белән Рәсәйгә кушылуы турында игълан иткән Шагали Шыкман авылы була. Кабере сакланган, өстендә һәйкәл дә бар. Кереп карыйсызмы?

Мин фәкыйрегезнең янга борылып төкерүен шәйләгәч, сүзсез генә алга тәгәрәдек. Юлда әле «дөньяда иң тынычлык сөюче халык» килеп төзегән «Изгеләр чишмәләре» булуын, аларның кайберләре өстенә хәтта «гөнаһларыңны юып, изгеләндереп» чыгара торган бассейннар корылып куелуын һәм аның ише юк-барлар турында телгә алып тормыйм. Безне иң мөһиме – табигать сокландыра һәм аны манзара кылудан туктап булмый иде.

Бөрҗән районы – Башкортстанның йөрәгедер кебек. Дүрттән өч өлешен искиткеч урманнар каплаган төбәк әкиятләрдәге бакча төсле. Анда йөзьяшәр нарат һәм карагайлар гаскәре, арада балан, шомырт, миләш. Аланлыкларын каплаган зәп-зәңгәр, ямь-яшел, сап-сары, җете кызыл чәчәкләренең матурлыгын иң оста рәссамнар да сурәтли алмас сыман. Җитмәсә, районны әллә ничә кишәрлеккә бүләргә ашыккандай, юлда һаман елан төсле булып, Агыйдел боргалана. Ләкин Ходай Тәгаләнең, юмартланып, күлләрне дә вак көзгеләр яисә көмеш тәңкәләр сыман сибеп үткән урыннары да бар. Елкычыккан дигән күле халык хәтеренә ингән әллә ничә риваять белән дә истәлекле. Аларда әкиятләрдәге канатлы акбүзат та шушы күлдән күтәрелгән, диләр. Хак-

●Собханкул авылының Агыйдел ярындагы биек кыя өстеннән күренеше.



МӘГАРӘСЕ

●Башкортстанның мәгариф министры булган И.Абызбаев.

●Сәламәтлек саклау министры К.Ишмөхәммәтов.

● Без мәгарә эчендә.



●Мәгарә эчендәге дивардан А.Рюмин күчереп ясаган борынгы рәсемнәрнең берсе.

●Азык-төлек һәм игенчелек министры Ш.Даутов.

●СССРның халык артисты А.Мөбәрәков.

тыр да. Әнә бит, Уфа каласында яшәүче архитектор Өлфәт Кобагышов шушы күл ярына Акбүзатны гәүдәләндерүче гаҗәеп ат һәйкәлен дә корып койган. Йә, Ходаем, мондый ат һәйкәлләре нишләп Татарстанда юк соң?!.

Бөрҗән районының үзәге Собханкул авылы урнашкан һәм Агыйдел елгасы әле дугаланып, әле көянтәдәй сузылып аккан табигать почмагы да гаҗәеп сокландыргыч. Елга аша таш күпер дә, асылмалы зур басма да төзеп куйганнар. Собханкул урамнары гаҗәеп тыгыз урнашкан булуга карамастан, һәр тарафта һаман өр-яңа йортлар төзиләр. Иң шәбе шул – район үзәгендә хәтта ике катлы таш биналар да юк. Һәммәсе гади, кабатланмас, барысы да үзләренчә, тегеннән өлкән агай фәрманы белән каккаланган түгел. Мондагы хуҗалыкларның аяк очында ук Урал кыялары, иллә мәгәр барыбер дә, шушы кысанлыкта да кәҗә-сыер, ат һәм каз-үрдәк тотарга да җаен табалар бит...

Ниһаять, без риваять итеп сөйләнелә торган Шүлгән-Таш тыюлыгында. Агыйдел яры буенда ул 22500 гектар мәйдан били. Тыюлыкны фәкать борынгы мәгарә эченә генә сәяхәт, дип күзаллау һич тә дөрес түгел. Бу урын элек гасырларда башкорт халкының чолыкчылык белән шөгыльләнү үзәге дә булган. Шуңа күрә тыюлыкның байтак мәйданында элеккеге чолыкчылык үрнәкләре, бу шөгыльгә багышланган махсус музей да бар. Алар янәшәсендә үк палеолит чорында яшәгән кешеләрнең борынгы тирмәләре, ау кораллары, бик оста сынчы тарафыннан тудырылган агач мамонт сыны. Шушы ханәләрне узгач кына, кунакларны инде мәгарә тарихына багышланган музейда каршылыйлар. Гәрчә мәгарә берничә гасыр элек үк билгеле булса да, фронтовик-зоолог А.Рюмин фәкать 1958 елда гына аның берничә бүлмә диварларында борынгы кешеләр охра белән ясаган сурәтләр күреп ала. Радиоуглеводород тикшерүләр үткәргәч, мәгарә диварларындагы рәсемнәрнең 14-17 мең еллар элек үк ясалган булуын ачыклыйлар. Бактың исә, моннан да «картрак» рәсемнәр фәкать Франциянең бер мәгарәсендә генә сакланган, Шүлгән-Таш исә үзенең тарихи тирәнлеге буенча икенче урынны яулап тора икән.

Мәгарәнең эче искиткеч зур, меңәр квадрат метр. Ул өч яруста, ягъни югарылыкта урнашкан. Мәгарәнең эчке озынлыгы өч мең метрдан арта, ләкин аның беренче ярусын манзара итүдән ары үтеп булмый. Мәгарә астыннан сузылган җир асты елгасының озынлыгы гына да сигез мең метрдан арта һәм ул нәкъ мәгарә авызында җир өстенә бәреп чыга. Шушы урында дайверлар 80 метр тирәнлеккә төшеп караган, тагын да тирәнрәк чуму да мөмкин, әмма хәвефле, ди. Ә без, фәкыйрьләрегез, мәгарә эченә 120 метр чамасы эчкә керә, аннары 20 метр тирәсе өскә күтәрелеп, кире төшә алдык. Икенче, өченче ярусларына туристларны үткәрмиләр, кеше гомере өчен куркыныч.

Мәгарәнең эче шактый салкын булса да, һич тә өшемәдек. Безне хыялга ирешү шатлыгы да, Айгиз Баймөхәммәтов кебек башкорт әдәбиятчылары белән дуслык та җылытты. Ә Шүлгән-Ташка янә барасы килеп тора...

Вахит ИМАМОВ.
Автор фотолары.

«Ак калфак» Бөтендөнья татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасының Мамадыш районында «Тарихны язмыйлар күкләрдә, языла яшәгән җирләрдә» исеме астында ике көнлек күчмә утырышы үтте. Аңа җиде чит илдән, Россиянең 40 төбәгеннән һәм Татарстанның 41 шәһәр-районыннан 200 гә якын ханым килгән иде. Утырыш-семинар Кече Сон авылында «Яруллиннар скверы»н ачу тантанасы белән башланды.

Тарихны язмыйлар

ЯРУЛЛИННАР БАКЧАСЫ

Татарстанның Мамадыш районындагы җыйнак авылы Кече Сон халкыбызга өч мәшһүр композиторны – Заһидулла, Фәрит, Мирсәет Яруллиннарны биргән. Заһидулла Яруллин татар музыка дөньясына кыллы оркестрны кертсә, улы Фәрит Яруллин татар халкына беренче опера «Шүрәле»не язып калдырган. Мирсәет Яруллин беренче оратория авторы буларак мәгълүм.

З.Яруллинны халкыбыз аеруча «Тукай маршы» аша белә. Бөек шагыйрь һәм композиторның язмышында уртаклыклар шактый. Әйтик, Заһидулла да 5 яшеннән тома ятим кала, төрле гаиләләрдә тәрбияләнә. Ул да 10 яшеннән дөнья гизә башлый, Чистай, Сембер, Уфа, Самара, Оренбург шәһәрләрендә булырга өлгерә, 1908 елны Казанга килә. Бу вакытта аңа 20 яшь була. Егет Казанның «Болгар» номерларында Тукай белән дә еш очраша, Салих Сәйдәшев, Фатих Әмирхан, Шиһап Әхмәров, Солтан Габәши кебек зыялыларыбыз белән аралаша. Заһидулланың Тукай вафатын да бик авыр кичерүе истәлекләрдә сакланып калган.

Аңлашыла ки, Кече Сонда Заһидуллиннар туып-үскән салам түбәле йорт күптән инде юкка чыккан. 1993-1996 елларда ул нигездә махсус корылган бинада Яруллиннар музее урнашкан була. Ни кызганыч, бу йорт янган, бик күп кадерле әйберләр юкка чыккан. Шуннан соң бирегә берни дә төземәгәннәр.

Авыл җирлеге башлыгы Мансур Сәләхов искәрткәнчә, тормышта бер генә вакыйга да, очрашу да очраклы булмый. Яңа гына эшли башлаган җитәкченең кулына Татарстанның халык артисты, Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге Татарстан Дәүләт бүләге лауреаты Мирсәет Яруллинга багышланган юка гына брошюра да юкка гына килеп эләкмәгәндер. Анда композитор Интертат.ру хәбәрчесенә биргән интервьюсында Кече Сонда үзләренең нигезе калмавын, авылга кайтканда аны пар каен гына каршы алуын, хәзер аларның йорты урынында алабута, кычыткан үсүен, музей торгызу турында күпме генә сүзләр алып барса да, ышандырулар гына ишетүен әйтә. Бу зар Мансур аганың күңеленә кереп утыра. Аннан соң 2016 елда авылда Яруллиннарга багышланган музей да ачыла, төп нигезләрендә исә алар исемендәге сквер булдыру турында да карар кабул ителә.

Шушы көннәрдә Заһидулла, Фәрит, Мирсәет Яруллиннар туып-үскән өй биләмәсендә «Яруллиннар скверы»н ачу тантанасы булды. Бәйрәмнең иң хөрмәтле кунагы исә Мирсәет Яруллинның хатыны Луиза ханым иде. Тантанада «Ак калфак» оешмасы әгъзалары, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары, Бөтендөнья Татар конгрессының Чаллы бүлеге җитәкчесе Факил Сафин, «Мәйдан» журналының бүлек редакторы Лилия Гыйбадуллина, шагыйрь Рафаэль Газизов, язучы Нәзифә Кәримова һ.б. әдипләребез, танылган композитор Эльмир Низамов, күренекле җырчы Мингол Галиев, район җитәкчеләре һәм авыл халкы катнашты.

Сквер беренче карашка ук ямьле, җанга тынычлык бирә торган рәхәт бакча булып хәтердә калды. Аның уртасына скрипка ачкычы рәвешендә ак вак таш җәелгән, тирәләре чәчәкләр, куаклар белән ямьләндерелгән. Бакчаны «Нота станы», «Композиторларның иҗат башлангычы» дигән конструкцияләр бизи. Соңгы корылма өч өлештән тора. Уртада Заһидулла Яруллин, аның ике ягында - ике улы. Анда - гади авыл тормышы. Кергән вакытта колонналар рәвешендә ясалган капка исә Яруллиннар иҗатының яшәвен, мәңгелек булуын белдерә. Бакчаның бизәлеше Чаллыда яшәүче кылкаләм остасы, Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы Александр Рученин иҗаты булса, аны Мамадыш районының төзелеш буенча бүлек башлыгы Фирдинант Әмиров җитәкчелегендәге бригада эшләгән.

Яруллиннар скверын ачу уңаеннан авылның «Васыйл чишмәсе» янында «Тамгалы чиләк», «Йолдыз күрсәтү», миллек бәйләү, җиләк җыю, дару үләннәре җыю кебек халкыбызның йолалары белән бәйле фольклор тамашалары да тәкъдим ителде.

Кунакларны Яруллиннар музее белән аның директоры Дания Хәбибуллина таныштырды. Хәтер мәгарәсе тарихи йортта - мәдрәсә бинасында урнашкан. Уку йортының тамырлары исә 1740 елга барып тоташа. Мәдрәсәдә заманында Чистай, Чаллы, Мамадыш, Спас якларыннан, күрше авыллардан килеп 300 дән артык шәкерт белем ала. Музейга килеп кергәч, Таҗетдин Ялчыгол рәсеменә дә күз төшә. Ул әтисе белән хаҗдан кайтканда, Ялчыгол хәзрәт вафат була. Шуннан соң Таҗетдин шушы мәдрәсәдә өч ел балаларга белем бирә. 1870 елда агач мәдрәсә яна, 1898 елда аның урынына таш бина салына һәм анда революциягә кадәр балаларга дини белем бирелә, аннары бинада (1970 елга кадәр) башлангыч мәктәп урнаша. Шушы мәдрәсәне тәмамлаган Миннегали Гыйльманов башта мәдрәсәдә, соңрак мәктәптә укыта. Әмма тора-бара бина җимерелеп юкка чыгу хәленә килә. 2014 елда грант отып һәм авыл халкы ярдәме белән мәдрәсә бинасын тулысынча яңарталар һәм анда музей коралар.

Билгеле ки, музейның төп өлеше Заһидулла, Фәрит, Мирсәет Яруллиннарга багышланган. Заһидулла абый ишле гаиләдә дөньяга килә. Әтисе шахтага китеп юкка чыга, әнисе авыру була. Ул да, биш яшьлек Заһидулланы тома ятим калдырып, бу дөньядан үтә. Бала апасының һәм авылдашларының гаиләләрендә 10 яшькә кадәр үсә, аннары аны Чистайга алып китәләр. Әйтүләренчә, Заһидулланы музыка кораллары көйләүче петербурглы немец И.Шнейдер үзенә йомышчы малай итеп алган. Әлбәттә, ул баланың музыкага сәләтен дә күргәндер, югыйсә, аны нота танырга, фортепианода уйнарга һәм музыка коралларын көйләргә өйрәтмәс иде. Музейда Заһидулла абыйның авылдашы Исмәгыйль абыйга һәм оныгы Наилә ханымга ясап бүләк иткән гармуннары саклана. Соңгысын Наилә апа, үзе авырый башлагач, бабайның туган ягында саклансын дип, бүләк итеп җибәргән. Аны журналист Фидаил Мәҗитов алып кайтып биргән. Заһидулла абыйның өеннән килгән радио да кызыксыну уята. Ә иң кадерле әйберләрнең берсе, мөгаен, Заһидулла абыйның 1960 елда Мирсәет абыйга язган хатыдыр. Ул анда улыннан үзенә гармуннар ясау өчен аның почмакларына куя торган кирәкярак алып кайтырга сораган.

Музейда шулай ук Фәрит Яруллинның истәлеге – аның җирләнгән урыныннан - Белоруссиядән кайткан туфрак та тәэсирләндерә. Аны композиторның Белоруссиядә бюсты ачылганда алып кайтканнар.

1941 август аенда «Шүрәле» балеты Мәскәүдә куелырга тиеш була, әмма 22 июньдә Бөек Ватан сугышы башлана, Фәрит Яруллин яу кырына ил азатлыгын сакларга китә. Татарстаннан бары тик ике композитор гына фронтта кулына корал тотып ут эчендә сугыша. Мамадыш төбәкне өйрәнү музее фәнни хезмәткәре Гөләндәм Давыдова Мирсәет Яруллинның бүгенге көнгә килеп җиткән хатының бер почмагында аның үз теләге белән сугышка китүе, бер кешене дә гаепләмәскә үтенгән сүзләре дә саклануын искә төшерә. Әмма композитор 1943 елда Белоруссия җирләрендә һәлак була. Аның җирләнгән урынын Белоруссиядә яшәгән милләттәшләребез табып, исемен Дубровный шәһәренең музыка мәктәбе янында һәйкәл торгызып мәңгеләштереп, аны карап тора (Эльвира Якшевич һәм Маргарита Якшевич Яруллиннар скверын ачу тантанасына да кайткан иде). Музыка мәктәбенә дә Фәрит Яруллин исеме бирелгән.

Халкыбыз Ф.Яруллинны онытмый. Бүгенге көндә Мамадыш хакимияте, төбәкне өйрәнүчеләре һәм музейчылары, журналистлары Белоруссия белән тыгыз элемтә урнаштырган. Ел саен июнь аенда Ф.Яруллин исемендәге фестиваль үткән көннәрдә композиторның каберен зиярат кылырга, аңа чәчәкләр салып хөрмәт күрсәтергә зур делегация барып кайта. Ф.Яруллинның бюсты шулай ук Мамадыш шәһәренең үзәк мәйданында да куелган. Каһарман композиторга Мамадышның үзәк мәйданында яңа һәйкәл дә төзү буенча эш башланган. Ф.Яруллинның, 1958 елда Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге булдырылганнан

күкләрдә

соң аның иң беренче лауреаты булуын да хәтерлибез. «Шүрәле» балеты исә Мәскәүдә 1945 елның март аенда барыбер куела. Н.Караченцевның әнисе сценарийны язуда катнаша. Мая Плисецкая Сөембикә ролен башкара. «Тормыш үзгәрә.1941 август аенда куеласы «Шүрәле» балеты белән бүгенгесе арасында аермалыклар күп», – ди Мамадыш төбәкне өйрәнү музее фәнни хезмәткәре Г. Давыдова.

Музейда Мирсәет ага Яруллинның костюмы, аккордеоны, пианиносы, фотоаппараты, аңа халык артисты исеме бирелү турындагы таныклыгы, медальләре, фотолары - кадерле истәлекләрдән. Мирсәет ага аларның беришен үзе бирсә, икенчеләрен, авырый башлагач, алып китүләрен сораган. Кунаклар авыл кешеләренең киңәшчесенә, ярдәмчесенә, өлкәннәрнең кайгыртучысына әверелгән җирлек башлыгы Мансур Сәләхов тәкъдиме белән сугыш һәм тыл ветераннарына багышлап торгызылган һәйкәл белән дә танышты.

КИРМӘН ҖЫЕНЫ

Кирмәнчек тә, X–XI гасырларда барлыкка килгән Болгар, Биләр, Сувар һәм Кашан шәһәрләре кебек үк, бай тарихка ия. Алтын Урда чорында 1395, 1399 еллардагы рус елъязмаларында телгә алынган Кирмәнчек шәһәрчеген рус ушкуйниклары Новгородтан Идел, Нократ елгалары буйлап төшеп яндыра. Кирмән шуннан соң тулысынча хәлләнеп китә алмаган, ди тарихчылар. Әмма галимнәребез, язма чыганаклардагы мәгълүматларга нигезләнеп XIV гасыр ахырында Кирмәннең әле яшәгәнлеген дә әйтә. Археологлар шәһәр булган урыннарны казып эзләнү эшләре алып барган, биредә болгарлар яшәвен, шулай ук фин-угор халыклары да булуын дәлилләгән күп табылдыклар чыккан. Әмма әле серләр ачылып бетмәгән. Аларны өйрәнү сорала. Хәзер руслар яши торган Грахань (Гәрәйхан) дигән авыл да кайчандыр болгарлар шәһәре булган.

1925 елда Кирмән җирләрендә этнограф Николай Воробьев та йөргән. Ул Татарстанда иң зур каберлекләрнең берсе булган Ханнар зиратын өйрәнә, 1337/38, 1339/40, 1351, 1352 елларга караган егермедән артык болгар кабер ташы язмаларының табылуын терки. 1880 елларда төбәкләр тарихын өйрәнүче археолог Е. Соловьев бу якларда да борынгы истәлекләрне барлап йөргән. Аннары 1992-1995 елларда Фаяз Хуҗин ул чакта үзенең шәкерте Альберт Нигамаев белән Кирмән тирәләренә килә. Ул чакта яхшы гына сакланган кабер ташлары тора әле. Берничә елдан соң килсәләр, барысы да ватылган була.

Кирмәнчек шәһәре янындагы Калатау турында төрле риваятьләр безнең көннәргә килеп җиткән, ул шәһәрне саклаган сугышчыларны да качырган, имеш. Бу урын сихәтле чишмәләре белән дә дан тота. Аларның килеп чыгышын ушкуйниклар кулыннан һәлак булган җиде кыз риваяте белән бәйлиләр. Күз чишмәсе бәреп чыгуга исә Сөембикә-ханбикә дә сәбәпче булган, имеш. Бу яклар Сафагәрәй белән Сөмбикә җирләре булган. Алар Гәрәйхан дигән утарларына барган вакытта чишмәләр янында туктап ял итә торган булганнар. Соңгы тапкыр ханбикә бу якларга ялгызы гына килә. Ул яраннарын чишмәләр янында калдыра да, тынычлык эзләп эчкәрәк кереп китә һәм илереп елый башлый. «Раббем, миңа ярдәм ит! Илемә олы дошман килә. Халкымны, илемне яклый алмыйм», - ди. Соңыннан бу урында бәреп чыккан чишмәне «Күз чишмәсе» дип атыйлар.

Бүгенге көндә исә Кирмән каласы урыннары өлешчә торгызылган, шәһәрнең кирмәне һәм манаралары корылган, аны саклаган каһарман бабаларыбыз хөрмәтенә истәлек ташы куелган. Җыен үткәрелә торган Кирмән аланы исә бу юлы кунакларны юллары яңартылып, чишмәләргә илтә торган күпер баскычлары төзекләндерелеп каршы алды.

Кирмән җыенына килүче кунакларны Мамадыш район башлыгы Анатолий Иванов сәламләде. Аның җитәкчелегендә җыенга Гарәп әмирлекләреннән килгән делегация дә килеп кушылды.

Кирмән җыены дүрт ел элек «Ак калфак» хатын-кызлар оешмасының Мамадыш районы бүлекчәсе җитәкчесе Розалия Ибраһимова башлангычы белән оештырыла. Алар башта биш ел дәвамында, чишмәләр янына өлкәннәр белән бергә килеп, бу тирәләрне тәртипкә китерә, коймаларын буйый, чишмәләрне чистарта, намаз укып, борынгы бабаларыбыз рухлары шат булуын теләп дога кыла. Алар Кирмән җыенын алга таба милләтнең үткәнен күрсәтә, татар халкын күтәрә торган фестиваль итеп үстерергә, киңәйтергә дә ниятли.

Мәйданда исә Мамадыш мәдәният бүлеге хезмәткәрләренең Кирмән тарихына багышлап әзерләгән «Тарих сәхифәләрен ачам» дип исемләнгән сәхнәләштерелгән зур тамаша (сценарий авторы – Г.Дәүләтшина) бара. Һәм бериш халык мәйдан тирәли куелган күргәзмәләрне тамаша кыла. Биредә кул эшләрен дә, борынгы ядкәрләребезне, милли киемнәребезне, Мамадыш туган якны өйрәнү музеенда сакланган археологик табылдыкларны да күрергә мөмкин иде. Мәйданда шул ук вакытта балалар өчен төрле уеннар гөрли. Мамадыш районының имам-мөхтәсибе Илһам хәзрәт Миңгалиевкә ияреп намаз укып, Кирмән җирләрен яклап шәһит киткән бабаларыбыз рухына багышлап дога да кылу исә җыенның йөзек кашы булды.

МАМАДЫШ КӨНЛӘШТЕРДЕ

Мамадыш кунакларны үзенең төзеклеге, матурлыгы белән дә хәйран итте. Шәһәр һәм район соңгы дистә ел эчендә танымаслык булып үзгәрде. Мамадышның үзендә зур шәһәрләрдә яшәүчеләр көнләшерлек «Яшьлек» ял паркы булдырылды, үзәк урам сыннар, уңайлыклар,чәчәклекләр белән ямьләндерелде. Нократ елгасы яр буе ял итү урыны исә әкияти бер урынны хәтерләтә башлады. «Арабелла» корабле, Парижның Эйфель манарасы теләсә кем күңелендә сокланулы уйлар уятырлык. Аккалфаклар Мамадышның 3 нче мәктәбендә, «Салават күпере» һәм «Миләшкәй» балалар бакчасында да, политехник көллияттә, М.Яруллин исемендәге сәнгать мәктәбендә дә булды. Әлбәттә, аларның эшчәнлегендә хатын-кызлар оешмасының Мамадыш районы бүлекчәсенең йогынтысы да сизелеп торды. Әйтик, «Салават күпере»ндәге «Акыллы диварлар», мөдир Наталья Мартынова җитәкчелегендә тәрбиячеләр һәм хезмәткәрләр тарафыннан ясалган Татарстан тарихына багышланган ике метрдан артык биеклектәге китабы, шәҗәрәләр, районлагы уңай күренешләрне күрсәткән «Үзгәрешләр сәгате» һ.б. теләсә кемгә үрнәк булырлык иде. Ә Гөләндәм Давыдованың Бөек Ватан сугышына җиде улын озатып, берсен дә көтеп ала алмаган Фатиха Әхмәдиевага куелган һәйкәл янында аның турында бәяны һәркайсыбызны тетрәндерде.

Күчмә утырыш-семинар, Мамадыш мәдәният сараенда үткән киңәшмәдән соң, Питрау бәйрәмен тамаша кылу белән тәмамланды.

Сөембикә КАШАПОВА.

Атнаның сәяси мизгелләре

КҮРСӘТЕП КЫЛЫНГАН АКТИВЛЫК

Атна хәбәрләре бүген тышкы сәясәттә Россиянең ясалма активлыгын хәтерләтә. Инде элегрәк хәбәр ителгәнчә, 22 июльдә өч ил (Россия, Украина һәм Төркия) вәкилләре, Истанбулда БМО химаясендә очрашып, Кара диңгез портлары аша Украинадан ашлыкны читкә чыгару буенча килешү имзалаган иде. Шуңа күрә 23 июльдә Одесса портының Россия хәрбиләре тарафыннан ракета утына тотылуын БМО генераль секретаре Антониу Гутерриш кискен гаепләп чыкты. Кремльдә исә ул һөҗүм Украина ашлыгын төяп читкә чыгаруга комачауламый, дип ышандырырга тырышалар. Ә РФ тышкы эшләр министры С.Лавров бу хакта, гомумән, ашлык буенча килешү Россиягә махсус хәрби операция үткәрүгә комачауламаска тиеш, килешүдә бу хакта сүз булмады, дип тә гаҗәпләндерде. Киевтә исә ашлык экспортын бу атнада башларга өметләнәләр, аны чыгарып бетерү өчен 8-9 ай вакыт кирәк булачагы турында да искәртәләр.

РФ президенты В.Путин 19 июльдә Тәһранда "Астана форматы" илләренең (Иран, Россия һәм Төркия) Сүриядәге вәзгыятьне җайга салу буенча очрашуында катнашты. Очрашу нәтиҗәләре буенча уртак белдерү дә кабул ителгән. Анда "Астана форматы"ның Сүриядәге кризисны җайга салу өчен актуальлеге турында әйтелә, Израильнең Сүриягә каршы дәвам итә торган һөҗүмнәре кискен гаепләнә, бу илдәге кризисны фәкать аның халкы һәм тыныч сөйләшүләр юлы белән генә хәл итә алачагы турында да әйтелә. Ә киләсе очрашу инде ел ахырына кадәр Россиядә үткәрелер, дип көтелә. Узган атнада шулай ук С.Лавров Африка илләренә сәфәр кылды. Ул аны 24 июльдә Мисырдан башлады һәм 27 июльгә кадәр Эфиопия, Уганда һәм Конго Республикасында булды. Ә бу хакта сөйләгән журналистлар, җае чыккан саен, Россия өчен бүген берниди изоляция дә юк, дигән фикерне үткәрергә тырышты. Бу исә үзе үк күп нәрсә турында сөйли. Ә В.Путинның G20 саммитында катнашу форматы очрашу алдыннан гына билгеле булачак.

Башка вакыйгаларга килгәндә, алары да ишарәле. Әйтик, узган атнада АКШ Киевкә хәрби ярдәмнең яңа пакетын өстәгән. Ак йорт вәкиле исә, Россия Украинаның яңа территорияләрен үзенә кушкан очракта, Вашингтон яңа санкцияләр кертәчәге турында белдергән. Россия хөкүмәте дус түгел илләр исемлеген тагын да киңәйткән. РФ тикшерү комитеты башлыгы А.Бастрыкин Киев режимының Донбасста кылган җинаятьләренә бәя бирү өчен, БМО канаты астында халыкара трибунал төзү мөмкинлеге булмаганга, андый трибуналны Сүрия, Иран һәм Боливия кебек илләр катнашында булдырырга чакырган. С.Лавров Мәскәүнең Киев белән киңрәк пландагы мәсьәләләр буенча да сөйләшүләргә әзер булуы турында белдергән. Ә Украина тышкы эшләр министры Д.Кулеба Россия белән сөйләшүләр үткәрү ул җиңелгәннән соң гына мөмкин булачагын әйткән.

Фоат УРАЗАЙ.

Каһарман

Миргазиян Крымов – Ленин һәм ике мәртәбә Кызыл Байрак орденнары иясе, җаны-тәне белән хәрби хезмәткә бирелгән шәхес. Гвардия полковнигы, дивизия командиры урынбасары дәрәҗәсенә ирешкән М.Крымов 1945 елның 15 апрелендә фашистларга каршы һөҗүм вакытында һәлак була.

Полковник дәрәҗәсенә 1935 елда ук лаек булган Крымовка ни өчен генерал исеме бирелмәгән? Югыйсә, «ГРУ: дела и люди» (2002, 417 стр.) дигән китапта Вячеслав Лурье аның турында: «Крымов М.Г. – татарин, из служащих. Генерал-майор. В Красной Армии с 1918 года» дип яза бит. Бу шәхес турында серләр күп, якташыбыз истәлеген халыкка кайтарырга кирәк.

2013 елда «Язмышыбыз Азнакай» китабына мәгълүмат җыйганда Чубар-Абдул мәктәбендә булдык. Бу белем учагы бик кадерле, чөнки сугышка хәтле монда Хаҗи Гарипов исемле укытучы эшләгән. Әтинең иң кече энесе. Ул сугыш алдыннан, артбатарея командиры буларак, Көнбатыш Украинадан яза: «Чиктән ерак түгел, 5 километр гына. Германия безгә каршы сугышка әзерләнә. Безнең чиктә 80 дивизия тупланды», – дип, Рихард Зорге кебек, хәбәр җибәргән ул 1941 елның 9 маенда. «Шушы көннәрдә сугышка кереп китү куркынычы да бар» , – дип өстәгән. Ләкин Миңнехаҗи Гарипов хәбәрсез югала, аның җибәргән язмасы да, Р.Зоргенең Токиодан килгән кисәтүе кебек, кирәк дип табылмый.

Килүебез бушка булмады. Мәндәй авылында үскән М.Крымов турында белешмәләр, тик Хаҗи абый турында белүче булмады. М.Крымов биографиясе бик кызыклы булып, китапка керде. Ләкин мөхәррир кыскартуы аркасында язма 1938 ел белән тәмамлана. Ә менә фотода ул хәрби киемдә полковник дәрәҗәсендә һәм погоннары сугыш азагында йөргән хәрби киемнәрдә генә була торган икәне күренә.

Әдәби чыганаклар буенча, Миргазиян Крымов 1891 елның 7 апрелендә Самара губерниясе, Бөгелмә өязе, Мәмин-Каратай авылында туа. Әтисе Галиулла Идиятулла улы указлы мулла була. Миргазиян ике яшьлек чагында, әти-әнисе белән Мәндәй авылына күчеп киләләр. Башлангыч белемне әтисендә, мәчет каршындагы мәдрәсәдә ала. Укуын дәвам итү өчен, 1905 елда 14 яшьлек егетне Казанга җибәрәләр. 1906 елда Галиулла мулла хатыны Сабира Мөхәммәтҗановаңы (кыз фамилиясе) аера. Шул вакыттан Миргазиянның әнисе белән элемтәсе өзелә. Алга китеп, әйтеп үтү кирәктер: әнисе авырлы килеш аерыла һәм 1907 елда ир углан таба. Аңа Барый исеме кушып, Крымов фамилиясе бирә. Кечкенә бала белән Сабира абыстай үзенең туган авылы Юлтимергә кайтып китә (Сарман районы яисә Лениногорск ягы – **М.Г.**).

Миргазиян 1907-1911 елларда семинариядә, Казан татар укытучылары мәктәбендә «земская стипендия» алып укый. Минзәлә өязендәге Чүбүкән (Чыбыклы-?) авылында 4 ел халык укытучысы булып эшли, август аенда Таверовага (?) күчерелә. 1915 елның көзендә Россия армиясенә чакырыла. Башта Казандагы 95 нче запас батальонда хезмәт итә. Берничә айдан рядовой Крымовны Тифлисның прапорщиклар мәктәбенә җибәрәләр. Мәктәпне тәмамлап «кече офицер» дәрәҗәсен алгач, Чиләбе шәһәрендәге 109 нчы запас пехота полкында хезмәт итә. 1917 елгы Февраль революциясеннән соң Чиләбе эшче һәм солдат депутатлары советы Башкарма комитеты әгъзасы, хәрби гарнизон башлыгы була. Октябрь революциясе вакытында Совет хакимияте ягында Чиләбе оборонасы белән җитәкчелек итә һәм генерал Корнилов фетнәсе вакытында 163 нче запас полкта башланган чуалышларны бастыруда катнаша. Фетнәне бастыруда катнашкан мөселман солдатлары бер ротага берләштерелә һәм командир итеп М.Крымов билгеләнә.

Илнең катлаулы тарихы, ачы язмышы язылган бу чорда Крымов Чиләбенең «шәһәрне саклау комитеты җитәкчесе» вазифасында була. Алар Кызыл Армия отрядларын, тимерьюлчыларны, тимер кою заводы эшчеләрен һәм башка хезмәт ияләрен оештырып, хәрби өйрәнүләр үткәреп, Ватанны контрреволюциядән якларга өйрәтәләр. Октябрь аенда шәһәр гарнизоны башлыгы буларак, Крымов Чиләбене есаул Титов һ.б. казак отрядларыннан яклау өчен көчләр туплап, аларга каршы тора.

Төбәктә Октябрь революциясе вәкилләре хакимлек иткән чорда ул 32 нче запас бригаданың комиссары һәм ВРК (вакытлыча ревкомитет) штабының исполком әгъзасы була. Атаман Дутов Оренбург казаклары ярдәмендә Чиләбе якларын яулап алгач, Крымовны февраль аенда, Уфага чакырып, Үзәк Комитет әгъзасы итеп сайлыйлар һәм контрреволюция оешмаларын юк итү бурычын йөклиләр. Үз теләкләре белән килгән 800 кешедән торган татар-башкорт революцион батальонын «Аерым Урал» дип атыйлар. 1918 елның февраль-март айларында бу көчләр Уфада Башкорт милли корылтаен, Хәрби Шураны һәм 2 нче мөселман полкын тар-мар итүдә катнаша. Шул елның март азагында камалышта калган Троицк (Җаек) шәһәрен сакларга Чиләбе хәрбиләренең штабы коменданты буларак җибәрелә. Май аенда Крымовны округның хәрби комиссары итеп билгеләпләр. Уфа 27 майда чехословак корпусы хәрбиләре тарафыннан басып алына. Миргазиян әсирлеккә эләгә, тик тиз арада качып котыла. Кызыллардан кечкенә отряд туплап Шадринскига юнәлә. Юлда очраган кулак күтәрелешләрен бастырып, совет җитәкчеләрен азат итеп баралар. Шадринскидан – Екатеринбургка, аннан Уфага кайталар. Монда аны губерна хәрби комиссары һәм оператив-кыр штабы әгъзасы итеп куялар. Крымов Самара һәм Чиләбе якларыннан яу белән килгән чехословак корпусына каршы торуны оештыра.

1918 елның ноябрь аенда М.Крымов Мәскәүгә командировкага җибәрелә һәм «Нарком военпром» карамагындагы Мөселман хәрби коллегиясенең (ЦМВК) бүлек мөдире итеп тәгаенләнә. Бу вакытта Мәскәүдә Мөселман командирлары курсы ачу хәл ителә. Бу эшне оештыру Крымовка кушыла.

ЦВМК 4 декабрьдә 200 кешелек хәрби курс ачу турында карар чыгара. 1919 елның 1 гыйнварына бөтен оештыру мәсьәләләрен чишәргә кушып, Крымовны Казанга җибәрәләр. Ике ай эчендә курсның команда составы билгеләнә, укытучылар җыела, уку һәм хуҗалык бүлеге оеша, лазарет ачыла, обмундирование һәм артиллерия, инженерия буенча җиһазлар сатып алына. Махсус бина итеп элеккеге «Петровское училище» сайлап алына. Март азагында М.Крымов Аерым Татар укчы бригадасы белән җитәкчелек итәргә куелса да, ул әле Мөселман курсларын кайгыртып тора. Шамил Усманов белән 6 апрельдә «Кызыл Армия» газетасында бергәләп өндәү бастыралар: «Свободолюбивые татарские джигиты – под Красное Знамя!» – дип хәрби хезмәткә чакыралар. (Шул вакытта «дошманнары» аңа Панисламизм республикасы төзергә өнди дип ялa ягa, ә Миргазиян үзе 1919 елда ВКП (б) сафына керә). «Кызыл Байрак астына!» – дигән өндәү күп тарафларга җитеп, кешеләрнең күңелен аулый. Илдә гражданнар сугышы бара, халык ач-ялангач. Татарлар иң авыр эшләрдә ялланып эшли. Кузбасс шахтасында, Кемерово күмер чабучы Түбән Сукаеш егете Мөхәммәтша Гариповка да килеп ирешә бу хәбәр. Ләкин якташ командирлар күбрәк хәрби һөнәр ияләрен чакыра: элеккеге офицерлар, телеграфист-телефонистлар, врач, шәфкать туташлары һ.б. Сугышка шахтерлар кирәкми, шуңа Мөхәммәтша «Укырга кирәк, укырга » , – дип уйлый.

М.Крымовка да белемен камилләштерергә кирәк. Мәдрәсә-семинария, училище белеме белән ерак китеп булмый. 1919-1920 елның башына кадәр ул – оперотряд башлыгы ярдәмчесе, соңрак башлык. Туган-үскән яклардан күңелсез хәбәрләр килеп ирешә: әтисе Галиулла мулланы 1920 елның апрель аенда Карамалы авылына барганда атып үтергәннәр... Ул чакта Миргазиян Казанда «Укрепленный район» штабы башлыгы вазифасында Сарапул, Чиләбе, Акмулла шәһәрләре аша үткән ныгытмаларны төзү белән шөгыльләнә. Чиләбедә Евгения Павилонская белән тормыш кора.

Тиздән М.Крымовны Көнчыгышка, 5 нче армиядәге экспедицион корпуска, штаб башлыгы ярдәмчесе итеп җибәрәләр. Монда ул 1921 елның көзенә кадәр хәрби хезмәттә була.

Ниһаять, басмачыларны тар-мар иткәч, укырга да вакыт чыга. 1921-1926 елларда Миргазиян М.Фрунзе исемендәге Хәрби академиядә укый. Монда инглиз һәм төрек телләрен үзләштерә. Академияне тәмамлагач, аны развед-идарә штабына эшкә җибәрәләр. Чынбарлыкта биш ел буе ул Төркиядә була һәм махсус задание үти: СССРның Төркия Республикасында сәяси вәкилләре каршысындагы атташе, аппарат хезмәткәре була. 1931 елның мартыннан ноябрь аена кадәр Кызыл Байраклы Кавказ армиясенең разведка идарәсе башлыгы

комдив Крымов


НАГРАДНОЙ ЛИСТ
1. Фамилия, имя и отчество
2. Звание
3. Должность, часть
Представляется к
4. Год рождения
5. Национальность
6. Партийность
7. Участие в гражданской войне, последующих боевых действиях по защите СССР и отечественной войне (где, когда)
8. Имеет ли ранения и контузии в отечественной войне
9. С какого времени в Красной Армии
10. Каким РВК призван
11. Чем ранее награжден (за какие отличия)
12. Постоянный домашний адрес представленного к награждению и адрес его семьи
1. Краткое, конкретное изложение личного боевого подвига или заслуг

Минзакир Әпсәләмовның урынбасары, соңрак идарә башлыгы була. 1932-1933 елларда Крымов кабат Фрунзе исемендәге Хәрби академиянең оператив факультетында белемен арттыра. Укуын тәмамлагач, Татарстан АССР Үзәк башкарма комитеты исемен йөртүче 1 нче Казан укчы дивизиясенең штаб башлыгы итеп билгеләнә. 1935 елда Фрунзе исемендәге Хәрби академиядә гомуми тактика кафедра җитәкчесе итеп раслана. Ел азагында аңа полковник дәрәҗәсе бирелә. Тыныч кына эшләгәндә Миргазиянның баш очында «болытлар куера». 1938 елның 1 гыйнварында академия буенча чыккан боерыкта: «Гомуми тактика кафедрасы ассистенты» – дигән вазифага хәтле төшерәләр. Илдә репрессияләр бара, НКВД хезмәткәрләре М.Крымовның нинди социаль катламнан икәнен ачыклый һәм 20 ел хезмәтен юкка чыгара. Шул җәһәттән бер өзек: «1938 елның 1 августында Оборона халык комиссары боерыгы белән 43-нче матдәнең «б» пункты буенча запаска җибәрелә, ә 1939 елда «троцкизм тарафдары булуы һәм үзенең социаль чыгышын яшергән өчен» партиядән чыгарыла.

Каһарман Крымов хәрби антына тугры кала. Мәскәү каласының Москворецкий районындагы ВУЗларда хәрби кафедра укытучысы һәм военрук булып эшли. Гаделлек өчен көрәшүен дәвам итә. 1939 елда хезмәттән җибәрү турындагы боерыкның «43нче матдәнең «а» пунктына үзгәртү кертәләр. Үз хокукларын торгызу өчен көрәшү нәтиҗәсе – милләттәшебезгә «эштән җибәрү» матдәсен «запаста калдыру»-га үзгәртергә насыйп була. Акланып, Крымов 1939 елдан Сталин исемендәге Мәскәү корыч институтында хәрби кафедра укытучысы булып эшли башлый.

Репрессия шаукымнары энесе Барый Крымовны да читтә калдырмый. НКВД куштаннары аны Сарман районының Иске Имән авылы мәктәбендә укытучы һәм завуч булып эшләгән вакытта 1937 елда «Тройка НКВД ТАССР» карары белән: «протаскивал чужую идеологию в обучение, использовал запрещенную литературу», – дип 10 елга хөкем итә, ул хезмәт белән төзәтү лагерена (ИТЛ) озатыла. Бары 1986 елда гына укытучы Барый Крымов исеме аклана. Аның тормыш юлы да тулысынча ачыкланмаган.

Миргазиян Крымов исә 1941 елның октябреннән Кызыл Армиянең Югары Хәрби гидрометеорология институтында тактика кафедрасы җитәкчесе була. 1942 елның 23 февралендә икенче мәртәбә (репрессиядән соң) хәрби ант кабул итә. Шул елның 6 октябрендә аны Тамбов шәһәрендәге 98 нче укчылар дивизиясенең командир урынбасары вазифасына билгелиләр. Аларны Сталинград фронтына җибәрәләр. Җиде ай буена барган дәһшәтле яулардан соң, полковник Крымовны 387 нче укчы дивизиягә күчерәләр, ә 1943 елның август аеннан 127 нче дивизиянең командиры итеп куялар. Бу Кызыл Байраклы, Кутузов орденлы дивизия Крымов җитәкчелегендә 1943 елның 2 сентябрендә Украинаның Чистяков шәһәрен азат итә. Шуннан соң 127 нче дивизияне «Чистяков дивизиясе» дип йөртә башлыйлар. 1943 елның 4 сентябрендә күрсәткән батырлыклары өчен якташыбыз М.Крымов Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә. Шул вакытта аны ВКП(б)га кандидат итеп теркиләр. (Хәзер Донецк халык республикасы биләмәсендәге шәһәр Торез исемен йөртә. Бу шәһәрдә М.Г. Крымов исемендәге урам бар.) Инде барысы да үз урынына кайта дигәндә генә, 1943 елның декабрь аенда данлыклы комдивны бу вазифасыннан бушатып, 1 нче Украина фронты хәрби советына күчерәләр. Сәбәбе: «За плохое руководство дивизией, за отсутствие заботы о быте и питании личного состава» . Ә бит устав буенча бу вазифалар дивизия командирыныкы түгел. Фронтта тәҗрибәле хәрбиләр бик кирәк – шуңа җаен табып, ике айдан Крымовны 38 нче укчы дивизиянең вакытлыча командир вазифасын башкаручы итеп билгелиләр. Монда да ул хәрби батырлык күрсәтеп дан казана һәм тиздән дивизия командиры итеп күчерәләр. Яңа 232 нче дивизияне җитәкләп, хәрби осталык күрсәтеп, икенче Кызыл Байрак ордене белән бүләкләнә.

1944 елның декабрендә Крымовны 2 нче Украина фронтына, 206 нчы укчы дивизиягә замкомдив итеп җибәрәләр. Бу дивизия бик данлыклы, хәрби казанышлары өчен Кызыл Байрак, Суворов һәм Кутузов орденнары белән бүләкләнгән. Комдив полковник Дременков Крымовны хөкүмәт бүләгенә болай тәкъдим итә: «За короткое время пребывания в дивизии показал себя тактически грамотным, волевым командиром. Имеет боевой опыт в руководстве частями дивизии, всегда находится в боевых порядках и контролирует ход боевых действий, своевременно донося командованию дивизии обстановку. Лично смел, дисциплинирован. Требователен к себе и своим подчиненным. Выдержан, морально устойчив. Делу партии Ленина-Сталина и социалистической Родине предан» .

1945 елның февралендә гвардия полковнигы Крымов хөкүмәт тарафыннан Ленин ордены белән бүләкләнә. Җиңү көнен каршыларга насыйп булса, якташыбыз югарырак генерал дәрәҗәсенә тәкъдим ителеп, тагын бәяләнер иде. Кызганычка, М.Крымов 1945 елның 15 апрелендә, Словениянең Сомбор шәһәрен азат иткәндә, каһарманнарча һәлак була. Шәһәр чиркәве янында җирләнә...

Кайбер чыганакларда Крымовны генерал-майор дәрәҗәсендә, дип язалар. Аның документлары генерал исеменә тәкъдим итеп әзерләнгән, имзаланган булуы да мөмкин. Шундый очракка үзем каһарман-шагыйрь Хәйретдин Мөҗәй мирасын тикшергәндә тап булдым. Полковник Хәйретдинов Харьков юнәлешендә барган сугышларда яраланып, әсирлеккә эләгә. Дахау концлагеренда гомере өзелә. Аның документлары полковник дәрәҗәсенә имзаланган була, тик ул үзе бу турыда белми кала (Хәйретдин Мөҗәй. Тормыш юлы һәм иҗаты. ТКН. 2010).

М.Крымовның да тормыш юлы тиешенчә өйрәнелмәгән. Аның ике абыйсы була: Мирсәет (1888-1918) һәм Әхәт (1902-1927). Әхәте Мәндәйдә туган булуы ихтимал. Әниләре язмышын да тулырак ачыкларга кирәк. Шундый егетләрне, булачак комдив һәм педогог табып үстергән Ана бит ул! Аталары Галиулла да тормыш каршылыкларына бирешмичә алга атлаган, заманча яшәгән мулла була. Мәндәйдә «Кредитное товарищество» оештыра.



Әлегә без төбәк тарихчысы Илдус Латыйпов, күренекле архивчы Дамир Шәрәфетдинов, тарих фәннәре докторы Яков Гришин, эзтабарлар Михаил Черепанов, Елена Сунгатова, Макар Донецкий язмаларын файдаланып, М.Крымов турында сезгә җиткерергә тырыштык. Әгәр без язмасак, ватанпәрвәр шәхесләребезнең исемнәрен килячәк буыннарга кем җиткерер?

Марсель ГАРИПОВ.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

30 июль (шимбә). ***Мөхәррәм аеның 1 нче көне. 3 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 4.55 сәгатьтә калка, 21.05 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 16.10 сәгать.***

Бик актив көн, хәвеф-хәтәр инстинкты, агрессия белән бәйле. Бүген чирләп китү ихтыяр көченең җитәрлек булмавын күрсәтә. Күзне арытмаска кирәк.

Кара карлыган

Ашказаны авыртканда, атеросклероз, ревматизм интектергәндә, 3-4 аш кашыгы вакланган кара карлыган яфрагын 300 мл кайнар суда, яхшылап төреп, 4 сәгать төнәтәләр, сөзәләр, көненә 4-5 тапкыр яртышар стакан эчәләр. Азканлылык булганда, хәлсезләнгәндә, чәй урынына көн буена карлыган яфрагын пешереп эчү файдалы. Грипп, фарингит, ларингит, тонзиллит, бронхит, пневмония булганда, 1 чәй кашыгы төелгән карлыган яфрагын 1 стакан кайнар суда ябык савытта 10-12 минут пешерәләр, сөзәләр, бал кушып, көн дәвамында 2-3 стакан эчәләр. Цистит интектергәндә, 6 аш кашыгы вакланган карлыган яфрагын 1 литр кайнар суда җылы урында 1 сәгать төнәтәләр, көненә 5-6 тапкыр 1әр стакан эчәләр.

31 июль (якшәмбе). ***Мөхәррәм аеның 2 нче көне. 4 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 6.14 сәгатьтә калка, 21.15 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 16.06 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Теләсә нинди элемтә, танышулар, күмәк эш бүген кыен кичерелә. Озаграк йоклау хәерле. Тәмлерәк һәм күбрәк ашау теләге зур булса да, чаманы югалтмаска кирәк. Ач торырга ярамый.

Витилигодан - әнис мае

Тапларга көненә 2 тапкыр яңа сыгылган рәваҗ тамыры согы сөртәләр. Яисә 1 чәй кашыгы кара чәйне чирек стакан кайнар суга салып, 3 минут кайнаталар, суынгач, сөзәләр, тапларга сөртәләр. Йә булмаса, 100 грамм әнис орлыгын килēдә төеп, ярты литр зәйтүн маена салалар, караңгы урында 1 ай төнәтәләр, аннары куыклар пәйдә булганчы җылыталар да, суытып, сөзәләр, тиредәге ак тапларга гел сөртеп торалар.

1 август (дүшәмбе). ***Мөхәррәм аеның 3 нче көне. 5 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 7.33 сәгатьтә калка, 21.23 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 16.02 сәгать.***

Бүген юлда булу әйбәт. Ач тору тыела. Күңел нәрсә тели, күпме тели – шулкадәр ашарга була, бигрәк тә яшелчә файдалы. Башлаган эшне ахырына җиткезү зарур. Ашказаны-эчәк авырулары кискенләшү тискәре энергиянең артык күп тупланүын күрсәтә. Кан әйләнеше системасы, иңк, муен, бронхлар зәгыйфь.

2 август (сишәмбе). ***Мөхәррәм аеның 4 нче көне. 6 нчы Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 8.52 сәгатьтә калка, 21.30 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 15.59 сәгать.***

Хисчәнлек арта. Һәртөрле аралашу күңелгә ятышлы. Бу көннәрдә әти-әнигә ихтирам көче аеруча куәтләнә, гаиләдә бергә җыелып, балачакның күңелле хатирәләрен

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

яңарту яшәү көче өсти. Безләр системасы, җилкә, кул,үпкә, бронхлар зәгыйфь, салкын тию ихтималы зур.

Тузганак мае

1 стакан тузганак чәчәген 1 стакан чистартылмаган көнбагыш маенда ярты сәгать кайнаталар. Сөзеп, суытып, суыткычта ел буе сакларга мөмкин. Мондый май пешкән җирне бик яхшы төзәтә – авыртуны да баса, кабарчыклар да чыгармый.

3 август (чәршәмбе). ***Мөхәррәм аеның 5 нче көне. 7 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 10.12 сәгатьтә калка, 21.38 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 15.55 сәгать.***

Һава энергиясенә бәйле көн. Тынгысызланырга, гайбәт сөйләргә ярамый. Ялгыз калып уйлану файдалы. Нерв системасы, үпкә зәгыйфь. Ач тору, ашказанын һәм эчәклекне чистарту уңай нәтиҗә бирә.

Тез авыртканда

2 шәр аш кашыгы эт шомырты (крушина) кайрысы һәм тузганак тамыры, 2 шәр чәй кашыгы петрушка, фенхель орлыгы һәм бөтнек яфрагын кушып, шуның 1 аш кашыгын ярты стакан кайнар суда 30 минут төнәтәләр, иртән ач карынга 2 шәр аш кашыгы эчәләр (авырту басылганчыга кадәр).

4 август (пәнҗешәмбе). ***Мөхәррәм аеның 6 нчы көне. 8 нче Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында, 11.35 сәгатьтә калка, 21.47 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 15.51 сәгать.***

Бүген бигрәк тә ут белән эш иткәндә саклык сорала. Ризык җиңел үзләштерелүчән булырга тиеш. Ашказаны, безләр системасы зәгыйфь, невралгия һәм стенокардияне кисәтү чаралары уңай нәтиҗә бирә. Колак авыртырга мөмкин. Бу атнада күзне саклау мөһим.

Күзгә дәва

Күз күреме начарайса, 5 уч вакланган нарат ылысын 2 стакан суга салалар, сүрән утта әз генә кайнатып алалар да, төнлә җылы урында төнәтәләр. Иртән сөзәләр, көн буена эчеп бетерәләр. 2 ай буе шулай дәваланалар: 7 көн рәттән ылыс төнәтмәсе эчәләр, 7 көн ял итәләр. Помидор, кара җиләк, кишер, йомырканы күбрәк ашау да күз өчен файдалы.

5 август (җомга). ***Мөхәррәм аеның 7 нче көне. 9 нчы Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында, 13.02 сәгатьтә калка, 21.58 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 15.47 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн, алдашу, ялганга бай. Хәтта сыйфатлы ризык белән дә агулану ихтималы бар. Күп аралашу хупланмый. Фикерләрне тупларга, үзегезне үпкәләткән кешеләрне кичерергә кирәк. Үпкә, ашказаны зәгыйфь. Кан басымы күтәрелергә, йөрәк, арка яки баш авыртырга мөмкин. Мунча керү файдалы.

Маринадланган кыяр

Кечкенә кыярларны (корнишон) 4 сәгатькә салкын суга салып куялар. 1 литрлы 4 банкага җитәрлек маринад әзерлиләр: 2 литр суга 7 аш кашыгы шикәр, 3 аш кашыгы тоз салып, кайнатып чыгаралар, сүндергәч, 180 мл 9 процентлы серкә өстиләр. Банкаларга дүрткә бүленгән 1әр кишер, бөҗралап туралган 1 әр баш суган, 1-2 шәр укроп зонтигы, тыгызлап кыярларны тутыралар да, кайнап торган маринадны коеп, тимер капкач белән каплыйлар.

Хикәятләр



Остазга ышаныч

Бер остазга белем алырга дип өч укучы килә. Алар мәдрәсәдә укыганнар, әмма аны ташлап киткән булганнар, ә хәзер анда киредән укырга алмыйлар...

Яңа остаз аларга әйткән:

– Һәр нәрсәдә дә миңа ышансагыз гына укытачакмын, шартым шундый, – дигән.

Беренче дәрестә үк остаз боларны сынап карарга уйлаган:

– Сезгә бирем, якындагы урманга барып, утын алып кайтыгыз, – дигән.

Шәкертләр ул урман турында башкаларның сөйләгәнен ишеткән булалар. Имеш, анда коточкыч куркыныч җанварлар яши икән...

– Шуны онытмагыз, дигән остаз, – ул урманда берәү дә яшәми, курыкмагыз, – дип әйтеп калган.

Урманда ул куркыныч җанварлар бетмәгәндер әле дип, беренче шәкерт урманга бөтенләй бармаган. Икенче шәкерт урманга кереп киткән. Агач астындагы ботакларның шарт-шорт сынуы аның күңелендә шик уяткан. Куркыныч җанварларны күз алдына китереп, акрын гына урман эченә таба атлаган. Шунда аның күз алдынаниндидер җанвар шәүләсе күренеп киткән кебек булган. Ул тиз генә борылып:

– Остаз безне алдаган, монда хәшәрәтләр бихисап, алар миңа якынлашалар, дип кычкыра башлый. Ул куркудан урманнан утынсыз йөгереп чыга.

Өченче шәкерткә урманга барырга вакыт җитә. Ул, «бисмилла» әйтеп, урманга керә һәм шактый күп утын җыеп, күтәреп чыга. Остазы янына килеп:

– Нигә башка шәкертләр коточкыч җанварлар турында сөйлиләр, мин күпме йөрдем, андый хәшәрәтләрне күрмәдем, – ди.

– Син минем сүзләремә чын күңелдән ышангансың. Үзебездәге куркуларыбыз аша без коточкыч нәрсәләр күргән кебек булабыз. Кешеләр белән дә шулай: кечкенә генә ышанычсызлык туа икән, куркуы сәбәпле, күпсанлы коточкыч хәшәрәтләр күз алдына килә башлый, – дигән остаз.

– Ике шәкерт минем сынауны узмады, шуңа күрә укырга бер шәкертем генә кала, – диде ул.

Кыйммәтле таш

Берәү үзенең бала чагын исенә төшереп, алмазны беренче күрүе фикеренең ничек үзгәрүе турында сөйләгән. Башта күргәч:

– Нинди кыйммәтле асылташ, – дигән.

Үсә төшкәч, ул алмазның составы графит кебек булуын, аның һәр карандашта файдалануын белеп, күңеле төшкән. Аннан соң аның структурасы кристаллик рәшәткәдән торуын һәм бик каты матдә булуын белгәч, күңеле күтәрелгән. «Инде ул – мөхтәрәм акыл иясе, остаз булгач, алмаз аңа гади таш кебек кенә булып калган. Аның алмаз турында мәгълүматы арткан саен, ул таш үзенең моңа кадәр белмәгән яңа кырлары белән ялтырый.

– Акыл иясе һәм үсмер баланың фикерләве бертөрлеме икән? Әгәр алай булса, нигә тырышырга, зирәклек тупларга һәм аларны үзләштерергә? – дип сорады тыңлап торган үсмер.

– Үсмер бала һәм акыл иясе – бертигез түгел. Бала алмазны бәяли алмый, чөнки аның чын кыйммәтен белми, ә акыл иясе бәяләми, чөнки аның чын бәясен, кыйммәтен белә. Бәхетне, мәхәббәтне, зирәклекне һәм шатлыкны ул алмазга сатып ала алмаганны һәм ахирәткә дә алып китә алмаганны яхшы белә.

Аллаһ разый булсын

Бер салкын кышлы елны ике кеше үзләренең хәлле авылдашлыга иген сорап килә. Игелекле кеше булганга күрә, тегесе аларның гозерен буш калдырмый, һәрберсенә берәр капчык иген биреп җибәрә. Ярлылар рәхмәт әйтә дә, капчыкларын җилкәләренә салып, өйләренә кайтып китәләр.

Беренче авылдашы өендә игенне ике капчыкка урталай бүлгән, берсен хәзергә ашап торырга, икенчесен язын кырга чәчәргә калдырган. Көзен ул үзе чәчкән орлыклардан икеләтә уңыш җыеп алган. Аңа тагын бер елга җитәрлек уңыш алган. Ул бер капчык игенне җилкәсенә салып үзенең хәлле авылдашы янына киткән. Үзенең алган бурычын түләргә һәм аңа рәхмәт әйтү нияте белән барган. Хәлле авылдашы аның түләргә алып килгән игенле капчыгын алмаган.

– Мин биргән капчыктагы иген сиңа сәдака, Аллаһы Тәгалә разый булсын. Әгәр игенеңне бүләк итәсең килсә, башка мохтаҗларга бирә аласың, – дигән хәлле авылдашы.

Икенче авылдашы капчыктагы игенне көн саен бодай боткасы пешереп, ел буе гаиләсе белән ашаган. Кышка инде аның ашарга запасы калмаган. Ул яңадан хәлле авылдашы янына сорарга киткән, әмма бу юлы аңа тегесе иген бирмәгән.

– Үзеңнең дустыңнан үрнәк алырга кирәк иде. Игеннең бер өлешен бакчаңа чәчәргә булдыра иден, үзеңә кышка ризык та булыр иде. Син ялкаулыгың аркасында боларны эшләмәдең. Әгәр сиңа тагын иген бирсәм, мин ялкаулар арттыручы булам бит! Аллаһы Тәгалә дә, пәйгамбәребез (с.г.в.) дә бу эшне хупламаган. Әнә үзеңнең дустыңа барып сора, ул сиңа иген бирер, әмма һаман хатаңны кабатлама, ялкауланып ятма. Башка кешеләрдән ярдәм көтеп утырма, бүтәннәргә булыш, яхшылык эшлә, Аллаһы Тәгалә синең игелекле эшләреңне күрер, – дигән.

Игелек кылу

Элегрәк бер шәһәрнең өч бай кешесе яшәүчеләргә игелек кылырга уйлаганнар, һәркайсы игелек өчен берәр тонна бөртекле алтын әзерләгән.

Беренче бай үзенең бөртекле алтынын очкычка (самолетка) төяп, шәһәр өстенә сипкән. Бу хәлдән соң яшәүчеләргә артык файда килмәгән, тормышлары яхшырмаган. Алар шәһәр буйлап бик вак бөртекләрне эзләп, җыеп йөри алмаганнар.

Икенче бай үзенең алтын комы өемен эретеп, анардан алтын акча тәңкәләре суктырган һәм шәһәрдә яшәүчеләрнең барысына да берәр тәңкә өләшеп чыккан. Кешеләргә ул акча күпкә җитмәгән... Бу хәл турында шәһәрдә яшәүчеләрдә татлы хатирәләр генә калган.

Өченче бай алтын ком тавын сатып җибәргән, ә аның акчасына ярлыларга йортлар төзеткән, аларны эш урыннары белән тәэмин иткән, аларның балаларына, оныкларына балалар бакчалары, мәктәпләр салдырган. Чыгымнарын үзе түләп барган.

Һәр бай үзеннән бер тонна алтынын шәһәрдә яшәүчеләргә игелекле эшләр өчен сарыф иткән. Бу эшләрнең нәтиҗәләре төрле булган.

Еллар узган, баштагы ике байның игелеге турында шәһәр архивындагы язмалар аша гына белеп була. Өченче бай турында аның салдырган бакчаларында, мәктәпләрендә укучылар фәлән бай төзеткән бинада укыдык, дип горурланып сөйлиләр. Дин тотучылар аның рухына дога кылудан туктамый. Ул байның юмартлыгы, шәфкатьлеге, зирәклеге турында хәбәрләр шәһәрдә яшәүчеләр авызыннан төшми...

Зирәк шәкерт

Мәдрәсәдә укучы шәкертләр арасында бик зирәк укучы булган. Башкалар, әлбәттә, анардан көнләшкәннәр, бездән әллә ни аермасы юк аның, дигәннәр. Бервакыт бу турыда остазларыннан сорарга булганнар. Аларның үтенечe буенча остазлары бирем әзерләгән, һәр шәкерт иртәгә икенче дәрескә берәр тавык суеп алып килергә тиеш булган. Ләкин бер шарты бар: моны берәү дә күрмәскә тиеш!

Икенче дәрескә шәкертләр суелган тавыкларын күтәреп килгән. Берсе генә тере тавыкны алып килгән. Ул – остазның яраткан шәкерте, һәр шәкерт үзенең тавыкны ничек качырып суйганы турында сөйләгән. Кайсыдыр шәкерт сарайда, кайсы чоланда, кайсы мунчада... Чират остазның яраткан шәкертенә җиткән.

– Әй, остазым, Аллаһы Тәгаләнең күрми калган нәрсәсе юк, – дигән.

Остаз башка шәкертләргә борылып:

– Аңладыгызмы, ни өчен мин аны барыгыздан да артыграк яратам, – дип әйтеп сүзен йомгаклаган.

Нияз БИШБАЛТА туплады.

Бишмәтеңдә 1000 төймә...

Татарларның «Бишмәтеңдә – биш төймә...» җыры бу очракка һич туры килми. Бу бишмәтләрдә аларның саны берничә меңгә җитә...

Лондон урамнарына елына ике тапкыр кара костюм-чалбарлы ир-атлар һәм кара күлмәкле хатын-кызлар чыга. Аларның киемнәре сәдәп-төймәләр белән чигелгән. Кем икән соң болар һәм ни өчен шулай киенәләр?! Үз-үзләрен тотышлары да үзгә, әйтерсең лә чын монархлар! Тик алар чынлыкта урам сәүдәгәрләре. Әлеге традиция XIX гасырга барып тоташа. Чөнки 1875 елда Генри Крофт исемле яшүсмер беренче тапкыр шушындый костюм киеп, үзенә игътибар яулый.

Генри Крофт 1861 елда Сомерс-Таун районының ярлылар гомер иткән кварталында туа. Малайга 10 яшь тулуга аның әтисе үлеп китә һәм аны ятимнәр йортына бирәләр. 13 яше тулуга ук, ул үз көнен үзе күреп урам себерә, җирле базардагы күселәрне тота башлый. Билгеле инде, кайчандыр үзенә һәйкәл куярлар дип уйламый да... Яшүсмер бер эштән дә курыкмый. Аның дуслары да арта бара. Генрига хөр һәм бәйсез урам сәүдәгәрләре компаниясе ошый. Чөнки аларны күрмичә калу мөмкин дә түгел бит! Бу сәүдәгәрләрнең кара киемнәрен бик җете төсле йолдызлар, кояш, ай, чәчәк, йөрәк, күгәрчен, ат дагасы, якорь, арба тәгәрмәче сурәтләре бизәп тора.

1860 елларда Темзада Япониядән килгән, бортында бай сәдәпләр партиясе булган зур кораб баткач, аларның киемнәренә дә перламутрлы сәдәп рәтләре өстәлә. Кайберәүләр исә моны Лондонның көньягында шундый ук сәдәпләр җитештерелә башлау белән бәйли, тик башкаларга кораб тарихы хакында сөйләү ошый... Әмма моңа кадәр үк инде азык-төлек сатучылар катламын, костерларны чалбарларына бер рәт перламутрлы сәдәпләр тегеп йөрүләре буенча хәтерлиләр. Алар моны бер-берсен тану өчен дә эшләгән. Костерлар катламы XVI гасырда ук булган һәм шул чорда да алар бер-берсенә һәрчак ярдәм итеп яшәгән, әйтик, арба тәгәрмәчләре ватылып китсә дә, бергәләп төзәткәннәр, берәрсе бөлсә, аңа бергәләп булышлык та иткәннәр... Мондый бәндәләрнең урамнарда кычкырып җырлавы, үзләренә игътибар иттерүләре дә яшүсмер күңеленә хуш килгән. Бу бит әле сәүдәне дә арттыра. Ә иң мөһиме, алар үзара тату, бер-берсенә ярдәм кулы сузарга әзер. Генри да ятимнәр йортындагы яшьтәшләренә булышлык итү кирәк дигән нәтиҗәгә килә. Ә менә акча туплау өчен шулай ук үзеңә игътибар җәлеп иттерү сорала һәм ул, перламутрлы сәдәпләр генә кулланып, төннәр буе яңа костюм иҗат итә. Аның сәдәпләре катлаулырак бизәкләр тәшкил итә. Ниһаять, костюм да, төймәле цилиндр да әзер! Шуларны киеп, базарга чыккач, Генриның артыннан халык иярә, урам сәүдәгәрләре исә аны үз эшчәнлекләренә кушылганы, алар мәнфәгатен якларга әзер булганы өчен, үзләренең «корольләре» итеп тә сайлап куеп, аңа булышлык итә башлыйлар. Популярлыгы зур булу сәбәпле, яшүсмер хәерчеләргә ярдәм итү өчен акча җыючы бар төр мәрхәмәтлек чараларында да катнаша, аннары матди табышны ярлылар, авырулар, чукрак һәм сукырлар арасында тарата. Генриның уңышын күреп, аңа дин әһелләре дә тартыла.

Ул үзенә 7 костюм тегә һәм башкалар өчен дә бизәмле костюмнар иҗат итүгә алына. Ә бер костюмына ул тулысынча сәдәпләр тегеп чыга. Бераздан Лондонның төрле районнарында шундый ук «энҗеле корольләр һәм королевалар» пәйда була. Аларның вазифалары: эчке конфликтларны чишү һәм үз мәнфәгатьләрен яклап, хакимият белән аралашу. Шунысы да бар: аларның һәрберсе үз костюмының калганнарныкына караганда яхшырак булуын тели. Шуңа күрә дә сәдәпләрне жилетларга, галстукларга, эшләпәләргә, кепкаларга да тегеп куялар, ә менә ханымнар сәдәпләр белән хәтта зонтикларын, сумкаларын да чуарлый. Гаҗәеп сан: уртача бизәлгән костюмга 30 000 төймә тагыла. Билгеле, аның авырлыгы да 30 килограммга җитә. Ә аны киеп йөрү – монысы тагын да авыррак халәт. Авыз суы корырлык итеп көнләшсеннәр өчен, тырышырга кирәк! Һәм мондый бәйгедә бары тик хатын-кыз гына җиңә ала. Әйтик, 1972 елда конкурста Беатрисс Мариотт беренчелеккә чыга, бу ханым үз костюмына 90 000 төймә таккан була!

1902 елда 41 яшьлек Генриның фотосы да һәр ай саен зур тираж белән чыга торган, бик популяр «The Strand Magazine» журналында басыла. «Мистер Крофт – Сомерс–Таунның энҗеле короле» диелә язмада һәм костюмы да тасвирлана: «Костюмда барлыгы – 4900 сәдәп, аларның 700е – баш киемендә, жилетта – 1500, чалбарда – 1500, путасында – 700 һәм манжетларда – 500».

Ә инде 1907 елда ул Бөекбритания короле Эдуард VII һәм королева Александра белән очраша. 1911 елда Лондонның барлык 28 районында да «үз патшалары» пәйда була, димәк, бу – «энҗеле монархия»! Шул ук елны аларның үз ассоциацияләре дә эшли башлый. 1926 елда бар Лондонның «энҗеле чын короле» титулы тагын Генри Крофтка бирелә. Үз тормышында әлеге шәхес 5000 фунт стерлинг акча җыя. Бу – ул чор өчен гаять зур сумма. Мәрхәмәтлек эшчәнлегенә керткән уңышлары өчен аңа бирелгән медаль һәм истәлекле тасмалар саны 200 гә җитә. Лондон башлыгы, 1928 елда Темза елгасы ташыгач, акча җыеп халыкка тапшырганы өчен дә аны медаль белән бүләкли. Генри Милли Медицина Хезмәте (NHS) оешканчы ук, госпитальләр өчен дә акча җыя.

1930 елның 1 гыйнварында 68 яшендә дөнья куя. Аның табутын музыкантлар, 400 гә якын «энҗеле король һәм королевалар», мәрхәмәт фондлары вәкилләре озата бара.

Бүген «энҗеле монархия» берничә төркемне тәшкил итә. Г.Крофт төзегән оешма 2001 елда берникадәр үзгәреш кичерә, тармаклана. Арадан 1902 елда оешкан Энҗелеләр гильдиясе – хәзер иң борынгысы дип санала. Алар, Лондон чиркәве аша, хәйрия максатларына ярыша-ярыша акча җыя. Һәр ел саен, 1875 елдагы кебек үк итеп, үз «король һәм королева»ларын сайлап кую бәйрәмен үткәрәләр һәм бу көнне бәйрәмчә киенгән халыкның кыяфәте әллә кайлардан ук ялтырап тора. Октябрь башында, Г. Крофтның туган көнендә, «энҗеле монархлар» уңыш бәйрәмен зурлый, урамнар буйлап йөреп үтә. Шул көндә җыр-биюләр, хәерчеләр өчен хәйрия акчасы җыю программасы башланып китә. Чөнки аларның девизы: «Без беркайчан да бөлмибез». Ягъни һәркемнең тормышында авыр чаклар булырга мөмкин, без моны алдан белмибез, ә мондый вакытлар җиткәнче, тормышка сөенергә, башкаларга да булышлык итәргә кирәк.

1931 елда рәхмәтле лондонлылар Генри Крофтка исә аны «энҗеле король» киемендә тасвирлаган һәйкәл дә куя. Г.Крофтның оныгының оныгы да шушы юнәлештә. «Монарх» үлгәч, нәсел дәвамчылары аның сәдәпләрен үзара бүлешә. Шулай итеп, һәрбер «король яисә королева»ның әбисеннән, әбисенең әбисеннән калган сәдәпләре бар.

«Сәдәплеләр»не Бөекбритания урамнарында һәрчак очратырга мөмкин. Алар хәтта 2012 елда, Лондонда XXX Җәйге Олимпиада уеннарын ачу тантанасында да катнашты.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА
әзерләде.

Каурый...
ашарга ярый?

"Каз канаты каурый-каурый, хатлар язарга ярый" дип җырлаган дәвер узды, хәзер каурыйны ашарга ярый башлаячак. Җирдә халык саны бик тиз арта, аксымлы ризыклар кытлыгы инде хәзер үк сизелә, киләчәктә исә бу зур проблемага әйләнергә мөмкин. Шунлыктан Швеция галимнәре ач халыкны туендыруның яңа ысулларын эзли. Лунд университеты биотехнологлары фикеренчә, кошчылык фабрикаларындагы калдыклар аксым чыганагы була ала. Ел саен бу фабрикаларда меңнәрчә тонна каурый чүплеккә ташлана. Галимнәр аларны тоз эремәсе һәм бактерияләр салынган контейнерга тутырырга тәкъдим итә. Билгеле бер температура саклангaнда, микроорганизмнар үрчи башлый һәм контейнердагы калдыклар аксымлы эремәгә әйләнә. 1 килограмм каурыйдан 900 грамм аксым алып була. Бәхеткә, швед галимнәре бу аксымны әлегә хайваннар азыгы әзерләүдә генә кулланырга ниятли, тик киләчәктә кеше ризыгына өстәү юлларын да өйрәнә.

("Die Presse").

Кайгыдан соң
куаныч яхшы

2014 елда Бөекбританиядә 25 яшьлек футболчы Рори Кертис автомобиль һәлакәтенә эләгә һәм озак вакыт комада ята. Аңына килгәндә, ул бик яхшы французча сөйләшә башлаган була. Сынчы Алонзо исә балачагында баш миен имгәтә, шунлыктан IQ күрсәткече 40-50 дән артмый, ул үзе ашый да, шнур да бәйли алмый. Әмма бу аңа дөньяда иң хөрмәтле скульпторлардан берсе саналырга комачауламый. Алонзо гаҗәеп сәләткә ия – ул теләсә нинди хайванның сынын искиткеч килештереп ясый ала, бигрәк тә ат сыннары шәп килеп чыга. Аның беренче күргәзмәсе 1986 елда оештырыла, бүген исә аның эшләре уртача 45 мең долларга бәяләнә. Тумыштан ук тиннитустан (колак шаулау) һәм гиперакузиядән (авазларны артык нечкә тоемлау) интеккән Джон Саркин, әлеге проблемалардан котылу өчен, операция ясата. Әмма операция уңышсыз булып чыга һәм Джонны инсульт бәреп ега, тик егет менә дигән картиналар яза башлый. Яңа сәләте Саркинның тормышын тамырдан үзгәртә – хәзер аның картиналары даими рәвештә галереяларга куела һәм кимендә 10 мең долларга сатыла. 1994 елда 42 яшьлек Тони Чикорияне яшен ата, янындагы шәфкать туташы ярдәм күрсәтеп өлгергәнгә генә, ул исән кала. Әкренләп савыкканда, Тониның колагында гел музыка яңгырый. Ир-ат пианино сатып ала, шундук уйнарга өйрәнә һәм көйләр яза башлый. 2007 елдан бирле үзе язган әсәрләрдән төзелгән концертлар куя. 2012 елда 22 яшьлек австралияле Бен Макмэхон каты авариягә эләгә һәм атна буе комада ята, аңына килгәч исә бик шәп итеп кытайча сөйләшә һәм укый-яза башлый. Ана теле булган инглиз телен исә берничә көннән соң гына исенә төшерә.

("The Local").

Хәерче озак яшәми

Алга киткән илләрдә уртача гомер озынлыгы һаман арта бара. Әмма XXI гасырда да бик кыска гомерле кешеләр яши торган илләр булуы аяныч. Мәсәлән, Чадта уртача гомер озынлыгы 48,52 елга, Конго Демократик Республикасында 47,42 елга тәңгәл. Соңгысы табигый ресурсларга гаять бай булса да, сәяси тотрыксызлык, инфраструктура юклыгы, йөзләрчә еллык колониаль изелү аны хәерчелек чигенә китереп җиткергән. Конго – сабыйлар арасында үлем-китем дәрәҗәсе иң югары булган илләрнең берсе. Свазилендта уртача гомер озынлыгы 47,36 ел тәшкил итә, биредә халыкның 26 проценты ВИЧ-инфекцияле. Әфганстанда халык уртача 47,32 ел, Замбиядә – 46,93 ел, Гвинея-Бисауда 46,76 ел яши. Соңгысында илдәге 100 мең кешегә 5 табиб туры килә, халыкның 9 проценты малярия белән йогышланган. Зимбабведа уртача гомер озынлыгы 46,59 елга тәңгәл.

("The Washington Post").

Бельгиядәге мини-Европа

Брюссельнең төньягындагы "Мини-Европа" – Бельгия башкаласындагы иң истәлекле урыннардан берсе. Анда ел саен 350 мең кунак була. Өч футбол кыры кадәр мәйданда Европаның 80 шәһәрендәге йөзләрчә данлыклы бинаның төгәл күчермәләре урнаштырылган. Алар барысы да бик җентекләп, тик 25 тапкыр кечерәйтеп эшләнгән. Мәсәлән, 324 метрлы Эйфель манарасы – 13 метрлы. Паркта Париждагы Триумф аркасы һәм Изге Ана соборы, Бранденбург капкасы һәм Берлин дивары, Афина Акрополе һәм Пиза манарасы, Венециядәге Дожлар сарае һәм Лондондагы Парламент (Биг-Бен белән бергә) бинасы, Һолландиядәге җил тегермәннәре һәм Төньяк диңгездәге нефть платформасы макеты бар. Везувий вулканы һәм Жак-Ив Кусто корабле кебек котелмәгән экспонатлар да шактый. Брюссельдәге Гран-Плас макетын ясау 350 мең еврога төшкән. Паркны бөтен Европа бергә төзегән: мини-Парижны – Франция, немец ядкәрләрен Германия, антик биналарны Италия акчасына салганнар. Эстония Таллинндагы "Юан Маргарита" манарасын, Латвия – Ригадагы Бәйсезлек һәйкәле күчермәсен, Литва – Вильнюс университеты кампусы миниатюрасын төзеп биргән.

("Der Spiegel").

Бар байлыгым – шул күлмәгем...

Датта Пхудж – үзенең бер елда эшләгән акчасының өчтән берен алтын күлмәккә сарыф итеп дан казанган һинд эшкуары. Унбиш зәркәнче ике атна буе "теккән" күлмәкнең авырлыгы 3,5 килограмм, өстәмә бизәнү әйберләре – муенса- беләзек-балдаклар тагын 6,5 килограмм тәшкил итә. Датта – финанс брокеры, хатыны – сәясәтче. Кемдер зиннәтле йорт сатып ала, кемдер затлы автомобильләр белән мавыга, ә менә Даттаның алтын күлмәк киясе килгән. 14 мең алтын таҗ яфракчыгы һәм 100 мең алтын ялтыравык ак вельвет тукымага тегелгән, алты төймәсе Сваровски кристалларыннан ясалган күлмәкнең бәясе 230 мең доллар чамасы. Датта бик ярлы гаиләдә туып-үскән, байлыгын үз көче белән туплаган. Аннары ул туганнарыннан ваз кичкән, алар белән бөтенләй аралашмаган. 2018 елда, 48 яшьлек чагында, Бомбейдан 150 чакрым ераклыктагы Пуна шәһәрендә дустының туган көненә килгәндә, бай эшкуарга һәм аның егерме яшьлек улына дистәдән артык ир-ат һөҗүм иткән һәм Даттаны таш атып үтергән. Улына тимәгәннәр, исән калдырганнар.

("Fishki.net").



Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

1 август

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

6.00, 7.10 «Манзара». 6+
7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «УЕННАН УЙМАК». 12+
10.00, 0.50 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА». 16+
11.00 «Татар халык җырлары».
11.30, 21.00 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 0.00 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Семь дней». 12+
14.00 «Заповедники РФ». 12+
14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
15.15 «Акыл батл».
16.00 «Переведи!» 6+
16.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Әдәби хәзинә». 6+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
22.00 Бөтендөнья татар конгрессының YIII съезды ачылышы.

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.25 «Кояшларың белән кил син миңа». 6+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Заман көзгесе». 6+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Фатыйх Хөсни турында телеочерк. 6+
15.30 «Ватандашлар». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
18.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 23.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
21.25 «Бөтендөнья татар конгрессының YIII пленар утырышы». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ДЕРЕВЕНСКИЙ РОМАН». 12+
10.20, 21.00 «ВЕРЬ МНЕ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ВАСИЛИСА». 12+
14.35 «Вместе по России». 12+
15.00 «Это лечится». 12+
15.30 «Трудовой фронт Великой Отечественной». 12+
16.15 «Кошечки-собачки».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 0.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ОТЧИМ». 16+
23.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.55 «СОФИЯ». 16+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.00, 12.20 «Забытое ремесло».
7.15 Черные дыры. Белые пятна.
8.00 Легенды мирового кино.
8.25 «МАРИОНЕТКИ».
10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
10.15 Красуйся, град Петров! Зодчие Андрей Воронихин, Александр Постников, Самсон Суханов. Горный институт.
10.45 Academia. Эрик Галимов. «Для чего мы исследуем Луну».
11.35 Искусственный отбор.
12.35, 21.15 «ПУТЕШЕСТВИЕ».
14.30 «Эрмитаж».
15.05 «Испания. Теруэль».
15.35, 23.50 «СЛЕДСТВИЕ ВЕДУТ ЗНАТОКИ».
17.10 Цвет времени. Анатолий Зверев.
17.25 «Осовец. Крепость духа».
18.10 К 90-летию Владимира Федосеева. И. Брамс. Симфония №4. Владимир Федосеев и БСО им. П.И. Чайковского.
19.00 Письма из провинции.
19.45 К 90-летию Владимира Федосеева. «Монолог в 4-х частях».
20.15 «Спокойной ночи, малыши!»
20.30 «Монолог балетмейстера».
23.10 Цвет времени. Эдвард Мунк. «Крик».

«НТВ»

5.00 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА». 16+
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
19.50 «ДЕСАНТ ЕСТЬ ДЕСАНТ». 16+
21.40 «ПОД НАПРЯЖЕНИЕМ». 16+

Сишәмбе

2 август

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «УЕННАН УЙМАК». 12+
10.00, 0.50 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА». 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
11.15 «Память сердца». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 0.00 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 6+
14.00 «Путь». 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
15.15 «Төймә».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Казаннан - казанга». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Кучтәнәч».
21.00 Бөтендөнья татар конгрессы YIII съездының пленар утырышы.

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40 «Туган җир». 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Йөрәктән - йөрәккә». Рәфкать Бикчәнтәев турында телеочерк. 6+
15.30 «Тамчы-шоу». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Бөтендөнья татар конгрессының YIII пленар утырышы». 6+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ДЕРЕВЕНСКИЙ РОМАН». 12+
10.30, 21.00 «ВЕРЬ МНЕ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ВАСИЛИСА». 12+
14.35 «Вместе по России». 12+
15.00 «Не факт». 12+
15.30 «Трудовой фронт Великой Отечественной». 12+
16.15 «Кошечки-собачки».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 0.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ОТЧИМ». 16+
23.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.55 «СОФИЯ». 16+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.00 «Другие Романовы». «Узник крови».
7.30 «Аксаковы. Семейные хроники».
8.10 Легенды мирового кино.
8.40 «ЧЕЛОВЕК ИЗ РЕСТОРАНА».
9.50 Цвет времени. Жорж-Пьер Сёра.
10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
10.15 Красуйся, град Петров! Зодчий Джакомо Кваренги. Смольный институт благородных девиц.
10.45 Academia. Эрик Галимов. «Для чего мы исследуем Луну».
11.35, 20.35 Искусственный отбор.
12.20 «Забытое ремесло».
12.35, 21.15 «ПРЕКРАСНЫЙ НОЯБРЬ».
14.15 «Первые в мире».
14.30 «Эрмитаж».
15.05 «Влюбиться в Арктику».
15.35, 23.50 «СЛЕДСТВИЕ ВЕДУТ ЗНАТОКИ».
17.05 «Русский театр».
18.05 К 90-летию Владимира Федосеева. П.И. Чайковский. Симфония №4. Владимир Федосеев и БСО им. П.И. Чайковского.
19.00 Письма из провинции
19.45 К 90-летию Владимира Федосеева. «Монолог в 4-х частях».
20.15 «Спокойной ночи, малыши!»
23.00 «Испания. Теруэль».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА». 16+
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
19.50 «ДЕСАНТ ЕСТЬ ДЕСАНТ». 16+
21.40 «ПОД НАПРЯЖЕНИЕМ». 16+

Чәршәмбе

3 август

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «УЕННАН УЙМАК». 12+
10.00, 23.00 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00, 0.40 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия». 6+
14.15 «Территория Мира». 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Туган авылым». 6+
21.00, 23.50 «Соотечественники». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
9.40 «Ачыктан - ачык». 12+
10.30, 20.30 «Юлчы». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Йөрәктән - йөрәккә». Илдар Кыямов турында телеочерк. 6+
15.30 «Яшьләр тукталышы». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ДЕРЕВЕНСКИЙ РОМАН». 12+
10.30, 21.00 «ВЕРЬ МНЕ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ВАСИЛИСА». 12+
14.35 «Вместе по России». 12+
15.00 «Это лечится». 12+
15.30 «Трудовой фронт Великой Отечественной». 12+
16.15 «Кошечки-собачки».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 0.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ОТЧИМ». 16+
23.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.55 «СОФИЯ». 16+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.00 «Другие Романовы». «Наука царствовать, или Мамина дочка».
7.30 «Аксаковы. Семейные хроники».
8.10 Легенды мирового кино.
8.40 «БЕЛЫЙ ОРЕЛ».
9.50 Цвет времени. Пабло Пикассо. «Девочка на шаре».
10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
10.15 Красуйся, град Петров! Зодчий Вениамин Стуккей. Особняк Казалета-Тенишевых.
10.45 Academia. Константин Скрябин. «Геном как книга».
11.35, 20.35 Искусственный отбор.
12.20 «Забытое ремесло».
12.35, 21.15 «ДОРОГОЙ ПАПА».
14.30 «Эрмитаж».
15.05 «Влюбиться в Арктику».
15.35, 23.50 «СЛЕДСТВИЕ ВЕДУТ ЗНАТОКИ».
17.05 «Русская живопись».
18.00 К 90-летию Владимира Федосеева. Д. Шостакович. Симфония №5. Владимир Федосеев и БСО им. П.И. Чайковского.
19.00 Письма из провинции. Свияжск (Республика Татарстан).
19.45 К 90-летию Владимира Федосеева. «Монолог в 4-х частях».
20.15 «Спокойной ночи, малыши!»
23.10 Цвет времени. Леон Бакст.

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА». 16+
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
19.50 «ДЕСАНТ ЕСТЬ ДЕСАНТ». 16+
21.40 «ПОД НАПРЯЖЕНИЕМ». 16+

Пәнҗешәмбе

4 август

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «УЕННАН УЙМАК 2». 12+
10.00, 23.00 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
14.15 «Женское счастье». 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
18.00 «Юлчы». 6+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Ватандашлар». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Кунак БИТ Шоу». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 20.00 «Рухының - үз күге». Равил Фәйзуллин турында телеочерк. 6+
15.30 «Халкым минем». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «ДЕРЕВЕНСКИЙ РОМАН». 12+
10.30, 21.00 «ВЕРЬ МНЕ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ВАСИЛИСА». 12+
14.35 «Реки России». 12+
15.00 «Клинический случай». 12+
15.30 «Первая Мировая». 12+
16.30 «Кошечки-собачки».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
20.00 «НАУЧИ МЕНЯ ЖИТЬ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 0.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ОТЧИМ». 16+
23.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.55 «СОФИЯ». 16+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Пешком...»
7.00 «Другие Романовы». «Теория заговора».
7.30 «Аксаковы. Семейные хроники».
8.10 Легенды мирового кино. Анатолий Кторов.
8.35 «ПРАЗДНИК СВЯТОГО ИОРГЕНА».
10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
10.15 Красуйся, град Петров! Зодчий Карл Росси. Михайловский дворец.
10.45 Academia. Константин Скрябин. «Геном как книга».
11.35, 20.35 Искусственный отбор.
12.20, 21.15 «СЕМЬЯ».
14.30 «Эрмитаж».
15.05 «Влюбиться в Арктику».
15.35, 23.50 «СЛЕДСТВИЕ ВЕДУТ ЗНАТОКИ».
17.15 «Любовь и больше, чем любовь».
18.10 К 90-летию Владимира Федосеева. Л. Бетховен. Концерт №5 для фортепиано с оркестром. Владимир Федосеев и БСО им. П.И. Чайковского.
19.00 Письма из провинции.
19.45 К 90-летию Владимира Федосеева. «Монолог в 4-х частях».
20.15 «Спокойной ночи, малыши!»

«НТВ»
4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА». 16+
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
19.50 «ДЕСАНТ ЕСТЬ ДЕСАНТ». 16+
21.40 «ПОД НАПРЯЖЕНИЕМ». 16+

Җомга

5 август
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 15.15 «УЕННАН УЙМАК 2». 12+
11.00 «Нәсыйхәт». 6+
11.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 6+
14.15 «Классный час». 12+
14.45 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
17.00 «Бәллүр каләм - Хрустальное перо-2022».
19.00 «Болгар радиосы» концерты. 6+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00 «Юлчы». 6+
23.00 «ЛЮБОВЬ БЕЗ ПЕРЕСАДОК». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 12+
9.40, 15.30 «Нәсыйхәт». 6+
10.30 «Казаннан казанга». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Татарлар». 12+
12.05 «Әдәби галәмгә тәрәзә...» Фәрваз Миннуллин турында телеочерк. 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 0.40 «Калеб». 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10 «Туган җир». 12+
19.35 «Заман көзгесе». 6+
20.05, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «НАУЧИ МЕНЯ ЖИТЬ». 16+
10.30, 21.00 «ВЕРЬ МНЕ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.45 «МЕНЯЮЩИЕ РЕАЛЬНОСТЬ». 16+
15.00 «Не факт». 12+
15.30 «Первая Мировая». 12+
16.30 «Кошечки-собачки».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15 Информационный канал. 16+
18.40 «Человек и закон».
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 «Две звезды. Отцы и дети». 12+
23.40 «Двое. Рассказ жены Шостаковича». 12+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «САЛЮТ-7». 12+
23.30 «КАНДАГАР». 16+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Пешком...»
7.00 «Другие Романовы». «Августейшая сестра милосердия».
7.30 «Литераторские мостки», или Человек, заслуживший хорошие похороны».
8.10 Легенды мирового кино.
8.35 «НАСРЕДДИН В БУХАРЕ».
10.00, 15.00, 19.30, 23.00 Новости культуры.
10.15 Красуйся, град Петров! Зодчие Егор Соколов, Аполлон Щедрин, Василий Собольщиков, Иван Горностаев. Императорская Публичная библиотека.
10.45 «Завод».
11.45 Искусственный отбор.
12.30, 23.20 «ЧЕЛОВЕК С ЗОЛОТОЙ РУКОЙ».
14.30 «Эрмитаж».
15.05 «Влюбиться в Арктику».
15.35 «СЛЕДСТВИЕ ВЕДУТ ЗНАТОКИ».
17.35 Цвет времени. Илья Репин. «Иван Грозный и сын его Иван».
17.50 90 лет Владимиру Федосееву. Шедевры мировой оперы. Владимир Федосеев и БСО им. П.И. Чайковского.
19.45 90 лет Владимиру Федосееву. Линия жизни.
20.40 «ИНСПЕКТОР ГУЛЛ».

«НТВ»
4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА». 16+
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
19.50 «ДЕСАНТ ЕСТЬ ДЕСАНТ». 16+
21.45 «ЛОВУШКА». 16+
23.25 Концерт «Живи спокойно, страна!»

Шимбә

6 август
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 6+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 «Татар халык җырлары».
11.30 «Казаннан - казанга». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 «Әсхәт Хисмәтовның 70 яшьлек юбилей кичәсе». 6+
16.00 «Туган җир». 12+
16.30 «Цирк завтрашнего дня». 6+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Соотечественники». 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБит- шоу». 12+
23.00 «ОДНОКЛАССНИЦЫ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Идрис Газиев тәкъдим итә. Бормалы су. З.Хәбибуллин». 6+
7.00, 15.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 Спектакль «Казан егетләре».
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 Зөфәр Хәйретдиновның 60 яшьлек юбилей кичәсе. 6+
23.20 «Тукран тәүбәсе». «Мунча ташы» спектакле. 16+

«ЭФИР»
5.00 «Опыты дилетанта». 12+
5.30 «Вместе по России». 12+
6.30 «Клинический случай». 12+
7.00 «Четверо в кубе».
7.30 «Сказочный патруль».
8.00 «Путеводитель по вселенной». 12+
8.30 «УБИЙСТВО НА ТРОИХ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «2040: БУДУЩЕЕ ЖДЕТ». 6+
14.30 «Реки России». 12+
15.00 «Инвиво». 12+
15.30 «ВЕЧНЫЙ ОТПУСК». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «АВГУСТ». 12+
23.00 «КОГДА ЗОВЕТ СЕРДЦЕ 5». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «Поехали!» 12+
11.10, 12.15 «Видели видео?»
13.40 «В ЗОНЕ ОСОБОГО ВНИМАНИЯ». 12+
15.35 «ОСВОБОЖДЕНИЕ». «НАПРАВЛЕНИЕ ГЛАВНОГО УДАРА». 12+
18.20 «На самом деле». 16+
19.25 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.35 «Сегодня вечером». 16+
23.15 «ПЕРВЫЙ УЧИТЕЛЬ». 12+

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
12.00 «Доктор Мясников». 12+
13.05 «Я ВСЁ ПОМНЮ». 12+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «ВТОРОЙ ШАНС». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
8.05 «ВТОРОЕ ДЫХАНИЕ».
10.15 «Передвижники. Николай Ге».
10.45 «ДОРОГА К МОРЮ».
12.00 «Дом ученых». Дмитрий Тетерюков.
12.30 Диалоги о животных.
13.15 «Монолог балетмейстера».
14.00 Легендарные спектакли Мариинского. Балет А. Чайковского «Ревизор».
15.45 «Энциклопедия загадок».
16.10 «Мировая литература в зеркале Голливуда».
17.00 «СТРАННАЯ ЛЮБОВЬ МАРТЫ АЙВЕРС».
19.00 «Анастасия».
19.55 Цвет времени. Ван Дейк.
20.05 К 100-летию российского джаза. Линия жизни. Виктор Фридман.
21.00 «В ЧЕТВЕРГ И БОЛЬШЕ НИКОГДА».
22.30 Опера «Упражнения и танцы Гвидо».

«НТВ»
4.35 «ДЕЛЬТА». 16+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!»
9.25 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.05 «Однажды...» 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
19.35 «ДЕСАНТ ЕСТЬ ДЕСАНТ». 16+
22.30 «Маска». 12+

Якшәмбе

7 август
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Яшәү яме». Сиринә Зәйнетдинова. 6+
8.00 «Адымнар». 12+
8.30 «Туган авылым». 6+
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». 12+
11.00 «Сула!» Ришат Төхвәтуллин. 6+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Галиҗәнап шагыйрь». 6+
13.30 Марат Мухин хитлары. 6+
16.00 «Ком сәгате». 12+
17.00 «Видеоспорт». 12+
17.30 «Соотечественники». 12+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 12+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
23.00 «ЧТО ГЛОЖЕТ ГИЛБЕРТА ГРЕЙПА». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 6+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Йөрәктән-йөрәккә». Лирон Хәмидуллин турында телеочерк. 6+
7.00 «Очрашулар эзләп» Габделфәт Сафин концерты. 6+
9.00, 22.45 «Йөрәктән-йөрәккә». 6+
10.00 «Юлчы». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.45 «Туган авылым». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 12+
13.00 Спектакль «Тагын Казан егетләре».
15.05 «Йөрәк җылысы». Филүс Каһиров концерты. 6+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 12+
20.00 «Семь дней». 12+
21.10 «Өмет йолдызы». Эльмира Кәлимуллина концерты. 6+

«ЭФИР»
5.00 «Опыты дилетанта». 12+
5.30 «Вместе по России». 12+
6.00 «Реки России». 12+
6.30 «Не факт». 12+
7.00 «Четверо в кубе».
7.30 «Сказочный патруль».
8.00 «Инвиво». 12+
8.30 «ВЕЧНЫЙ ОТПУСК». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «АВГУСТ». 12+
15.00 «Путеводитель по вселенной». 12+
15.30 «УБИЙСТВО НА ТРОИХ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «2040: БУДУЩЕЕ ЖДЕТ». 6+
22.35 «ВНЕ ВРЕМЕНИ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.05, 6.10 «ОТЧАЯННЫЕ». 16+
6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
7.00 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.45 «Часовой». 12+
8.15 «Здоровье». 16+
9.20 «Непутевые заметки».
10.15 «Парни «с Квартала». 16+
11.20, 12.15, 18.20 «АНДРЕЕВСКИЙ ФЛАГ». 16+
21.00 «Время».
22.35 «ВЫБОР АГЕНТА БЛЕЙКА». 12+

«РОССИЯ»
5.35 «ПОЛЫНЬ ТРАВА ОКАЯННАЯ». 12+
7.15 «Устами младенца».
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
12.00 «Доктор Мясников». 12+
13.05 «Я ВСЁ ПОМНЮ». 12+
18.00 «Песни от всей души». 12+
22.00 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Энциклопедия загадок».
7.05 Мультфильмы.
8.05 «ИНСПЕКТОР ГУЛЛ».
10.25 «Обыкновенный концерт».
10.55 «В ЧЕТВЕРГ И БОЛЬШЕ НИКОГДА».
12.25 «Первые в мире».
12.40 Диалоги о животных.
13.25 Виктор Захарченко и Государственный академический Кубанский казачий хор.
14.40 «Кубанские казаки». А любовь девичья не проходит, нет!»
15.20, 23.20 «КУБАНСКИЕ КАЗАКИ».
17.10 «Что на обед через сто лет».
17.55 «Пешком...»
18.25 Острова. Вадим Коростылев.
19.10 «Романтика романса».
20.05 «ВАШ СЫН И БРАТ».
21.35 Большая опера.

«НТВ»
4.35 «ДЕЛЬТА». 16+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
12.00 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.00 «Своя игра».

Кадак каккан күкрәккә

Сәрхушләр җыелып эчү өчен урынны һәрчак таба. Әлмәттә яшәүче Сиринә ханым күршесендә дә шундый бер фатир бар. Анда 1966 елгы Э.Сабиров тора. Әтисе исән чакта тыныч була, ике ел чамасы элек Рифкать карт вафат булгач, Эдуард айнымыйча эчә башлый, ялгызак абзый торагын эчкечеләр дә үз итә. Йомшаграк итеп әйтсәк, бик ышанычлы булмаган затлар күңел ача торган урында хәвеф-хәтәр килеп чыгу ихтималы арта.

Быел 7 мартта да анда хәмерле мәҗлес баруын сизә күршеләр, чөнки әллә ни тавышланмасалар да, кычкырып сөйләшкәннәре, ыгы-зыгы килүләре ишетелә. Кичкә таба Сиринә ханымның 16 яшьлек кызы Адилә (кайбер исемнәр үзгәртелә) урамга җыена, ләкин подъезддан кире әйләнеп кереп, андагы йолкыш кыяфәтле исерек «мужик»тан куркуын әйтә. Әлбәттә, әни кеше аны озата чыга һәм син кем, монда нишләп торасың дип, теге бәндәдән сорау алырга керешә. Әмма анысы ярым-йорты сүзләр мыгырдап, Эдуард фатирына юнәлә, чая ханым, мәсьәләгә ачыклык кертү ниятеннән, аның артыннан иярә.

Ике бүлмәле фатирга узгач та, шикләнә калып, Адиләгә урамда көтеп торучы егете Никитаны чакырырга куша, чөнки залдагы өстәл артында тагын бер ир уртасы кеше, утыз яшьләрендәге хатын-кызны да күргәч, ошбу исерекләрдән барысын да көтәргә була дип уйлый, шулай да «притон», «бардак » оештырган юньсезләрне пыр туздырып ачуланырга керешә. Ошбу хәлне көтмәгән кунаклар, чәркәләрне дә бушатып тормыйча, китәргә кузгалалар. Ул арада Сиринә йокы бүлмәсе идәнендә яткан хатын-кызны шәйләп, аның куллары суынган, йөрәк тибеше юк, ягъни җансыз икәнен ачыкларга өлгерә. Ошбу мәхшәрне кунак хатын-кыз да күрә, ә ике ир заты күз ачып йомганчы юкка чыга, лаякыл хуҗа исә йокы симертә.

Полиция эксперты өлкән яшьтәге хатын-кызның үз үлеме белән дөнья куймавын шунда ук ачыклый. Мәрхүмәнең муенындагы, кешенең буылуын раслаучы «буразна», күкрәгенең сул ягындагы яра, тәгәлрәге, сизелер-сизелмәс тишек моны раслый. Соңрак үткәрелгән экспертиза сул үпкәне җәрәхәтләү, күкрәк куышлыгына кан җыелуга китергән, соңгысы үлемгә сәбәпче булган дип белдерә. Ике көннән моның карчык күкрәгенә йөзле, ягъни 10 см озынлыктагы кадак кагу нәтиҗәсе икәне дә мәгълүм була.

Э. Сабиров беренче көнне аңлатма бирерлек хәлдә булмый, айныгач та мәрхүмәнең кем булуын да әйтә алмый, бары тик шул якларда яшәүче Зоя атлы әби икәнен җиткерә. Үле килеш табылуына ике тәүлек дигәндә, аның 1952 елда туган З.Кузнецова икәнe ачыклана. Зарар күрүче итеп билгеләнгән 34 яшьлек улы әнисенең эчәргә һәвәслеген, салмыш баштан ызгыш чыгара торган гадәте булуын яшерми. Шуңа күрә аның Э.Сабиров фатирына килеп әләгүенә дә гаҗәпләнергә туры килми, ләкин хуҗага ияреп кайтмый ул анда, ә бәлки 42-43 яшьләрендәге Марина һәм Владислав атлы эчкече сукбайлар белән килеп керә. Э. Сабировтан бу хакта ишеткәч тә оперативниклар иң әүвәл аларны эзләп таба. Марина һәм Сиринә ханымга юлыккан яшьрәк ир белән хатын-кызның үтерүгә катнашы булмавы тиз ачыклана, ә подъездда күршеләргә шом индереп торган Владислав Кустовскийның гаебе шик уятмый.

Шаһитлар күрсәтмәләре генә түгел, 1979 елгы ошбу кешенең үткән тормышы һәм хәзерге яшәү рәвеше дә икеләнергә урын калдырмый. Шул районда Рус Акташы авылында туып-үскән В.Кустовский Зәйдә торучы хатыны, мөстәкыйль яшәүче балалары, аз санлы туганнары белән аралашмавын әйтә. Башлыча, урлау, талау кебек җинаятьләре өчен сигез мәртәбә хөкем ителгән, барлыгы 17 ел гомерен колониядә уздырган йөремсәк угры ул. Чөнки Чиләбе өлкәсендәге Карталы шәһәре, Әлмәт, Ижау, Зәй, Чаллы судлары алдында җавап тоткан, соңгы хөкемен үтәп узган ел азагында гына азат ителгән. Әлбәттә, акылга утырмаган, яшәр урыны булмаган, хәтта паспортын да югалткан ир-ат бергә эчкән шешәдәшләре торагында куна, аларның да кубесе үзе кебекләр булганга подъезд, подвалларда йоклаган чаклары да була, кыскасы эчкече сукбайлар кебек яши, әйтүенчә, хәмерлек акчаны үткән-сүткәннәрдән соранып юнәтә, нефтьчеләр каласында тормыш төбендәгеләргә мәрхәмәтле кешеләр күбрәк, күрәсең.

7 мартта көндез шул ук ысул белән тапкан аракыны кыстырып, Э.Сабиров фатирында пәйда була ул. Шешәнең төбенә төшкәч, анда утыруның мәгънәсе калмый, кала урамнарын буйларга, эчәргә җай чыгарырга кирәк була. Шактый гына йөргәннән соң, аларның сөйгәне Марина белән юллары кисешә. Ошбу 1978 елгы ханым республиканың икенче почмагындагы Яшел Үзән каласыннан, әйтүенә караганда, Әлмәткә дүрт-биш ай элек танышлары янына кунакка килә дә кире китми. Төпләнеп кала дисәк, хак булмас, чөнки даими торагы булмаганга яңа таныш-белешләр янында кунып йөри. «Пятерочка» кибетендә җыештыручы булып йөрүче Зоя түтине дә яхшы белә, чөнки бергәләп эчкән чаклары була, ә ике ай чамасы элек яңа төрмәдән кайткан В.Кустовский белән дуслашып китә. «Ул мине, мин аны ошаттым, арабызда романтик мөнәсәбәтләр урнашты, бергә яшәгән чакларыбыз да булды», – дип сөйли Марина Баламутко. Ул көнне дә ир затын колач җәеп каршылый Марина, сагынуын да әйтә, өч-дүрт көн айный алмавыннан зарлангандай да итеп куя. Ә иң мөһиме, үзе белән аракы булуын әйтеп куандыра. Шул рәвешле, алар эчү генә түгел, еш кына кунып та йөргән Эдуард фатирына юнәләләр. Гөнаһ шомлыгына каршы димичә булмый, кибет янында Зоя әби Кузнецованы очратып, аны да үзләре белән алалар.

Болай да салмыш хуҗа абзый, тиз исереп, күрше бүлмәдәге диванда йокларга түнә. Шул арада әче телле карчык белән ир уртасы кеше арасында низаг чыга. Владислав төрмәчеләр кануннары, ягъни «понятие» буенча дөрес яшәүче зат булarak, миңа атап кычкырылган кимсетүле сүзләргә түзеп тора алмадым, аңа жәза бирергә, ягъни үтерергә карар кылдым, ди. Калганын ул сөйләгәннәр буенча сурәтлик. Шул нияттән, чалбарының тасмасын тартып алып, корбанының муенына урый, шул баудан тартып чалкан егылган карчыкны йокы бүлмәсенә өстерәп кертә, муенына аягы белән баса, канга буялган кроссовкасын су белән сөртеп ала, ләкин хәл эчендәге кешенең әле исән икәнен чамалап, үзе әйтмешли, башлаган эшне ахырына кадәр җиткерергә уйлап, кадак ала, комачауламасын өчен күлмәген өскә күтәреп күкрәген ача да очлы әйберне йөрәк турысына куя, йодрыгы белән сугып, чытырдатып эчкә кертә. Үтерү коралы булып хезмәт иткән төп «вещдок» соңрак залдагы өстәл астында табыла.

Әлеге күрсәтмәләрне төп шаһит Марина да раслый. Аеруча мөһим эшләр буенча тикшерүче Раил Зарипов аларны кара-каршы утыртып сорау ала, күрсәтмәләре бер-берсеннән аерылмый. М.Баламутко кадаклы мәхшәрне күрми, чөнки теге явызны тынычландыра алмагач, куркып алданрак чыгып кача. Ә Кустовский, әйтүенчә, үзен «агарту» йөзеннән мәрхүмәнең күлмәген рәтли, пәлтәсен киdерә, иңенә сумкасын элеп куя да урамга чыга һәм шул тирәдәге ташландык бинада сыйланучы сәрхушләргә кушыла. Әлбәттә, юньле кеше булмый анда. Соңрак Эдуард Сабиров фатирында күршеләр күзенә чалынган 1987 елгы Дмитрий Чистай кешесе, әйтүенчә, Әлмәткә эш эзләп килеп сукбайлыкка чыккан зат. Габдрахман авылыннан 31 яшьлек Алиса да эчәргә хирыс, юкса үзе кебек салмыш егете белән җимерек йортта ирләр белән сыра чөмереп тормас иде. 60 яшьләрендәге тагын бер бомж һәм Малыш кушаматы йөртүче В.Кустовскийны өстәгәч, барлыгы биш кеше була анда. Владислав шешәләр бушагач Э.Сабиров фатирында калган аракыны эчәргә тәкъдим итә. Аңа Чистай малае Дима һәм Алиса иярә.

Ул чакта Эдуард абзый сусап уянган, шул бүлмәдә яткан мәетне атлап залга чыккан була. Әйтүенчә, Зоя карчыкны исереп йоклап ята дип уйлый. Килеп кергән өч кунак белән бер чәркәне каплагач та тагын йокыга тала ул. Чистай егете исә йокы бүлмәсендә яткан гәүдәне күрә, аның янына килеп җансыз икәнен ачыклый һәм Владиславтан «Кем?» – дип сорый. «Мин» – дигән җавапны ишеткәч, ягъни сыйланырга чакырган бәндә кеше үтерүен танығач, тавыш чыгара. Әлбәттә, иң беренче чиратта, үзенә мәшәкать чыгачагын аңлый ул. Озын буйлы егеттән шүрли калган Кустовский киенеп подъездга чыга һәм безгә мәгълүм булганча, күршеләр игътибарын җәлеп итә.

Владислав эз суытырга уйламый, икенче көнне дә шул тирәләрдә буталып йөри һәм Маринаны очратып куя. Сүз алдагы кич хәлләре турында бара, билгеле. Влад үзенә бик авыр икәнен белдерә һәм тынычлану өчен аракы алуын үтенә. Шул рәвешле, 8 март көнне гашыйк сукбайлар соңгы очрашуларын билгеләп үтәләр. Икенче көнне аларны полиция тоткарлый. В. Кустовский шунда ук гаебен танып, кыскача әйткәндә, әбинең йөрәгенә кадак кагуын әйтеп беркетмә төзи, чөнки аның йөрәккә түгел, үпкәгә эләгүен белми.

Тикшерү комитетының Әлмәт бүлегенең аеруча мөһим эшләр тикшерүчесе Р.Р.Зарипов аңа аңлы рәвештә кеше үтерүдә гаепләү белдерә. Чөнки психиатрлар экспертизасы үз гамәлләрен аңламаслык хәлдә булмаган дип белдерә. Әлеге тикшерену нәтиҗәләрендә В.Кустовскийның ярдәмче мәктәптә укуы, психиатрда исәптә торуы, эчкечелекнең аның рухи халәтенә тискәре йогынты ясавы һәм башка кимчелекләре дә күрсәтелә. Аның күрсәтмәләрендә дә акылга тулылыгын шик астына алырлык сәер фикерләр очрап куя. Әйтик, хәлсез карчык җанын кыюын, үзе әйтмешли, «зона» законнарын үтәү итеп күрсәтә. Аның кебекләр гадәттә, гаебен киметергә тырышса, ул, кеше кыдган гамәлләре өчен закон каршында җавап тотарга тиеш дип, барысын да үз өстенә өя, гомумән, мондый үзенчәлекле ысул белән үтерүченең аң-фикер дәрәҗәсе икеләндермичә калмый бит инде. Хөкем утырышларында бу мәсьәләгә адвокат басым ясады, хөкем ителүчегә кабат психиатрик экспертиза үткәрүне сорады. Сирәк була торган хәл, хөкемдар аның ошбу үтенечен канәгатьләндерде һәм утырышларны туктатып торырга карар бирде, күрәсең, ул да Кустовскийның холык-фигыльләндәге сәерлекләргә игътибар иткән. Гаепләү ягы исә психиатрия белгечләренең фикере үзгәрер дип санамый. В.Кустовский хәзер Уфадагы сырхауханәдә ятып тикшерену уза. Табибләр нәтиҗә ясаганнан соң, хөкем утырышлары дәвам иттереләчәк.

Наил ВАХИТОВ.

«Сугыш һәм тынычлык»

Россиянең халык рәссамы, профессор, И.Репин исемендәге сәнгать академиясе укытучысы, Россия сәнгать академиясе академигы Александр Быстров һәм аның укучылары, И.Репин исемендәге дәүләт сәнгать академиясенең монументаль сәнгать остаханәсен тәмамлаган рәссамнар: Роман Абдуллин, Чермен Гугкаев, Марат Кесаев, Сергей Некрасов әсәрләреннән гыйбарәт яңа күргәзмә «Хәзинә» милли сәнгать галереясында август уртасына кадәр эшли. Роман Абдуллин иҗатын былтыр газетабызның май санында яктырткан идек. Ниһаять, татарстанлылар аның картиналары белән шәхсән соклана ала. Күргәзмә моңа кадәр Санкт-Петербургта, Мәскәүдә һәм Екатеринбургта зур уңыш белән узды.

А.К.Быстров – студентлары монументалист-рәссамнар булсын өчен күп көч салучы педагог, ул аларны чын ватанпәрвәрләр булырга да өнди. Аның кичәге студентлары – инде югары профессионализмга ия иҗатчылар, күптөрле һөнәри бүләк иясе. 34 яшьлек Чермен Гугкаев Санкт-Петербург дәүләт университетында укыта, Россия сәнгать академиясенең көмеш медаленә, Россия Рәссамнар берлегенең «Духовность. Традиции. Мастерство» алтын медаленә лаек. 37 яшьлек Марат Кесаев – шушы ук медальләр иясе. 39 яшьлек рәссам Сергей Некрасов мондый бүләкләрдән тыш, 2021 елда «Гаилә – Россия жаны» Бөтенроссия бәйгесендә җиңгән. Әңгәмәдәшем – 30 яшьлек талантлы рәссам, Татарстан Рәссамнар берлеге әгъзасы Роман Абдуллин исә 2021 елда Россия сәнгать академиясенең алтын медале һәм «Духовность. Традиции. Мастерство» алтын медале белән бүләкләнде. 2021 елдан башлап, үзе тәмамлаган академиядә укыта. Барлык рәссамнарның да әсәрләре илебездән кала, чит дәүләтләрдә дә саклана. «Һәр рәссамның төп иҗади темасы була. Мин менә бик кечкенәдән рәсем ясыйм, шул чакта ук инде дошманны бомбага тотучы совет очкычларын сурәтли идем, – диде Роман Фарист улы әңгәмәбез барышында. – 1990 елларда туган безнең буын өчен патриотизм темасы актуаль түгел иде, әмма безнең нәселдә дә сугышта катнашучылар бар... Менә дәү әтиемнең абыйсы Феогент Карнаухов сугыш турында сөйләргә яратмады, төгәлрәге, безгә, балаларга, бөтенләй сөйләмәде. Минем өчен Бөек Ватан сугышы хакындагы гаилә хатирәләре чыганагы дәү әтием Иван Самойлович булды. Феогент Самойлович вафат булгач кына, ул аның 1943 елда Харьков янындагы сугышта каты яраланган булганы хакында әйтте. Алар бик зур кукуруз басу аша үткәннәр һәм аны чыкканда фашист пулеметчылары утына эләккәннәр, взводтан нибары берничә генә кеше исән калган. Шулчак командир аңа танкка каршы коралны, авыр булганга күрә, ташлап калдырырга һәм тылга барып җитү ягын карарга әмер биргән. Чолганыштан чыкканда, ул күп кан югалткан һәм ярым аңсыз хәлгә җиткәндә, каршына бер кеше килүен күргән, якынайгач кына аның иңенә автомат аскан немец солдаты икәнен аңлаган. Ул чакта курку да, көч-куәт тә, һәм кулда корал да булмаган... Федя бабабыз үлемнән куркып, сукмактан читкә дә тайпылмаган. Немец хәлсез совет солдатына карап, тыныч кына атлый биргән. Алар тигезләшкән, бер-берсенең күзләренә караганнар һәм немец солдаты туктамыйча узып киткән. Федя бабабыз да аркасына ядрә килүенә әзер булган. Ату яңгырамаган. Әмма немец бабабызның аркасына түгел, һавага аткан да ары атлаган. Феогент Самойлович безнекеләргә кадәр чыга алган, аны, Свердловск өлкәсендә яшәүче энисе һәм энеләре шатлыгына, Свердловск госпиталенә җибәргәннәр. Сугышка башка алмаганнар, кулы терсәк сөяге турысында бөгелми-турайммый торганга әйләнгән. Ул исәп-хисапчылар курсын тәмамлаган һәм лаеклы елга кадәр Староуткинск металлургия заводының баш хисапчысы булып эшләгән. Безнең өчен ул чын герой, җиңүче, тик беркайчан да сугыш турында сөйләмәүче, аны искә алмаучы кеше иде!

Бу күргәзмәдә эшләре куелган һәр рәссамның Бөек Ватан сугышында катнашкан туганнары бар. Һәрберебез үз иҗатында шушы теманы яктырта. Укытучым Александр Быстров бервакыт әйтте: «Иң мөһиме – бирешмә! Бары алга бар – бер адым да артка чигенмә!» Мин шулай эшлим дә. Менә хәзер шушы күләмле күргәзмәбезне Казанга, тарихи Ватаныма алып килдем! (Әтием нәселе – Татарстаннан). Аны тамашачылар ошатып карар дип өметләнәм».

Академик А.К.Быстровның күргәзмә уңаеннан әйтелгән сүзләре: «Әлеге рәссамнар үз картиналарында караңгылык белән яктылык арасындагы көрәш темасын яктыртырга тырышты. Рәссамнарыбыз – туры юлда, әлеге осталарның әсәрләре тирән патриотик рухта, милли рухта, аларда үткәннәргә дә һәм күбрәк дәрәҗәдә киләчәккә дә караш салынган. Алар кыю рәвештә алга бара, бу искиткеч рәссамнарның картиналарында реализмның бөек көче һәм Санкт-Петербург академия мәктәбе традицияләре көче бар!»

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк, г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 29.07.2022

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2600 данә

Заказ 2763

16+